# Татарстанда ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ

№1 МАРТ 2016

МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ П2268



## Россия Президенты Владимир ПУТИН: «Ачарга рөхсәт итәм!»

16 бит

# Татарстанда ЖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ

МЕСТНОЕ САМОУПРАВЛЕНИЕ В ТАТАРСТАНЕ

№1, март 2016
Мәгълүмати-аналитик, иҗтимагый-сәяси басма

**БАШ МӨХӘРРИР**
Нияз ӘХМӘДУЛЛИН, e-mail: redaktorms@gmail.com

**БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ**
Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ

**ЧЫГАРЫЛЫШ МӨХӘРРИРЕ**
Фәридә Әхмәтҗанова

**ЖУРНАЛИСТЛАР**
Марина Бельтикова, Людмила Карташова,
Екатерина Куликова, Лилия Нурмөхәммәтова

**ФОТОГРАФЛАР**
Андрей Титов, Таһир Мәхмүтов

**ВЕРСТКА**
Евгений Курьянов

**КОРРЕКТОР**
Айсылу Корманова

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт Идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү турындагы таныклык ПИ №ТУ 16-00621, 29.09.2011.

Журнал татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.
Гомуми тираж: 3270 данә (татар телендә – 1341 данә,
рус телендә – 1929 данә)



Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстанда җирле үзидарә» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.



**РЕДАКЦИЯ:**
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Тел.: (843) 293-60-15

«Казанская недвижимость» Нәшрият йорты» ЯАҖндә басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2нче йорт
Заказ: № 12458
Офсет басма
Басарга кул куелды: 18.03.2016

16+

**Гамәлгә куючы һәм нәшер итүче:**
**Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы 420014, Татарстан Республикасы, Казан, Кремль**


## ЭЧТӘЛЕК




ТАТАРСТАН муниципаль хакимиятенә 10 ел **6 бит**



Минсәгыйть ШАКИРОВ: «Ун ел – тарих өчен мизгел генә ул» **8 бит**



КОЛЛЕГАЛАР котлый **12 бит**



**РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
РӘИС –
**Шакиров Минсәгыйть Закирович,** Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе

**Андреева Людмила Николаевна** – Казан шәһәр думасы секретаре

**Белов Александр Николаевич** – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент җитәкчесе

**Воропаева Татьяна Васильевна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе урынбасары

**Гарипов Илнур Мәхмүтович** – ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – ТР Президентының Территорияләр белән эш идарәсе башлыгы

**Гусева Любовь Акимовна** – сәясәт фәннәре кандидаты, КФУның дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты

**Ратникова Римма Атласовна** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары

**Хәбибуллин Альберт Галимҗанович** – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе



*Владимир ПУТИН: «Ачарга рөхсәт итәм!»* **16 бит**

*РЕСПУБЛИКА саннарда* **18, 28, 42 битләр**





*СТРАТЕГИЯ-2030: муниципаль дәрәҗәдә* **20 бит**

*СЕССИЯЛӘР йомгаклары буенча брифинг* **22 бит**





*БАЛАЛАР өчен удар төзелеш* **24 бит**

*КРИЗИСКА каршы инвестицияләр* **30 бит**





*ДӘВАМЫ булачак* **32 бит**

*ТЫКШЫНУ бәһасе* **34 бит**





*КЕЧЕ хуҗалыкларның «олы» хуҗалары* **38 бит**

*БӘХЕТ формуласы* **44 бит**





*ТАРТЫЛУ ноктасы* **48 бит**

*КАМА буендагы яшел кала* **52 бит**





*МАТУР авыл* **56 бит**

*КАНУН яңалыклары* **60 бит**



## ИКЪТИСАДЫЙ ЙОМГАКЛАР




2015 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында сәнәгать җитештерүе күләме 1 трлн 856 млрд сум тәшкил иткән, сәнәгать җитештерүе индексы – 100,4 процент. Татарстанда сәнәгать җитештерүе күләменең иң зур өлеше (60,9 процент) нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләренә туры килә – 1 трлн 131 млрд 300 млн сумнан артык. Бу саннар ТР Икътисад министрлыгы һәм ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының уртак йомгаклау коллегиясендә яңгырады.

Чарада ясаган чыгышында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов алты-җиде елда Татарстан сәнәгать җитештерүе күләмен өч тапкырга арттыра ала, дигән ышаныч белдерде. «Төп үсеш ноктасы – нефть-газ химиясе, беренче чиратта «Татнефть» компаниясе һәм кече нефть компанияләре – алар нефть чыгару күләмнәрен тәэмин итәргә һәм ресурс базасы – битум, сланец нефте, яңа технологияләр буенча җитди эш алып барырга тиеш. 2017 ел ахырына без ТАНЕКОның яңа комплексы төзелешен төгәлләргә тиеш, ә бу исә тагын 6 млн тонна нефть эшкәртү дигән сүз», – диде республика башлыгы.

РФ сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Дмитрий Овсянников Татарстан сәнәгатенә булышлык итү һәм үстерү буенча масштаблы эш алып барылуы турында мәгълүмат җиткерде. 2008 елдан башлап 2015 елга кадәр 48 млрд сумнан артыграк федераль субсидияләр 109 сәнәгать һәм сәүдә предприятиесенә бүлеп бирелгән. Республиканың моношәһәрләрендәге сәнәгатькә ярдәм итүгә аерым игътибар бирелә. Татарстанда шәһәр формалаштыручы предприятиеләре – «ПОЗиС» АҖ, Алабуга автомобиль заводы, «КАМАЗ» ГАҖ һәм «Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы» ААҖ – РФ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының эшчәнлек өлкәсенә караган дүрт моношәһәр бар. 2015 елда ТР моношәһәрләре предприятиеләренә 7,7 млрд сумнан артык суммада ярдәм күрсәтелгән. Быел 2 февральдә РФ Хөкүмәте Яр Чаллы шәһәрендә алга-рышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе булдыру турында карар кабул итүен билгеләп үтик. Бу «КАМАЗ» ГАҖнән тыш, тагын 10 меңгә якын яңа эш урыны булдыру мөмкинлеге бирер һәм шәһәрнең инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттырыр, дип көтелә. Инвестицияләр күләмен ел саен, ким дигәндә, 20 процентка арттырырга планлаштыралар.

## МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ




Узган елда мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагының тулай кереме 49 млрд сумнан артып киткән, бу 2014 ел белән чагыштырганда, 1,5 процентка күбрәк. «Быел әлеге күрсәткеч 52 млрд сум тәшкил итәргә тиеш», – дип билгеләп үтте министрлыкның йомгаклау коллегиясендә ТР премьер-министр урынбасары – ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов.

«Узган җәйдә РФ Хөкүмәте рәисе Дмитрий Медведев катнашлыгында тантаналы рәвештә Иннополис шәһәре ачылды. 2015 елда аның территориясендә 34 компания теркәлде, республика дәрәҗәсендә 96 млн сумлык салым җыеп алынды», – диде министр. Хәзерге вакытта 15 компания МИЗ резиденты булып тора. «Иннополис» МИЗның беренче резидентларыннан кергән инвестицияләрнең гомуми күләме 2,7 млрд сум.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагы өчен төп бурыч булып Иннополис шәһәренең алга таба үсеше кала, дип басым ясады. Перспективада әлеге шәһәр Россиянең ИТ-башкаласы булырга тиеш, ди республика башлыгы. Рәсми саннарга караганда, бүген Россиядә миллионга якын ИТ-белгеч кирәк. ТР Президенты әлеге проблеманы хәл итү өчен, Иннополистагы университет кына аз, республиканың башка югары уку йортларын да җәлеп итәргә кирәк, дип саный.

Электрон хезмәтләр үсеше турында сөйләгәндә, Рөстәм Миңнеханов, ил җитәкчелеге алдында 2018 елга Россиянең 70 процент халкына электрон дәүләт хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге тудыруны тәэмин итү бурычы тора, дип ассызыклады. Былтыр Татарстанда республика халкына 60 миллионнан артык электрон хезмәтләр күрсәтелгән, бу 2014 ел белән чагыштырганда, 84 процентка күбрәк. Электрон түләүләр суммасы бер ел эчендә 2 тапкырдан да артып, 6,5 млрд сумга җиткән.

## ЗУР һӘМ КЕЧЕ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР




Төп капиталга инвестицияләр кертү буенча Татарстан гадәттәгечә Идел буе федераль округында беренче урында, ә Россиядә беренче өчлеккә керә – ТР Инвестицияләр үсеше агентлыгының йомгаклау коллегиясендә шушындый мәгълүмат яңгырады. Былтыр төп капиталга җәлеп ителгән инвестицияләр күләме 597 млрд сум тәшкил итте, дип билгеләде Агентлык җитәкчесе Талия Миңнуллина. 2015 елда республикага чит илләрдән 812 млн доллар инвестиция җәлеп ителгән, шуның турыдан-туры килгәне – 482 млн долларга якын. «Инвестицияләрнең күп өлеше «Алабуга» МИЗ резидентларына туры килә, – дип билгеләп үтте Агентлык башлыгы. – Димәк, Татарстан көн саен 2 миллионнан артык доллар җәлеп итә».

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында республиканың инвестицияләр эзләрлек мөмкинлекләре күп, аларның барысы да кулланылмый, дип басым ясады. «Инвестицияләр – тыштан кергән акчалар гына түгел, беренче чиратта, һәр районның, һәр шәһәрнең һәм республиканың, тулаем илнең үз потенциалын ачарга кирәк, – диде республика башлыгы. – Әлбәттә, тышкы инвесторлар белән эш алып бару да мөһим, чөнки безгә акчалардан тыш, технологияләр, тәҗрибә, ышанычлы партнерлар һәм яңа базарлар да кирәк». Бүген һәрбер шәхси ихата, крестьян хуҗалыгы, кече һәм эре предприятиеләр – болар барысы да инвесторлар, дип саный Татарстан Президенты. «Әгәр элек инвестицияләр һәм аларны җәлеп итү турында икътисад министры, сәнәгать министры яки махсус икътисадый зона җитәкчесе сөйләсә, бүген инде үзен хөрмәт итә торган һәрбер район башлыгы инвестицияләр җәлеп итәрдәй, нәтиҗәдә яңа эш урыннары булдырырдай, салым базасы туплардай кызыклы проектлар эзли», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

## «ҮСЕШ НОКТАСЫ»




Февраль уртасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов район һәм шәһәр Советларының йомгаклау сессияләрендә катнашу кысаларында Түбән Кама муниципаль район Советы утырышында катнашты. Чара башланыр алдыннан ул Түбән Кама нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы базасындагы ресурслар үзәгенең эше белән танышты. Уку-укыту учреждениесе нефть химиясе тармагы предприятиеләре өчен 8 эшче һөнәре һәм 2 белгечлек буенча кадрлар әзерли. Бүген техникумда, Менделеевск филиалын да исәпләп, 1195 булачак белгеч белем ала.

Район һәм шәһәр Советы сессиясендә Түбән Кама районы башлыгы һәм Түбән Кама шәһәренең мэры Айдар Метшин муниципаль берәмлекнең узган елда ирешкән нәтиҗәләре турында хисап тотты. 2015 ел йомгаклары буенча, Түбән Кама районы ТР сәнәгать продукциясе күләменең 23 процентын җитештергән. Сәнәгать җитештерүе индексы 102,3 процент тәшкил итә. Төп капиталга инвестицияләр җәлеп итү күләмнәре буенча район республиканың муниципаль берәмлекләре арасында 2 урынны алган. «Шушы чорга берләштерелгән бюджет күләме 18 млрд сум тәшкил итә, ягъни республика бюджетыннан алган финанслар күләме шәһәр һәм район бюджеты белән бермә-бер туры килә диярлек», – дип өстәде Айдар Метшин.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Түбән Кама депутатлары алдында чыгыш ясап, республиканың якын киләчәктә төп үсеш ноктасы булып Кама инновацияле территориаль-җитештерү кластеры тора, дип билгеләде. Ә төп пункт бирелдә – Түбән Кама районы, ул нефть химиясе өлкәсе өчен җавап бирә.

«Түбән Кама – бөтен ил күләмендә җитди сәнәгать төбәге. Биредә каучуклар, полимерлар һәм нефть эшкәртүнең эре үзәге урнашкан. Биредә югары һөнәри осталыкларын күп тапкырлар раслаган куәтле коллективлар эшли. һәм мин Түбән Камада нефть-газ химиясе комплексын үстерү буенча программаларыбызның гамәлгә ашырылачагына шикләнмим», – дип сүзен йомгаклады Рөстәм Миңнеханов.

## ХИСАП ЧАМАСЫ



ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы коллегиясенең йомгаклау утырышы Казанның аерым предметларны тирәнтен өйрәтүче 179нчы урта белем бирү мәктәбендә узды.

ТР Премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов ведомствоның узган елгы эш нәтиҗәләренә анализ ясады һәм 2016 елда төп бурычларның берсе – инклюзив белем бирүне активлаштыру, дип басым ясады. «Бүген үк гомуми белем бирү учреждениеләре һәм массакүләм мәктәпләрнең аерым сыйныфлары базасында мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирүне оештыру юнәлешендә эшләүче муниципалитетлар бар», – диде ул. Бүгенге көнгә 9 районда 6 коррекцион сыйныф оештырылган, аларда ишетү, сөйләм, терәк-хәрәкәт системасы һәм акыл үсеше тоткарланган 500дән артык бала укый. Казанның 78нче мәктәбе базасында мөмкинлекләре чикләнгән балаларны сәламәт яшьтәшләре белән бергә укыту өчен ресурс үзәге булдырылган.

ТР Премьер-министры Ильдар Халиков, коллегиядә катнашучылар алдында чыгыш ясап, Татарстанда белем бирү сыйфаты мәсьәләләрендә нәтиҗәләр һәрвакыт яхшы булды, соңгы елларда тагын да яхшырды, дип билгеләп үтте. «Россиядә үткәрелгән тикшеренүләр күрсәткәнчә, безнең мәктәп укучыларының нәтиҗәләре гомумроссия күрсәткечләреннән 10–20 процентка югарырак», – дип ассызыклады ул. ТР Премьер-министры республикада лидер мәктәпләр һәм аутсайдер мәктәпләр булуын аерым игътибарга алды. Иң яхшы мәктәпләргә генә стимул була торган түгел, ә аутсайдерлар да чыгу юлын таба алырдый система булдыру мөһим. Хөкүмәт башлыгы директорлар һәм укытучылар мөдирләре өчен хисап эшенең артык күп булуына да басым ясады. Бу процессны гадиләштерергә һәм автоматлаштырырга кирәк. Аның фикеренчә, 2015 елгы хисапларны анализлап, кайсылары мөһим, кайсыларының кирәк түгеллеген ачыклау зарур.

## ЧАЛЛЫНЫ ДИВЕРСИФИКАЦИЯЛӘҮ

Икътисадый җәһәттән катлаулы булган 2015 ел йомгаклары буенча, Яр Чаллы предприятиеләрендә эшләп чыгарылган сәнәгать продукциясенең күләме 185 млрд сум тәшкил иткән. Сәнәгать җитештерүе индексы – 80,2 процент (ТР – 100,4 процент). Бу турыда шәһәр Советының йомгаклау сессиясендә Яр Чаллы шәһәренең мэры Наил Мәһдиев әйтте. Шәһәр икътисадына шәһәрне формалаштыручы төп предприятие – КАМАЗ зур йогынты ясый. Шәһәр башлыгы Яр Чаллы үсешендә монојүнәлешле икътисадтан китү һәм аны алга таба диверсификацияләү мөһим шарт булып тора, дигән фикердә. Ул, бүгенге көндә шәһәрдә 30 меңнән артык кече һәм урта бизнес субъекты эшли, аларда 50 меңнән артык кеше хезмәт куя, дип белдерде. Эшкуарлык өлкәсе тулай территориаль продуктының 30,1 процентын һәм җирле бюджетка кергән салымнарның 35 процентын формалаштыра. Быелтыр шәһәрдә индустрия һәм сәнәгать паркларының үсешен тәэмин итү эше дәвам иттерелгән: «Мастер» Кама индустриаль паркы (257 резидент, 5 мең эшче, 2015 елгы табышы – 28,9 млрд сум), «Үсеш» (18 резидент, 5се төзелеш башлаган), «Чаллы» (3 резидент, 30 млн сумлык продукция) һәм «Җиһаз базасы».

Яр Чаллының 2015 елдагы үсешенә йомгак ясап, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов эшчәнлекнең шактый юнәлешләрендә ирешелгән югары күрсәткечләрне билгеләп үтте. Яр Чаллы – уку-укыту, балалар туу буенча республика рейтингында икенче урында. Шәһәрнең төп бурычы – Татарстан Президенты моңа басым ясап әйтте – кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү. «Безгә яңа нәтиҗәле җитештерү проектларына инвесторлар чакырырга кирәк», – дип өндәде республика башлыгы.



## ЮГАРЫ АМБИЦИЯЛӘР

Бизнесны районның географик үзенчәлекләрен истә тотып, андагы кешеләр ярдәмендә оештырырга кирәк, диде мамадышлыларга ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Мамадыш муниципаль районы Советы утырышында чыгыш ясап. «Сезнең янәшәдә эре сәнәгать үзәкләре урнашкан: Түбән Кама, Яр Чаллы, «Алабуга» МИЗ. Сез бу процесска кушылырга тиеш», – дип басым ясады республика башлыгы. Аның фикеренчә, сәнәгать предприятиеләрен үстерү, урта һәм кече бизнесны булдыру таләп ителә. «Югары амбицияле бурычлар куярга кирәк, – диде ул. – Сез үзегезнең керемнәр өлешен 50 процентка кадәр арттырырга планлаштырасыз. Үз-үзеңне туендырып тору – 100 процент ул». «Тулаем алганда, районда кызыклы идеяләр күп. Аңлашыла, район зур һәм авырлыклар җитәрлек. Әмма динамиканы саклап кына калырга түгел, тизләтергә дә кирәк. Моның өчен барлык мөмкинлекләр дә бар», – дип ышана ТР Президенты.

Район башлыгы Анатолий Иванов үзенең докладында районның берләштерелгән бюджеты, федераль һәм республика бюджетларыннан кире кайтарылмый торган керемнәрне дә кушып исәпләгәндә, 1 млрд 57 млн сум (расланган еллык күрсәткечтән 114 процент) тәшкил итте, дип билгеләде. Үз керемнәре – 361 млн сум, бу – берләштерелгән бюджетның 34 проценты. Соңгы 5 елда үз керемнәре 70 процентка кадәр арткан.

## АБРУЙ КҮТӘРҮ ТАЛӘП ИТЕЛӘ



Елның беренче ике аенда республиканың муниципаль берәмлекләре узган елга йомгак ясый. Район һәм шәһәр Советлары сессияләре республика җитәкчелеге катнашлыгында үтә. 3 февральдә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның Аксубай районы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында фикер алышуда катнашты. Дәүләт Советы спикеры капиталь ремонт ясалган урта мәктәпне, «Дельфин» йөзү бассейнын, район кашышлары күргәзмәсен карады. Районның мәдәният йортында җирле җитештерүчеләр – крестьян-фермер хуҗалыклары һәм эре КФХ, кием-салым тегү һәм башка халык һөнәрләре белән шөгыльләнүче һөнәрчеләр үзләренең продукцияләрен күргәзмәгә куйган иде.

Район башлыгы Камил Гыйльманов районның дотациядә калуын билгеләде, 2015 елда бюджеттан тәэмин ителеш 67,1 процент тәшкил иткән. Район территориясендә алты эре агросәнәгать предприятиесе эшли. Моннан тыш, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән тагын 45 КФХ шөгыльләнә. Авыл хуҗалыгының акчалата табышы, 2014 елга карата 112 процент булып, 937 миллион сум тәшкил иткән.

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, алдагы авыр елда тупланган потенциалны һәм көндәшлеккә сәләтлелекне югалтмас өчен, барлык тырышлыкны тупларга кирәк. Бу процесста авыл җирлекләре башлыклары мөһим роль уйнарга тиеш, республиканың агросәнәгать секторы һәм кече территорияләр үсешенең тәгаен бурычлары нәкъ менә алар җилкәсенә төшә. «Авыл җирлекләре башлыкларының ролен һәм абруен күтәрергә кирәк. Алар алдында бик зур бурычлар тора – территорияләр үсеше өчен актив кешеләрне эзләүне дәвам итү һәм республика бюджеты бирә торган мөмкинлекләрне аңлату. Боларның барысы да җирлекләрнең абруен күтәрә».

## МИЛЛИАРДЛЫК СӘЛАМӘТЛЕК

Ел башы традиция буенча республика министрлыкларының һәм ведомстволарының йомгаклау коллегияләре чоры. 4 февральдә Казанда ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының да коллегиясе узды. Әлеге чарада катнашкан ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, сәламәтлек саклау өлкәсендә киң күләмле эшләр башкарыла. Тармакның берләштерелгән бюджеты якынча 40 миллиард сум тәшкил итә. Әлеге суммага өстәмә рәвештә сәламәтлек саклау учреждениеләрен төзү, яңартып кору һәм капиталь ремонт ясау, аларга җиһазлар алу өчен тагын 4 миллиард сум акча бүленгән.

Соңгы вакытта сәламәтлек саклау өлкәсе структура һәм сыйфат ягыннан зур үзгәрешләр кичерде, дип саный республика башлыгы. «Шуңа карамастан халыкның сәламәтлек саклау өлкәсеннән күбрәк көтүен күрәбез. һәм, әлбәттә, без халыкның медицина хезмәтләренә булган ихтыяҗларын тулаем канәгатьләндердек, дип әйтә алмыйбыз». Татарстан Президенты әйтүенчә, күрсәтелә торган хезмәтләр дәрәҗәсе республика районнарына карап аерыла: «Кайдадыр без халыкара стандартларга җавап бирәбез, кайдадыр, кызганычка каршы, – юк. Матди-техник база да, белгечләр дә, медицина техникасы да барлык җирдә дә нормаларга туры килми». Рөстәм Миңнеханов ведомтсвоның эшчәнлеген уңай бәяләде. «Министр да, аның командасы да алдынгы сызыкта бара, дип саныйм, – диде ул. – Әмма сезгә кисәтүләр юк, дип әйтергә дә ярамый. Алар күп! Алга таба да булачак, чөнки кешеләр торган саен таләпчәнрәк була бара».

## ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ ЮБИЛЕЕ



Быел февраль башында хезмәттәшебез, Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы Вячеслав Михайлович Козлов 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. ТР Муниципаль берәмлекләре Советы ихлас күңелдән юбилярны тәбрик итә! Аның республика халкы хакына куйган күпьеллык хезмәте муниципаль җәмәгатьчелек арасында, тулаем Татарстанда абруй һәм ихтирам яулады.

Вячеслав Козлов 1956 елның 7 февралендә ТАССРның Чистай районы Яңа Чишмә авылында туган. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә эшләгәннән соң, 1990 елдан 2000 елга кадәр ул Яңа Чишмә районында район Советы рәисенең беренче урынбасары, район хакимияте башлыгы урынбасары була. 2000–2010 елларда Вячеслав Козлов Татарстанның Чистай районын җитәкли. 2010 елда язмыш аны туган җиренә алып кайта. Яңачишмәлеләр аны район башлыгы итеп сайлап, үзенең ышанычларын белдерә. Бу еллар Яңа Чишмә районының авылларында социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеш, кешеләрнең яшәү шартлары яхшыру буенча уңышлар белән билгеләнә.

Вячеслав Михайловичка сәламәтлек, көчегәр һәм туган районын үстерү юлында яңа уңышлар телибез!




Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН.

БЫЕЛГЫ ЕЛНЫ, һИЧ АРТТЫРУЛРСЫЗ, РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ҮСЕШЕ ӨЧЕН МӨһИМ ЕЛ ДИЯРГӘ БУЛА. МЕНӘ ИНДЕ УН ЕЛ ДӘВАМЫНДА РЕСПУБЛИКАНЫҢ һӘМ ТУЛАЕМ ИЛЕБЕЗНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТЛӘРЕ ХОКУКЫЙ КООРДИНАТАЛАРНЫҢ ЗАМАНЧА БЕРДӘМ СИСТЕМАСЫНДА ЭШЛИ. ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ ӨЧЕН ДӘ ЮБИЛЕЙ ЕЛЫ УЛ, ЧӨНКИ АЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ КОРЫЛТАЙЛАРЫ 2006 ЕЛНЫҢ МАРТЫНДА БУЛЫП УЗГАН ИДЕ.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР! КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимияте конгрессының мин җитәкләгән Актуаль мәсьәләләр комитеты исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән бүгенге көндә «җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү»не оештыруда иңнәрендә авыр йөк йөртүче барлык хезмәттәшләремә ихлас күңелдән зур рәхмәтемне белдерәм. Ул Россия Федерациясе 1996 елның 28 февралендә имзалаган Җирле үзидарәнең Европа хартиясенә тулысынча туры килә.

Шуны аерым ассызыклап үтәм: әлеге еллар дәвамында Татарстанда муниципаль хакимият органнары үсеше системасы эволюцион юл белән, нинди дә булса тетрәнүләрсез, шул ук вакытта динамикалы, федераль һәм республика кануннияте билгеләгән срокларны һәм нормаларны саклаган хәлдә барды. Әлеге өлкәдә үзебез туплаган мөстәкыйль хокукый көйләү, эшне оештыруга заманча якын килүләр һәм җәмәгатьчелек тәҗрибәсе моңа гарантия булды.

Муниципаль корылышның ныклы нигезенең конституцион реформага һәм 1994 елда кабул ителгән «Җирле үзидарә турында»гы республика канунына таянуы хәзер беркемгә дә сер түгел, ә аларны исә Россия төбәкләре арасында мондый канун иҗат итүнең беренче үрнәге дияргә дә буладыр. Гомумән алганда, гамәлдәге «җирлек моделен» саклаган хәлдә, без җирле үзидарәнең хокукый, икътисадый, финанска бәйле нигезләрен яңадән күздән кичердек һәм аның киләчәктәге алгарышлы үсеше өчен уңайлы шартлар тудырдык. Шуның нәтиҗәсендә, 1990нчы еллар ахырына Татарстанда ҖҮИнең эшли алырлык, халык мәнфәгатьләрен кайгыртырга сәләтле, муниципалитетларның нормаль эшчәнлеген тәэмин итәрлек системасы формалашкан иде инде.

ҖҮИ органнары вәкилләре Җыены тәкъдиме буенча, 1999 елда Татарстан Президенты Указы нигезендә оештырылган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советының беренче үрнәге – Җирле үзидарә буенча республика Советы бердәм дәүләт сәясәте булдыру, дәүләт һәм муниципаль структуралар, иҗтимагый оешмалар, кече һәм урта эшкуарлык вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү җәһәтеннән зур һәм уңай роль уйнады. Әлеге Совет гамәлдә булган җиде елга якын вакыт дәвамында миңа аның эшчәнлеге белән турыдан-туры җитәкчелек итәргә, җирле үзидарә органнарына бәйле оештыру-хокукый, кадрлар, ресурслар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә актив катнашырга, булышырга туры килде.

Әлеге җәһәттән, «Россия Федерациясендә җирле



**Төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларның керем өлешен шәкелләштерү чыганаклары ачыкланды һәм аларның чикләре билгеләнде. Муниципаль хакимият органнарында эшләүчеләрнең һөнәрилек дәрәҗәсе һәм кадрлар егәре сизелерлек яхшырды. Муниципаль берәмлекләр Советы йөзендә, ҖҮИ органнарының муниципальара нәтиҗәле хезмәттәшлеге оештырылды.**

**Гомумән алганда, бу вакыт эчендә Татарстанда киң колачлы җирле үзидарә системасының адекват институциональ-норматив кысасы барлыкка китерелде. Социаль өлкәләргә, аерып әйткәндә, җир-милек мөнәсәбәтләренә һ.б.ш. караган аерым бер дәүләт вәкаләтләрен муниципалитетларга тапшыру механизмы эшләнде.**

үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы» 131-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан башлап җибәрелгән киң колачлы муниципаль реформаны хокукый яктан «озата бару» республика Дәүләт Советының икенче һәм аннан соңгы чакырылышларында өстенлекле бурычларының берсе булды. Республика муниципаль берәмлекләренең чикләре һәм статусы депутатлар тарафыннан бик вакытлы билгеләнде. Муниципалитетлар тормышына турыдан-туры яисә читләтеп тәэсир итүгә бәйле «Җирле үзидарә турында», «Муниципаль сайлаулар турында», «Муниципаль хезмәт турында», «Яңа оештырылган муниципаль берәмлекләрдә җирле үзидарә органнарын оештыру турында» һәм башка күп кенә кануннар кабул ителде.

Гомумән алганда, бу вакыт эчендә Татарстанда киң колачлы җирле үзидарә системасының адекват институциональ-норматив кысасы барлыкка китерелде. Социаль өлкәләргә, аерып әйткәндә, җир-милек мөнәсәбәтләренә һ.б.ш. караган аерым бер дәүләт вәкаләтләрен муниципалитетларга тапшыру механизмы эшләнде. Төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларның керем өлешен шәкелләштерү чыганаклары ачыкланды һәм аларның чикләре билгеләнде. Муниципаль хакимият органнарында эшләүчеләрнең һөнәрилек дәрәҗәсе һәм кадрлар егәре сизелерлек яхшырды. Муниципаль берәмлекләр Советы йөзендә, ҖҮИ органнарының муниципальара нәтиҗәле хезмәттәшлеге оештырылды.

Сүз дә юк, җирле үзидарә органнарының проблемалары болар белән генә хәл ителә дип уйлау ялгыш фикер булыр иде. Киресенчә, биредә федераль хокукый көйләүнең тотрыксызлыгы, керем һәм чыгым йөкләмәләре арасындагы зур аерма һ.б. күп нәрсәләр барыбызга да билгеле. Үз мөмкинлекләребез кысаларында, югарыда атап үтелгән мәсьәләләрне федераль үзәк каршында даими рәвештә күтәреп чыгарга омтылабыз, канун чыгаручыларның төбәкара һәм округлардагы берләшмәләренең карарларын берләштереп кабул итүен тәкъдим итәбез. Шунысы сөенечле: республикабыз башлангычлары ил җитәкчелегендә аңлау һәм яклау таба...

Бөтен республикабызның киеренке һәм җаваплы хезмәте нәтиҗәсендә, Татарстан шәһәр һәм авылларының инфраструктурасы үсешендә уңай үзгәрешләр күзәтелә. Үзара салым, үсешнең төп юнәлешләре буенча халык белән ачыктан-ачык фикер алышу чаралары ярдәмендә, гражданнарны җирле проблемаларны хәл итүгә җәлеп итү дәрәҗәсе арта бара. Безнең дөрес юлда булуыбызны һәм халык алдында җирле үзидарәнең абруе күтәрелүен 2015 елда булып узган муниципаль сайлауларның уңышлы нәтиҗәләре раслый дип саныйм. Бүгенге тормышның гади булмаган шартларында, яңартылган депутатлар корпусына үз территорияләренең социаль-икътисадый үсешендә катнашуны җитди рәвештә активлаштыру зарури, шул исәптән Стратегия-2030 кысаларында.

Янәдән искәртеп үтәм: җирле үзидарә хакимиятнең халыкка иң якын торган баскычы ул, шунлыктан бездән ачыклык һәм көнүзәк проблемаларны тиешле югарылыкта хәл итүне өмет итәләр. Бүгенге фикердәшләр командасының мондый бурычларны үтәп чыга аласына шигем юк. Бөтен татарстанлылар мәнфәгатен кайгыртып башкарылучы катлаулы һәм җаваплы хезмәт юлыгызда уңышлар һәм яңа казанышлар теләп калам!



УН ЕЛ ЭЛЕК – 2006 ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫНДА РЕСПУБЛИКАДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ СИСТЕМАСЫ ГАМӘЛГӘ КЕРДЕ. РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬ БЕРГӘЛЕГЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ СЪЕЗДЫНДА ОЕШТЫРЫЛГАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР СОВЕТЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ БЫЕЛ МАРТ АЕНДА ШУЛАЙ УК УН ЕЛ ТУЛА. БҮГЕН БЕЗ ТР МБС РӘИСЕ МИНСӘГЫЙТЬ ШАКИРОВ БЕЛӘН ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЛАРЫНЫҢ УН ЕЛ ЭЧЕНДӘ НӘРСӘГӘ ИРЕШӘ АЛУЫ ТУРЫНДА ӘҢГӘМӘ КОРАБЫЗ.

# *Минсәгыйть ШАКИРОВ: «Ун ел – тарих өчен мизгел генә ул»*

**Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.**

**– Минсәгыйть Закирович, эш ничек башланып китте?**

– 2005 ел ахырында республикабызның район һәм шәһәр Советларының сайлап куела торган органнарына депутатлар сайлаулар булып узды. Сайлаулар җирле үзидарә турындагы яңа Федераль закон (131 – ФЗ) нигезендә үткәрелде, анда илнең барлык төбәкләре үз биләмәләрендә җирле үзидарә системасын кертеп бетерүнең соңгы вакыты (2006 елның гыйнвары) күздә тотылган иде. Шуңа ярашлы рәвештә, республикада җирле үзидарә системасы 2006 ел башыннан үз вазыйфаларына кереште.

Сүз уңаеннан искәртеп үтәсем килә: әгәр тарихка бераз тирәнгәрәк керсәк, җирле үзидарә турындагы беренче канун СССР Халык депутатлары съезды тарафыннан 1990 елда ук кабул ителгән иде. Соңрак илдә җирле үзидарәне кертүгә бәйле Россия кануннары, Россия Федерациясе Президентының шуны күздә тоткан указлары пәйда була. Димәк, күптөрле сәбәпләргә бәйле рәвештә, муниципаль хакимият дөньяга озак туа.

ҖҮИнең нигезен тәшкил иткән 131нче Федераль канунның нормалары, башка бик күп нәрсәләр белән бергә, Россия Федерациясе субъектларында Муниципаль берәмлекләр Советлары төзүне күздә тотты. Әлеге ка-



Совет Президиумының киңәйтелгән утырышы үзен нәтиҗәле эш форматы итеп күрсәтте.

нун нигезләмәләреннән чыгып, 2006 елның мартында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы (ТР МБС) оешты. Беркадәр соңрак Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы ( МБГК) барлыкка килде, без дә аның әгъзасы булдык.

Совет эшчәнлеген оештыру һәм финанс нигезләрен төзү эзлекле рәвештә барды. ТР МБС Уставында аның эшчәнлеген Совет әгъзасы булган Муниципаль берәмлекләр взнослары хисабына финанслау күздә тотыла. Шул финанс мөмкинлекләренә таянып, әүвәле дүрт кешедән торган Совет аппараты оештырылды. Беренче вакытларда үз бинабыз юк иде, Совет Казан мэриясе биргән бер кабинетка урнашты.

Россиянең төрле төбәкләрендә Муниципаль берәмлекләр Советларының аякка басуы төрлечә баруын чагыштырып карар өчен, бер мисал китереп узам: илебездәге Советларның кайберләре хәтта МБГКна әгъзалык взносларын да түли алмый иде, ә ул исә нибары 90 мең сум. Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы эшчәнлеге тарихында шундый мисаллар да бар: әгъзалык взносларын түли алмаганга, кайбер Советлар берничә мәртәбә МБГКнан чыгарылдылар, алар бераздан янәдән әйләнеп кайттылар һәм тагын шул ук сәбәп аркасында Конгресстан чыгарга мәҗбүр булдылар. Килешәсездер, 90 мең сум акча таба алмаган оешманың эшчәнлеген күз алдына китерүе дә авыр. Бу очракта ниндидер конструктив эш алып бару турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Кызганычка, федерациянең кайбер субъектларында Муниципаль берәмлекләр Советлары бүгенгәчә тулы көченә эшләп китә алмады әле.

Шул ук вакытта илебездә бик уңышлы эшләүче Муниципаль берәмлекләр Советлары аз түгел. ТР МБС да шундыйлар исәбендә, ул республика муниципаль бергәлегендә һәм дәүләт хакимияте органнарында үзенә ихтыяҗ булган, абруйлы оешмага әверелде. Минемчә, җирле үзидарә үсешендә Советларның роле бик зур. Бүгенге көндә башка берninди мәйданчыкта да муниципалитетларның үзара фикер алышуын, тәҗрибә уртаклашуын, проблемаларны уртага салып сөйләшүен, бергәләп эшләү планнарын коруын, дәүләт хакимияте органнары белән уртак хезмәттәшлек алып баруын күз алдына китереп булмый. Муниципаль берәмлекләр Советлары төбәк дәрәҗәсендә муниципаль берәмлекләрнең мәнфәгатьләрен алга сөрә, күтәреп чыга һәм кайгырта.

**– Советның дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеге ни рәвешле һәм нинди юнәлешләрдә гамәлгә ашырылды?**

– Татарстанның беренче җитәкчеләренең үз вакытында республика районнарын һәм шәһәрләрен җитәкләгәндә муниципаль дәрәҗәдә эшләү мәктәбен узуы, һичшиксез, безгә уңай килде. Шунлыктан алар территорияләрне үстерү һәм җирлекләрдә тормыш-көнкүрешне оештыру процессында җирле үзидарәнең урынын һәм ролен аңлый иде. Сүз дә юк, системаны нигезеннән башлап үзебезгә төзүгә бәйле авырлыклар да булды, барлык юнәлешләрдә кемдер башлаган эшне дәвам иттермәдек бит, беренче адымнарны үзебезгә ясарга туры килде. Эшебез Федераль кануниятә фикер каршылыклары күп булуы сәбәпле дә катлауланды. Бик еш кына дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының вәкаләтләр өлкәсе үзара кисешә яисә анык билгеләнмәгән иде. Кайбер төбәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хакимият арасындагы үзара мөнәсәбәтләр капма-каршы куелу сәбәпле, эшләре мәхкәмәдә тартышуга чаклы барып җитте. Татарстанда, киресенчә, дәүләт һәм муниципаль хакимият арасындагы мөнәсәбәтләр беренче көннән үк ныклы нигездә төзелде.

Республикабызның беренче Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиев һәм бүгенге Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов территорияләр белән нәтиҗәле идарә итүнең нигезе көчле җирле хакимият булуын үз чыгышларында даими рәвештә ассызыклый. Республика җитәкчелеге муниципаль идарәнең теләсә кайсы хакимиятнең нигезе булуыннан чыгып эш итә, чөнки ул халыкка аеруча якын тора, гражданнарның проблемалары һәм ихтыяҗлары белән тыгыз бәйләнештә.

Сүз дә юк, дәүләт хакимияте органнарының оештыру, фи-

нанс, хокукый, методик ярдәменнән тыш, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы эшкә сәләтле оешма буларак аякка басып, үзенә йөкләнгән вазыйфаларны тиешенчә үти алмас иде. Кайвакытта, муниципаль хакимиятләр дәүләт ярдәменнән файдалангач, алар мөстәкыйль түгел, дигән фикерне дә ишетергә туры килә. Ә бу алай түгел. Җәмгыятьтә тулысынча мөстәкыйль булырга ярамый. Һәр акыллы гамәл, эшчәнлек үзара көйләнү нигезендә корыла, ул үзара килештерелгән һәм гомуми бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Татарстан Республикасында эшләр нәкъ менә шулай башкарыла.

**– Совет алдына беренче чиратта нинди бурычлар куелган иде?**

– Барысын да алдан белдек, иң беренче менә монысын хәл итәбез, ә аннан соң тегесен дигән анык планнарыбыз бар иде, дип әйтә алмыйм… Юк, алай түгел. Көн тәртибе муниципаль хакимият органнарының көндәлек эшчәнлеге барышында килеп туган проблемалардан чыгып төзелде. Без баштан ук әлеге барлык мәсьәләләрне дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлектә генә чишеп булуыннан чыгып эш иттек. Шул рәвешчә, акрынлап Советның эш формалары шәкелләште, шулар арасында Совет Президиумының киңәйтелгән утырышларын, түгәрәк өстәлләрне үткәрү үзләрен аклады.

Совет Президиумында җирле үзидарә үсеше концепциясенә, муниципаль хакимиятнең дәүләт органнары белән үзара хезмәттәшлегенә бәйле күп мәсьәләләр карала. Президиум утырышларында ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе, ТР Министрлар Кабинеты вәкилләре, юнәлешле министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, республика муниципаль берәмлекләре башлыклары урынбасарлары катнаша.

Ел саен үткәрелеп килүче Республика муниципаль берәмлекләре съезды – муниципаль бергәлек өчен зур вакыйга. Әгәр эшчәнлегебез башланган чорда резолюцияләрне съезд нәтиҗәләреннән чыгып кабул итсәк, соңрак ТРның дәүләт һәм муниципаль хакимияте органарының уртак эшчәнлеге чаралары планын әзерли башладык. Бу документта муниципаллар һәм республика министрлыклары алдында торган барлык төп бурычлар бер ел алдан бәян ителә, җирле үзидарә һәм дәүләт хакимияте органнары алдында торган җаваплылык зоналары ачыклана. Әлеге Планны ТР Премьер-министры һәм Муниципаль берәмлекләр Советы рәисе имзалаганнан соң, ул Татарстан Президенты тарафыннан раслана. Шул рәвешчә, Планда куелган бурычларны үтәү, муниципалларга гына түгел, республика органнары өчен дә, шулай ук федераль министрлык һәм ведомстволарның территориаль бүлекчәләре өчен дә мәҗбүригә әверелә. Советның чираттагы һәр съездында, уртак чаралар планына бәйле йөкләмәләрнең үтәлеше, теге яки бу сәбәпләр аркасында, кайсыларының әлегә көнүзәк мәсьәлә булып калуы хакында делегатларга тулы хисап бирелә. Түгәрәк өстәлләр күбесенчә гамәли мәсьәләләрне карауга багышлана. Җирле үзидарә үсешендәге күп проблемалар хуҗалык итүгә бәйле, ә алар исә көндәлек тормышта пәйда булган каршылыклардан туа. Шунлыктан без алар турында түгәрәк өстәлләрдә уртага салып фикер алыша башладык, аларда ТР Премьер-министрының беренче урынбасары, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары рәисләре катнаша.

Съездларның берсендә ҖҮИ хезмәткәрләренә тәгаенләнгән бүләкләр булдыруны тәкъдим иттек. ТР Президенты безне хуплады, нәтиҗәдә «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен» дигән медаль барлыкка килде. Аңа йөзләгән иң яхшы муниципаль хезмәткәр лаек булды инде. Ә аннан соң Советның үз бүләкләрен – Мактау грамотасын һәм ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисенең Рәхмәт хатын булдырдык.

Безнең башлангыч нигезендә республиканың иң яхшы муниципаль берәмлекләренә грантлар булдыру – Совет эшчәнлегенең тагын бер сизелерлек һәм әһәмиятле эш нәтиҗәсе. Ел саен бәйге нәтиҗәләре буенча сайлап алынган иң яхшы 104 авыл җирлегенә, үз биләмәләрендәге проблемаларны хәл итү өчен, 1 миллион сум акча бирелә. Муниципаль хезмәткәрләрдә үз эшенә кызыксыну уяту максатыннан, Совет 15 номинация буенча республика бәйгесе игълан итте. Җиңүчеләр Россиядә җирле үзидарә көне алдыннан бүләкләнә. Ел саен (ике мәртәбә) республиканың иң яхшы муниципалитетларына автомобильләр бирелә, аның ачкычларын ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшыра.

Эшчәнлегебез барышында шундый нәрсәгә тап булдык: җирле үзидарә системасы шактый нәтиҗәле эшләгән авыл җирлеге белән чагыштырганда, шәһәрләрдә, аеруча зур калаларда, халык шактый ук сүлпән. Биредә яшәүчеләр үзләренең җирле үзидарәне гамәлгә ашырудагы ролен, бу процесста катнашуның зарурияттен тулысынча аңлап бетерми. Нәкъ менә шуңа төшенүебез нәтиҗәсендә, республика шәһәрләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү идеясе туды. Бүгенге көндә бездә 350гә якын ТИҮ төзелде һәм эшчәнлек алып бара инде.

Татарстан муниципаллары Россия төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге җирле үзидарә үсеше тәҗрибәсен даими рәвештә өйрәнә. Әйтик, узган елның ноябрендә Казанда Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессының күчмә утырышы булып узды.

**– Муниципаль хакимият үсеше процессына нинди бәя бирер идегез?**

– Бу процесс дәвам итә. Тулаем алганда, бүгенге көндә республика муниципаль берәмлекләренең үсеш темплары әйбәт. Татарстанда социаль-икътисадый үсеш буенча утыздан артык программа эшли. Алар нигезендә ФАП, клублар, балалар бакчалары сафка бастырыла, мәктәпләр төзекләндерелә, парклар һәм башка күп нәрсәләр булдырыла, муниципаль берәмлекләр дистәләгән еллар дәвамында җыелып килгән бик күп проблемаларны хәл итә. Әлеге программаларның берсе узган елда безнең Совет инициативасы белән кабул ителде, ул авыл Советлары биналарын капиталь төзекләндерүне күздә тота.

Республикада эшли башлаган үзара салым салу программасы бик югары нәтиҗәлелеккә ия башлангычларның берсенә әверелде. Шул ук вакытта, халыктан җыелган акчаларга 1гә 4 нисбәтендә республика бюджетыннан өстәп түләнә. Бюджетның үзара салымга бу рәвешле катнашуына мисалның Россиянең бер генә төбәгендә дә булганы юк әле. Үзара салым авыл җирлеге өчен ае-



Республика җитәкчеләре җирле үзидарәнең Татарстан үсешендәге ролен яхшы аңлыйлар.

руча көнүзәк мәсьәлә ул, анда яшәүчеләр акчаларны җыюда теләп катнаша, чөнки аларның барысы да нәкъ менә үз авылларында яки бистәләрендә аның нинди максатка тотыласын беләләр. Үзара салым аркасында, кешеләр бергә берләшкәч, юлларны төзекләндерү, биләмәләрне тәртипкә китерү, сулыкларны чистарту кебек турыдан-туры үзләренә мөнәсәбәтле бик күп катлаулы мәсьәләләрне хәл итеп булуына инаналар.

Тагын бер мөһим мәсьәлә муниципаль кадрларны һөнәри яктан әзерләүне үз эченә ала. Җирле үзидарәгә старт бирелүгә, республика муниципаль хезмәткәрләр рәтен тутырырга сәләтле югары әзерлекле белгечләргә кытлык кичерә башлады. Элек муниципалитетларда юристларга һәм икътисадчыларга ихтыяҗ юк иде. Хокукый кыр шактый ук гади һәм аңлаешлы булды. Әмма җирле үзидарә турындагы федераль кануниятькә шактый зур тизлек белән үзгәрешләр кертелә башлады. Үз көченә кергәннән бирле, 131-ФЗ номерлы Федераль законга йөздән артык төзәтмә кертелде, моннан тыш, шул кануннардан чыгып кабул ителгән, хокукый нормаларны аңлауны бик нык катлауландыручы бихисап актлар барлыкка килде. Муниципалитетларда өсте-өстенә өелгән хокук бозулар усал нияткә бәйле түгел, ә юридик әзерлекнең тиешенчә булмавы аркасында иде. Әлеге вазгыятьтә һөнәрмәндләргә ихтыяҗ бик зурдан булды.

Нәкъ менә шул сәбәпле, без муниципаль хакимият органнары хезмәткәрләрен һөнәри яктан әзерләүгә һәм булганнарының белемен күтәрүгә җитди рәвештә керештек. Әлеге гамәлебездә ТР Президентының Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты, КФУның Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе бик нык булышты. Алар белән берлектә укыту программалары төзелде, белем бирү алып барыла.

Муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән һәм республиканың барлык төбәкләрендә ел саен уздырылучы белем бирү семинар-киңәшмәләре даими эшкә әверелде. Министрлыклар һәм ведомстволар, федераль структураларның территориаль органнары вәкилләре авыл җирлекләре башлыклары, муниципаль хезмәткәрләр алдында чыгыш ясый һәм аларның сорауларына җавап бирә. Шунысы бик мөһим: семинарларның бөтен темалары муниципаллар белән алдан ук килештерелә.

Быел ТР Муниципаль берәмлекләре Советының үз журналын бастырып чыгара башлавына биш ел тула. Басма муниципаль хакимият эшчәнлеген яктыртуда бик әһәмиятле роль уйный, әлеге мәйданчыкта муниципаллар иң уңышлы тәҗрибәләре белән уртаклаша, биредә муниципалитетлар тормыш-көнкүрешенең төрле өлкәләре анализлана, кануниятътәге үзгәрешләр киң яктыртыла. Журналның уңышлы булуын аның 3 мең данәдән күбрәк булган тиражы раслый, ул хәтта федераль «Муниципаль Россия» журналыныкыннан да артыграк. Совет эшчәнлеге, ҖҮИ үсеше гомумән алганда башка ММЧнда да киң яктыртыла, аерып әйткәндә, ТНВ каналында муниципаль бергәлеккә багышланган тапшырулар даими рәвештә чыгып килә.

Бүгенге көндә Муниципаль берәмлекләре Советында һөнәрилеккә ия коллектив оешты. Совет Аппараты ҖҮИ үсеше барышында туган барлык проблемаларны анализлый, аларны хәл итүгә юнәлдерелгән программалар төзи. Юридик идарә муниципаль берәмлекләргә актив рәвештә хокукый ярдәм күрсәтә, моңа авыл җирлекләрендә ихтыяҗ аеруча зурдан. Юристларыбыз мәхкәмә процессларында муниципаль берәмлекләр мәнфәгатен яклый, җирлекләргә норматив актлар әзерләүдә ярдәм күрсәтә.

**– Юбилей елында республика муниципалларына нинди теләк телисез?**

– Җирле үзидарә системасы гамәлдә булган ун ел эчендә республикада күп нәрсәләр эшләнде. Тормыш бер урында гына тормый бит, алда безне яңа бурычлар көтә. Ун ел – тарих өчен мизгел генә ул, шунлыктан, хезмәттәшләремә киләсе унъеллыкта узганындагысыннан да күбрәк эшләргә насыйп булсын, дигән теләктә калам.



**Виктор КИДЯЕВ, РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасының Федератив корылыш һәм җирле үзидарә мәсьәләләре комитеты рәисе, Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы президенты**

**Хөрмәтле Минсәгыйть Закирович!**

Сезне һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советының барлык әгъзаларын Совет оешуның 10 еллыгы белән ихластан тәбрикләргә рөхсәт итегез! Сез туплаган гамәли һәм теоретик тәҗрибә чыннан да уникаль дип әйтү бер дә арттыру булмастыр. Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең үсеше һәм аңа ярдәм иң югары дәрәҗәдә оештырылган. Сез сүздә генә түгел, чынбарлыкта да төбәк һәм муниципаль хакимиятләрнең тыгыз хезмәттәшлеген җайлый һәм шуның белән бергә халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, социаль һәм икътисадый проблемаларны хәл итүгә булышу, гражданнарны җирле үзидарә процессына җәлеп итү кебек төп бурычларны хәл итә алдыгыз. Әлеге системалы эш нәтиҗәләре күзлексез дә күренә, сезнең җирле үзидарә үстерүне көйләүгә, муниципаль бюджетларны тулыландыруның яңа чыганакларын булдыруга, муниципалитетларның кадрлар базасын ныгытуга юнәлтелгән инициативаларыгыз һәрьяклап өйрәнүгә һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында таратуга лаек.

Сезгә ихлас күңелдән Татарстан Республикасы халкының тормышын яхшырту юнәлешендәге эшегездә яңа уңышлар телим. Идеяләрегез алга таба да хезмәттәшләрегезне һәм фикердәшләрегезне берләштерсен, ә барлык башлангычларыгыз уңышка ирешсен!



**Наталья РЕПИНА, «Мари Эл Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенең башкарма директоры**

**Хөрмәтле коллегалар!**

«Мари Эл Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе Татарстан Республикасы муниципаль бергәлеген истәлекле вакыйга – ТР Муниципаль берәмлекләре Советы эшчәнлегенең 10 еллыгы белән тәбрик итә! Эшчәнлекнең 10 еллыгы – үткән чорда эшләнгәннәргә тагын бер тапкыр тирән һәм һәрьяклы анализ ясап, ирешелгән нәтиҗәләргә бәя бирү һәм киләчәктә үсеш юлларын билгеләү өчен яхшы мөмкинлек ул.

Бу елларда Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы Идел буе федераль округында да, Россия Федерациясе дәрәҗәсендә дә үзенең әһәмиятен һәм зарурлыгын дәлилләде. Совет муниципаль берәмлекләргә ярдәм күрсәтү буенча бик зур эш алып бара, дәүләт хакимияте органнары эшендә актив катнаша һәм муниципалитетара хезмәттәшлекне үстерә. Нәкъ менә ТР Муниципаль берәмлекләре Советы муниципалларның мәнфәгатьләрен федераль дәрәҗәдә яклауга юнәлтелгән күп кенә закон чыгару инициативаларын башлап җибәрүче булып тора.

ТР Муниципаль берәмлекләре Советы 10 еллык эшчәнлеге дәверендә гамәлдәге проблемаларны хәл итүнең бердәм юлларын таба, уңай тәҗрибәне күрә, хуплый һәм тарата, муниципаль кадрларны төрле яклы белем белән тәэмин итә алды.

2015 елның 12–14 ноябрендә Казанда Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы әгъзаларының гомуми җыелышын үткәргәндә Советның бөтенроссия күләмендәге әһәмияте тагын бер тапкыр расланды. Россия Федерациясе субъектларының күп кенә Муниципаль берәмлекләре Советлары киләчәктә үз эшләрен ТР Советы тәҗрибәсен өйрәнеп һәм нигез буларак алып оештырачак. Кунакларга җитди мөнәсәбәтне һәм 2015 елның 12–14 ноябрендә Советлар делегацияләрен кабул итүдәге югары дәрәҗәне тагын бер кат билгеләп үтәсе килә. Бу көннәрнең җентекләп уйланылган, кызыклы һәм бай программасы кыска вакыт эчендә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше, Муниципаль берәмлекләр Советы эше һәм Татарстандагы истәлекле урыннар тарихы белән танышырга мөмкинлек бирде.

Мари Эл Республикасы муниципаль бергәлеге исеменнән безнең Советлар арасында киләчәктә дә муниципалитетара хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшү дәвам итәр һәм бу, һичшиксез, Татарстан Республикасы белән Мари Эл Республикасы арасында дустанә һәм партнерлык мөнәсәбәтләрен ныгытыр һәм үстерер, җирле үзидарәне үстерүдә саллы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирер, дип өметләнәбез.

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советына ихлас күңелдән киләчәктә уңышлар һәм республикагызның муллыгын тәэмин итүгә юнәлтелгән барлык планнарыгызның гамәлгә ашуын телибез!




**Хөрмәтле коллегалар!**



**Всеволод БЕЛИКОВ, Санкт-Петербург Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе**

Санкт-Петербург Муниципаль берәмлекләре Советы һәм барлык муниципаль бергәлек исеменнән сезнең барыгызны да Татарстан Республикасында җирле үзидарә системасы эшли башлау һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы төзелүнең 10 еллыгы белән тәбриклим.

Халыкка иң якын һәм аңлаешлы булган җаваплы, көчле җирле хакимият гражданлык җәмгыяте һәм дәүләтнең тотрыклы үсеше нигезе, дип арттырусыз әйтеп була.

Татарстан Республикасында җирле үзидарә 10 ел эчендә оешу һәм үсешнең катлаулы юлын үтте, зур тәҗрибә туплады һәм республиканың сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тармакларында әһәмиятле көчкә әйләнде.

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы, җирле үзидарә органнары белән дәүләт хакимияте органнары хезмәттәшлегендә төп мәйданчыкка, барлык муниципаль бергәлек мәнфәгатьләрен кайгыртучыга әйләнеп, Татарстанда җирле үзидарә системасы үсешенә шактый өлеш кертте.

Сез Совет алдына куелган бурычларны нәтиҗәле һәм югары дәрәҗәдә үтисез: җирле үзидарә тармагында республика законнарын камилләштерү эшен башкарасыз, җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары һәм җәмәгать оешмалары белән бердәм хәрәкәт итү системасын үстерәсез, җирле үзидарә органнарының сайланып куелучы вазыйфаи затларын һәм муниципаль хезмәткәрләрне укытуны оештырасыз, территориаль иҗтимагый үзидарә системасын булдырасыз, җирле үзидарә органнарына мәгълүмати һәм методик ярдәм күрсәтәсез.

Советның тагын бер казанышы – 2015 елның 13 ноябрендә Казанда Муниципаль берәмлекләрнең гомумроссия конгрессы әгъзаларының гомуми җыелышын иң югары дәрәҗәдә үткәрүе.

Сез үзегезнең көндәлек эшегез белән Татарстан Республикасында иң катлаулы мәсьәләләрне дә иң югары нәтиҗәлелек белән хәл итәргә сәләтле файдалы җирле хакимият барлыгын күрсәтәсез.

Сезнең эш тәҗрибәгез Татарстан муниципаль берәмлекләре арасында гына таралып калмыйча, Россия Федерациясенең башка субъектлары җирле үзидарә органнары өчен дә уңай үрнәккә әйләнергә тиеш, дип саныйм.

Сезнең һәммәгезгә дә бетмәс-төкәнмәс энергия һәм илһам, яңа һөнәри казанышлар һәм уңышлар телим!



**Дмитрий СЛАВЕЦКИЙ, «Самара өлкәсе Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенең башкарма директоры**

**Хөрмәтле коллегалар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары!**

«Самара өлкәсе Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе әгъзалары сезне Татарстан Республикасы тормышындагы истәлекле вакыйга – Татарстан Республикасында җирле үзидарә системасы эшли башлау һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы төзелүнең 10 еллыгы белән тәбрикли.

Җирле үзидарәнең хәрәкәтләндергеч көче – ул, беренче чиратта, кешеләр, муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре. Аларның тырышлыгы, профессиональлеге, хезмәт сөючәнлеге һәм үз эшенә тугрылыгы нәтиҗәсендә территорияләр үсеш ала, яңа социаль, мәдәни, спорт объектлары төзелә, халык берләшә.

Татарстан Республикасы җирле үзидарәнең нәтиҗәле эшли торган системасын төзи һәм аның дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлеген тәэмин итә алды, бу халыкның шактый проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Тупланган тәҗрибә тирән хөрмәткә, ә кайбер аспектлар буенча РФнең башка субъектларында кабатлануга лаек.

Җирле үзидарәне үстерү мәсьәләләрендә алга таба да хезмәттәшлек итүгә өметләнәбез һәм ихластан барлык башлангычларыгызда уңышлар телибез!



**Николай ГОРШЕНИН, Ульяновск өлкәсе Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе**

**Хөрмәтле Минсәгыйть Закирович!**

Ульяновск өлкәсе Муниципаль берәмлекләре Советы һәм безнең төбәкнең муниципаль берәмлекләре исеменнән Татарстан Республикасында җирле үзидарә системасы эшли башлау һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы төзелүнең 10 еллыгы белән тәбриклим.

Бу елларда Совет җирле үзидарәне үстерүдә, муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын күтәрүдә һәм муниципаль берәмлекләрнең кадрлар потенциалын үстерүдә сизелерлек роль уйный башлады.

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы, башка төбәкләр муниципалитетлары белән муниципалитетара хезмәттәшлекне тәэмин итә торган орган сыйфатында, республикадан читтә дә танылу алды. Аерым алганда, республика Советы ярдәмендә Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы белән ТРның Спас районы арасында җирле үзидарә һәм ике якка да файдалы хезмәттәшлекне үстерүнең төп мәсьәләләре буенча тыгыз үзара бәйләнеш урнаштырылды.

Муниципаль берәмлекләр Советы туплаган тәҗрибә төп бурычны – Татарстанның һәр муниципалитетында яшәү сыйфатын күтәрүне хәл итүдә яхшы ярдәмче булыр, дип ышанам.



**Вячеслав ПРОСВЕТКИН, «Севастополь шәһәре Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе рәисе**

**Хөрмәтле коллегалар!**

«Севастополь шәһәре Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе исеменнән Татарстан Республикасында җирле үзидарә системасы булдырылуның 10 еллыгы уңаеннан ихлас тәбрикләүләребезне кабул итегез.

Җирле үзидарәнең роле һәм әһәмияте бик зур. Ул РФ конституцион төзелешенең бер баганасы гына түгел, социаль тотрыклылык һәм икътисадый үсеш нигезе дә. Россия Муниципаль берәмлекләре конгрессына кергәнлектән, Татарстан Республикасында булып, без шуңа кабат инандык. Сез ирешкән нәтиҗәләргә югары бәя биреп, без көн саен туып торган бурычларны хәл итүнең никадәр тырышлык, көч, уҗәтлек таләп иткәнлеген аңлыйбыз. Бүген, артка борылып карап, сез үткән 10 еллыкның үзегез өчен казанышлар һәм тормышка ашырылган планнар чорына әйләнүен күреп горурлана аласыз.

Сезнең тәҗрибәгез, һөнәри һәм оештыру потенциалыгыз Татарстан Республикасындагы гына түгел, бәлки бөтен Россиядәге җирле үзидарә органнары үсешенә ярдәм итсен.

Хезмәттәшлек һәм ярдәмчеллек өчен рәхмәт!

**Кадерле коллегалар, муниципаль берәмлекләр башлыклары!**

Сезне Татарстан Республикасында җирле үзидарә системасы эшли башлау һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы төзелүнең 10 еллыгы белән тәбриклим.

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы – Россия Федерациясендә иң алдынгылардан берсе. Муниципаль берәмлекләр Советының стратегик әһәмияттәге һәм кирәкле структура булуында без елдан-ел күбрәк инана барабыз. Совет хакимиятнең төрле баскычларының бердәм хәрәкәтен координацияли, проблемаларны ачыклау, тикшерү һәм аларны хәл итү юлларын эзләү мәйданчыгына әйләнә. Сезнең эшегез нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы һәм тулаем Россия Федерациясе муниципаль бергәлеге үсешенең аеруча мөһим проблемалары комплексы хәл итөлә.

Сезгә нык сәламәтлек, эшегездә уңышлар, якыннарыгызга бәхет һәм иминлек, шәһәр һәм авылларыгызда яшәүче халыкка муллык һәм тынычлык телим.



**Олеся ХАРИТОНЕНКО, «Кырым Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе рәисе**

---

**Хөрмәтле Минсәгыйть Закирович!**

Пермь крае Муниципаль берәмлекләре Советы исеменнән Сезне Татарстан Республикасында җирле үзидарә системасы эшли башлау һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы төзелүнең 10 еллыгы белән тәбриклим!

Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә системасы бүген югары нәтиҗәлелеге белән аерылып тора һәм уникаль уңышлы тәҗрибәгә ия. Бу күбесенчә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы казанышы.

Сез, Минсәгыйть Закирович, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары һәм депутатлары, Россия Федерациясендә җирле үзидарәне үстерүгә бәһаләп бетермәслек өлеш кертәсез.

Сезгә җирле үзидарәне үстерүдә яңа казанышлар һәм Татарстан Республикасын киләчәктә дә социаль-икътисадый яктан үстерүгә юнәлтелгән уңышлы карарлар кабул ителүен телибез!



**Александр КУЗНЕЦОВ, Пермь крае Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе**

---

**Кадерле коллегалар!**

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы оешуның 10 еллыгы уңаеннан ихлас тәбрикләүләребезне кабул итегез.

Татарстан Республикасы – Россия Федерациясенең динамик үсештәге субъекты ул, аның бай традицияләре, тормышның барлык тармакларындагы инновацияләре белән аерылып торган икътисадый культурасы бар.

Татарстан Муниципаль берәмлекләре Советы муниципаль бергәлектә мөһим роль уйный. Совет җирле үзидарәнең республиканың барлык муниципаль берәмлекләре халкы өчен иң актуаль булган мәсьәләләрен тикшерү өчен иҗтимагый мәйданчык булып тора.

Советның туплаган гамәли тәҗрибәсе, аның җирле үзидарә мәсьәләләре буенча төбәк һәм федераль законнар чыгаруга юнәлтелгән эшчәнлеге бәяләп бетергесез. Совет, тырышлыгын җирле үзидарәне ныгытуга юнәлтеп, территорияләрнең социаль-икътисадый үсешенә актив ярдәм итә. 10 еллык ул – гади юбилей гына түгел, бәлки эшкә нәтиҗә ясау һәм шул ук вакытта барлык муниципаль бергәлекне кайгыртуга юнәлтелгән яңа бурычларны билгеләү вакыты да.

Советның эш тәҗрибәсе куелган максатларга ирешергә, Татарстан Республикасы халкы бәхете өчен уңышлы заманча проектларны тормышка ашырырга ярдәм итсен!



**Юрий АЛПАТОВ, «Пенза өлкәсе Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе Идарәсе рәисе**

# Владимир ПУТИН: «Ачарга рөхсәт итәм!»






Фото www.tatarstan.ru сайтыннан

12 февральдә Чаллыга Россия Президенты Владимир Путин килеп китте. Төрле чараларга гаять бай бу кышкы кыска көндә дәүләт башлыгы Кама автозаводында беренче йөк автомобиле чыгарыла башлауның 40 еллыгына багышланган тантанада катнашты, Хәрби-сәнәгать комиссиясе утырышын үткәрде, ТРның Менделеевск районында урнашкан «Аммоний» АҖның яңа химия заводын ачарга видеоконференция режимында команда бирде, сәфәр азагында исә автокаладагы «Кванториум» балалар технопаркын карады.

Кама автозаводы конвейерыннан беренче йөк машинасы 1976 елның февралендә төшкән иде. Шул көннән бирле чаллылылар 2 миллион 173 меңнән артыграк машина җитештергән. Юбилей хөрмәтенә КАМАЗ хезмәткәрләре бәйрәм митингына җыелды. Заводта шәһәр турында чыгыш ясаганда, Владимир Путин: «Биредә яшәү өчен кирәкле шартлар һәм гаиләләр ишәйсен, балалар үссен өчен, искиткеч атмосфера тудырыла. Әмма завод шәһәрнең йөрәге булып кала. Бу дәвер эчендә күп нәрсә булды. КАМАЗ, дөньяда унберенче урынны биләп, үз тармагында әйдәп баручы предприятиеләрнең берсенә әйләнде. Ә илебездә исә йөк автомобильләре һәм йөк күчерүләр базарының 50 проценттан артыграгын нәкъ менә КАМАЗ алып тора. Бу бик шәп күрсәткеч, беренче!» – дип басым ясады.

Шул ук кичтә аммиак, метанол һәм бөртекләндерелгән карбамид җитештерә торган «Аммоний» комплексы эшләтеп җибәрелде. Владимир Путин: «Ачарга рөхсәт итәм!» – дип команда бирде. Предприятие җитәкчелегенә мөрәҗәгать итеп, Россия Президенты «Аммоний» төзүчеләрен «табигый газны эшкәртү буенча бик кирәкле, тулы цикллы зур предприятиене гамәлгә кертүнең беренче этабының» уңышлы төгәлләнүе белән котлады. «Бездә мондый предприятиеләрнең 1991 елдан бирле ачылганы юк иде. Һичшиксез, бу кирәкле проект, аның продукциясе төзелештә дә, авыл хуҗалыгында да, башка өлкәләрдә дә кулланылачак. Инвестицияләр дә саллы – 1,5 миллиард доллар, азиат партнерлар – кытай, япон инвесторлары, шулай ук Европа сәнәгать компанияләре вәкилләре белән дә кооперация шәп. Проектның беренче өлеше гамәлгә кертелде. Сезнең бу предприятиене үстерү планнарыгыз да булуын беләм. Сезне тәбрик итәсем һәм уңышлар телисем килә», – диде Владимир Путин.


1976
КАМАЗ № 000001
XXV съезду КПСС
КАМАЗ
001

# РЕСПУБЛИКА саннарда



**3 млн 868 кеше – 2016 ел башына Татарстанда шуның кадәр кеше яши.** Шуларның 2 млн 955 меңе шәһәрдә яши, 912 меңе авылда көн итә. 2015 елда Татарстанда халык саны 3 млн 861 мең кеше булган, шуның 2 млн 947 меңе – шәһәрдә, 914 меңе авылда яшәгән. Ел йомгакларыннан авылда яшәүчеләрнең саны кимүе, шәһәрдәгеләрнең артуы күзәтелә.



**56 мең 899 бала – 2015 елда республикада шуның кадәр бала туган.** Бу 2014 елгы белән чагыштырганда, 209га күбрәк. Туучылар саны ягыннан Татарстан Россия төбәкләре рейтингында – 16 нчы, Идел буе федераль округында беренче урынны били. Халыкның табигый артуы күрсәткече мең кешегә 2,7 кеше тәшкил иткән.



**34 млн тоннадан артыграк нефть – былтыр Татарстанда шуның кадәр кара алтын чыгарылган, 2014 ел белән чагыштырганда, 2,8 процентка күбрәк.** «Татнефть» компаниясе скважиналардан 27 млн тонна, кече нефть компанияләре 7 млн тоннадан артыграк алган. 2015 елда Россиядә 534 млн тонна нефть чыгарылган, ил буенча нефть табу үсеше 1,4 процент тәшкил иткән.



**17, 3 млн тонна – былтыр Татарстанның нефть эшкәртү заводларында шуның кадәр углеводород чималы эшкәртелгән** (республикада чыгарылган 34 млн тоннадан).



**1нче урын – 2015 елның гыйнвар-декабрь айларында Татарстан муниципаль берәмлекләренең социаль-икътисадый үсеше рейтингында Казан шундый уңышка иреште.** Икенче һәм өченче урыннарда – Әлмәт белән Түбән Кама районнары. 2015 елның гыйнвар-декабре рейтингында Әлки (+9 позиция), Мамадыш (+8 позиция) районнары позицияләрен ныгыткан. Уңай динамика авыл хуҗалыгында җитештерелгән тулай продукция күләменең үсеш тизлеге, төп капиталга инвестицияләрнең, торак йортларның гомуми мәйданы арту, теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе кимү белән бәйле.

**1,8 трлн сум – узган елда Татарстанның тулай төбәк продукты күләме шуның кадәрне тәшкил иткән.** Әлеге күрсәткеч 2014 елгы дәрәҗәгә туры килә (чагыштырма бәяләрдә). Шул ук вакытта сәнәгать җитештерүе күләме, 1,856 трлн сум тәшкил итеп, 0,4 процентка арткан. Машина төзелеше, резина эшләнмәләр җитештерү «артка тәгәрәгән», авыл хуҗалыгы һәм төзелеш алгарак киткән.



**28,5 мең сум – узган ел Татарстанда уртача хезмәт хакы шуның кадәр булган.** Татарстанлыларның реаль акча кереме 2015 елда 6,8 процентка кимегән, шул ук вакытта уртача хезмәт хакы 6,1 процентка арткан. Халыкның банкларга кертемнәре 30 процентка арткан. Ваклап сату әйләнеше 12,8 процентка кимегән.




**9нчы урын – 2015 елда Татарстан торак төзелеше күләме буенча РФ субъектлары арасында әлеге позицияне (2405,5 мең кв. м) били.**



**37,5 млн сум – узган елда ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, штрафлар күләме шуның кадәр сумма тәшкил иткән.** Янгынга каршы 38 мең чара үтәлергә тәкъдим ителеп, шуларның 99,7 проценты башкарылган. Узган ел эчендә министрлык республикада планлы рәвештә – 2,5 мең һәм планнан тыш 8,4 мең тапкыр тикшерүгә чыккан. Ведомство коллегиясендә 2015 елда кече һәм урта бизнес субъектларына карата административ йөкләнешнең кимүен билгеләделәр. Шулай итеп, планнан тыш тикшерүләр саны – 14 процентка, административ санкцияләр саны 10 процентка кимегән.



**60 миллионнан артыграк электрон хезмәт – былтыр Татарстан халкына шуның кадәр электрон хезмәт күрсәтелгән** (бер ел элекке белән чагыштырганда, 84 процентка күбрәк). Электрон түләүләр бер ел эчендә, ике тапкырдан да артып, 6,5 млрд сумга җиткән.





Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.
Андрей ТИТОВ фотолары.

# СТРАТЕГИЯ-2030: муниципаль дәрәҗәдә

2016 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫНДА ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ БЫЕЛ ҮЗЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШЫН УЗДЫРДЫ. ЭЛЕКТӘН КИЛГӘН ГАДӘТ БУЕНЧА, ЧАРА КИҢӘЙТЕЛГӘН ФОРМАТТА – ТР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ БАШЛЫКЛАРЫ УРЫНБАСАРЛАРЫ, РЕСПУБЛИКА МИНИСТРЛЫКЛАРЫ ҺӘМ ВЕДОМСТВОЛАРЫ ВӘКИЛЛӘРЕ КАТНАШЛЫГЫНДА, ВИДЕОКОНФЕРЕНЦИЯ РӘВЕШЕНДӘ ҮТКӘРЕЛДЕ, АННАН ТАТАРСТАННЫҢ БЕР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ДӘ ЧИТТӘ КАЛМАДЫ.

ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров үткәргән утырышта ТРның беренче вице-премьеры Алексей Песошин, ТР вице-премьеры – сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов, ТР икътисад министры Артём Здунов, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары Илнур Гарипов, Эшкуарлар хокукын яклау буенча ТР Президенты каршындагы вәкаләтле вәкил Тимур Ногманов һәм ТР дәүләт һәм муниципаль органнарының башка җаваплы хезмәткәрләре катнашты. Утырышта катнашучылар республика муниципалитетлары эшчәнлегенә бәйле, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының үзара хезмәттәшлегенә өлкәсен колачлаган берничә көнүзәк мәсьәләне карады.

Казан, Кама, Әлмәт агломерацияләре кысаларында, муниципалетитара мәйданчыклар төзүгә бәйле мәсьәлә буенча фикер алышканда, катнашучылар арасында кызу бәхәсләр куерды. ТР икътисад министры Артём Здунов чыгышында республика үсеше Стратегиясе-2030 кысаларында ТР муниципаль берәмлекләренең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен булдыру зарурияте билгеләп үтелде. Шул ук вакытта, әлеге документлар югарыда атап үтелгән агломерацияләрнең гомуми үсеше стратегияләрен исәпкә алып төзелергә тиеш, ягъни муниципалитетлар стратегияләренең үзләре кергән агломерацияләр кысаларында һәм бер-берсе белән килештерелеп башкарылуы таләп ителә. Стратегияләрдә чыганаклар









һәм хезмәт ресурсларын урнаштыру картасы, җитештерү тармаклары һәм әзер продукцияләрне, хезмәт күрсәтүләрне сату базарлары ачыкланган булуы мәҗбүри. Артём Здунов муниципалитетара хезмәттәшлек тиешле дәрәҗәдә оештырылган очракта гына көтелгән нәтиҗәләргә ирешеп булачагын ассызыклады. Министр шулай ук әлеге процесста проблемаларның күрше муниципаль берәмлекләрдә урнашкан көндәш җитештерү мәйданчыклары турындагы мәсьәләләрдән башланачагын искәртте. Татарстан көндәшлеккә ия төбәк булсын өчен, муниципалитетларда предприятиеләрне урнаштырганда, бер-берсенең мәнфәгатен истә тотып эш итәргә киңәш бирде.

Һәр муниципаль берәмлек үз стратегиясен булдырырга, шулай ук аны биш ел дәвамында гамәлгә ашыру чаралары планын корырга тиеш. Күп районнар мондый документларны әзерләү буенча эшкә керешкән инде. Икътисад министрлыгы муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен булдыру мәсьәләләре буенча үзәкләштерелгән консультацияләр үткәрүне тәкъдим итә. Артём Здунов, Татарстан территориясендә гамәлгә ашырылучы икътисадый программалар комплексын тулаем күздә тоткан хәлдә, әлеге документларны әзерләү процессын координацияләүнең кирәклегенә игътибарны юнәлтте. Ул утырышта катнашучыларга агломерацияләр белән идарә итү системасы проектын да тәкъдим итте.

ТР МБС Президиумы әгъзалары, утырышта катнашучылар чыгышларында муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләүдәге төп проблемаларга, көндәшлеккә ия җитештерү предприятиеләрен урнаштырганда муниципалитетлар арасындагы мәнфәгатьләрне көйләүгә карата төрле фикерләр яңгырады. Президиум әгъзалары агломерацияләр белән идарә итү мәсьәләләре буенча үз фикерен белдерде. ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров төрле карашларны чагылдырган чыгышларны йомгаклады, бүгенге сөйләшүгә бәйле барлык мәсьәләләр буенча, Икътисад министрлыгы һәм республика муниципалитетлары катнашлыгында, тагын бер мәртәбә җентекләп фикер алышырга тәкъдим итте. Президиум шулай ук муниципаль берәмлекләргә үзләренең социаль-икътисадый үсеше стратегияләрен гамәлгә ашыру буенча биш елга исәпләнгән планнар төзергә тәкъдим итте.

Ә аннан соң ТР МБС Президиумы әгъзалары дәүләт яисә муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрендә урнашкан стационар булмаган сәүдә объектлары эшчәнлеге тәртибенә бәйле мәсьәләләр, архитектура һәм дизайн өлкәсенә караган белгечләрне әзерләү проблемалары буенча фикер алышты.

Утырыш барышында Президиум әгъзалары ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров тәкъдиме буенча, ачык тавыш бирү юлы белән, ТР МБС рәисе урынбасарын сайлап куйды. Әлеге вазыйфага Алексеевск муниципаль районы башлыгы Владимир Козонков тәгаенләнде. Урынбасар сайлау ТР МБС Президиумы алдында торган бурычларның арткannан-арта баруы шартларында әлеге мәсьәләләрне тиз арада хәл итүгә булышырга тиеш.

Президиум ТР Муниципаль берәмлекләре Советы тарафыннан ел саен үткәрелеп килүче республика бәйгеләре нигезләмәсенә кайбер үзгәрешләр кертте.




Нияз ӘХМӘДУЛЛИН тексты.
Андрей ТИТОВ фотосы.

# СЕССИЯЛӘР йомгаклары буенча брифинг

ФЕВРАЛЬ АЕ РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕНЕҢ 2015 ЕЛГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ЙОМГАКЛАР ЯСАУ БЕЛӘН БИЛГЕЛӘНӘ. ТРАДИЦИЯ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛИТЕТЛАРНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШЕ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ АНАЛИЗ ЯСАП, ФИКЕР АЛЫШУ РАЙОН ҺӘМ ШӘҺӘР СОВЕТЛАРЫ СЕССИЯЛӘРЕНДӘ ҮТӘ. СЕССИЯЛӘР 3 ФЕВРАЛЬДӘ ТАТАРСТАННЫҢ АКСУБАЙ РАЙОНЫНДА БАШЛАНЫП КИТЕП, 29 ФЕВРАЛЬДӘ ЧИРМЕШӘН ҺӘМ ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫНДА ТӨГӘЛЛӘНДЕ.

Барлык сессияләр дә диярлек киңәйтелгән форматта узды: депутатлардан тыш, йомгак ясау эшендә иҗтимагый оешмалар вәкилләре дә – ТИҮләрнең, яшьләр һәм ветераннар оешмаларының җитәкчеләре, профсоюз эшлеклеләре, дин әһелләре катнашты. Татарстанның дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының үзара килешеп эшләвенең тагын бер үзенчәлеге – республика җитәкчеләре Советларның барлык сессияләрендә дә катнаша – ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов алты сессиядә, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин – ун, ТР Премьер-министры Илдар Халиков җидесендә катнашты, калган сессияләрдә ТР Премьер-министрының урынбасарлары булды. ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров шулай ук дистәдән артык сессиядә турыдан-туры катнашты.

1 мартта ТР Лаеш районының Комлы Кавал авылында журналистлар өчен брифинг булды, анда ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров һәм ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова Татарстан Муниципаль берәмлекләре Советының 2015 елдагы эшчәнлеге йомгакларына карата үз фикерләрен белдерделәр, агымдагы елның планнары турында сөйләделәр. Видеоконференция режимында брифингны республиканың 45 муниципаль берәмлегеннән күзәттеләр.

Брифингны ачып, Әсгать Сәфәров ММЧ вәкилләренә республиканың муниципаль берәмлекләрендә алып барыла торган күләмле эш турында сөйләде. Ул социаль-икътисадый үсеш рейтингында төп күрсәткечләр буенча муниципаль берәмлекләрнең позицияләрендәге үзгәрешләр динамикасына анализ ясады, урта һәм кече бизнесны үстерү, муниципаль сәнәгать мәйданнарын ачу, инвестицияләр җәлеп итү, миграцияне контрольдә тоту буенча муниципаллар алдында торган бурычларга тукталды. Журналистлар Татарстанда социаль-икътисадый үсешне тәэмин итүче 30дан артык программаның гамәлгә ашырылу нәтиҗәләре буенча иң соңгы мәгълүматлар белән таныштылар: юллар төзелешеннән алып, мәктәпләрне капиталь ремонтлауга кадәр. Әсгать Сәфәров быел күз



РФ Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан республикадагы иҗтимагый тотрыклыкны ныгыту кирәклегенә аерым басым ясап әйтте.

ТР Муниципаль берәмлекләре Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров, Советларның йомгаклау сессияләре җирле үзидарә органнарының эшчәнлеген алга таба планлаштыру өчен мөһим, дип билгеләде. Ул шулай ук Татарстанның авыл җирлекләрендә яшәүчеләрнең барысына да кагыла торган гражданнар җыеннары тәҗрибәсе турында да сөйләде, анда гражданнарның җирле хакимият эшчәнлеге турында тулы хисап белән таныша һәм үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алу мөмкинлегенә ия була. Ул халыкта «президентныкы» дип йөртелә торган өч дистәдән артык социаль-икътисадый үсеш программаларын тормышка ашыруның әһәмиятен ассызыклады. Программалар турында сөйләгәндә, Минсәгыйть Шакиров аларның кайберләренә тәфсилләп тукталды. Авыл җирлекләре Советлары биналарын капиталь ремонтлауны да үз эченә алачак программа агымдагы елда гамәлгә ашырыла башлаячак. Бу программа башлангычы белән былтыр Муниципаль берәмлекләр Советы чыккан иде. Тагын бер программа – үзара салым быел да дәвам иттереләчәк. 2015 елда референдумнар нәтиҗәләре буенча 122 миллион сум тирәсе акча җыелган. Финанслар белән ярдәм итү кысаларында республика бюджетыннан 488 миллион бүлеп бирелгән. Бу акчаларга муниципаль берәмлекләрдә авыл араларындагы юллар төзелә, территорияләр төзекләндерелә. Үзара салымның әһәмияте тагын шунда, дип ассызыклады Минсәгыйть Шакиров, конкрет хуҗалык мәсьәләләрен хәл итү белән бергә, территорияләр белән идарә итүгә кешеләр үзләре дә җәлеп ителә, кешеләр үзләре җыйган акча хисабына эшләнгән эшләргә саграк карый башлый.

Асылда, муниципаль берәмлекләрдә ТИҮләр барлыкка китерү һәм аларны үстерү буенча киң җәелдерелгән эш тә шушы ук максатларны күздә тота. Бүген Татарстанда 350 ТИҮ исәпләнә. ТИҮләр хәрәкәте үсешендә Әлмәт, Лениногорск, Чистай, Яр Чаллы алда бара. Әкренләп ТИҮләр Казанда да барлыкка килә, беренчеләрдән булып башкала чикләрендә – биредә 51 ТИҮ формалашкан.

Минсәгыйть Шакиров 2015 елдан башлап ТР МБСның ТИҮләрне кызыксындыру максатында бәйге оештыру башлангычын ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан хуплануына басым ясады. Бәйгенең гомуми бүләкләү фонды 40 миллион сум тәшкил итте. ТИҮ җитәкчеләре дә акчалата компенсация ала, бу исә эшкә стимул бирә. Алга таба ТР МБС җитәкчесе авыл җирлекләренә кагылышлы грантлар системасы турында җентекләп сөйләде. Ел саен иң яхшы 104 авыл муниципалитеты берәр миллион сумлык грант ала, ул акчалар урыннардагы кискен проблемаларны хәл итү өчен тотыла.

Советларның узган сессияләрен анализлап һәм муниципаль депутатлар корпусының елдан-ел үсә барган һөнәри дәрәҗәсен билгеләп, Минсәгыйть Шакиров депутатлар комиссияләренең эшен көчәйтү кирәклеге турындагы фикерен дә белдерде. Аның фикеренчә, аларның потенциалы тулысынча файдаланылмый. Муниципаль норматив актларны чыгару процессында канунннарны саклау проблемасына да кагылды ул. Узган елдан башлап, барлык документлар да прокуратура органнарында экспертиза үтә, шуннан соң гына муниципалитетларның вәкаләтле һәм башкарма органнары тарафыннан кабул ителә. Сүзен йомгаклап, Минсәгыйть Шакиров, Татарстанның дәүләт һәм муниципаль хакимияте уртак бурычларны хәл итү өстендә бергәләп эшли, төп бурыч – республиканың социаль-икътисадый үсеше аша татарстанлыларның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, дип ассызыклады.

ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова матбугат вәкилләренә парламент депутатларының муниципаль берәмлекләрдә урнашкан сайлау округларындагы эше турында сөйләде, муниципаль Советларның закон чыгару эшендәге кайбер башлангычларын билгеләде, җирле үзидарә үсешенең Татарстан хакимиятенең барлык тармаклары өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуына басым ясады.

Очрашу ахырында брифингта катнашучылар журналистларның сорауларына җавап бирделәр.



**Екатерина КУЛИКОВА тексты.**
**Фотолар автордан, һәм шулай ук «Яр Чаллы шәһәре» МБ матбугат хезмәтеннән алынды.**

# БАЛАЛАР *өчен удар төзелеш*

УЗГАН ЕЛ ЯР ЧАЛЛЫДА МЕҢНӘН АРТЫК САБЫЙ ЯҢА БАЛАЛАР БАКЧАСЫНА ЙӨРИ БАШЛАДЫ. ӘЛЕГЕ БАКЧАЛАР БАРЫСЫ ДА ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ КЫСАЛАРЫНДА ТӨЗЕЛДЕ. БАКЧАЛАРНЫҢ ҺӘРКАЙСЫ 240 УРЫНГА ИСӘПЛӘНГӘН. 6 МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ 2014 ЕЛНЫҢ ДЕКАБРЕНДӘ САЛЫНА БАШЛАГАН ИДЕ.

Узган елның июлендә берьюлы ике учреждение сабыйлар өчен үз ишекләрен ачты. Шуларның беренчесен – «Челнинская мозаика» балалар бакчасын – ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Үзенең чыгышында республика башлыгы балаларның һәркем тормышында иң кадерле кеше булуына басым ясады:

– һәр кеше өчен үз баласы зур байлык. һәм минем уйлавымча, әлеге байлык сезнеке генә түгел. Шәһәрнеке, республиканыкы һәм бөтен илебезнеке. Республикада демографик вазгыять уңай якка үзгәрә, һәм Чаллы бу яктан лидерлар арасына керә. Татарстан тарихында әлегә кадәр шундый кыска вакыт эчендә мондый сандагы балалар бакчалары төзелгәне юк иде әле.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен ачу тантанасында Рөстәм Миңнеханов, тиздән микрорайонда яңа мәктәп төзеләчәген әйтеп, анда яшәүчеләргә тагын бер шатлыклы хәбәрен җиткерде. Мәктәп монда күптәннән бик кирәк, шуңа күрә әлеге хәбәр көчле алкышлар белән кабул ителде.

«Челнинская мозаика» төзелеше удар темплар белән барды. Төзүчеләр объектны бары тик ярты ел эчендә сафка бастырдылар. Учреждениедә медицина блогы, психолог, туган телне өйрәнү кабинеты, музыка һәм спорт заллары, сенсорлы бүлмә һәм бассейн бар.

Ачылыш тантанасында катнашкан кечкенә Алисәнең әнисе Айгөл Гришина кызын бакчага алай иртә йөртә башларга уйламаган булуын әйтте:

– Мәгариф идарәсендә ачылыш сентябрь-октябрь айларында, дип әйткәннәр иде. Мин көзгә кадәр бакчага китәрбез дип уйламаган да идем, шуңа күрә мондый хәбәрне ишетү бик күңелле булды.

Июль башында Яр Чаллыда тагын бер бакча – «Миләүшә» нәниләрнең шат авазларына күмелде, анысы ЗЯБ бистәсендә ачылды. Ачылыш тантанасында катнашкан ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов ба-

**Элегрәк, ди әнисе, малай татарча исәнләшә генә белә иде, ә хәзер әти-әнисе һәм тәрбиячеләрнең генә түгел, шәһәрнең дә горурлыгына әйләнгән. Декабрьдә Нияз татар теле буенча шәһәр конкурсында катнашкан һәм икенче урынны алган. «Яблочко» балалар бакчасына йөри башлаганнан бирле (узган елның сентябреннән), Нияз Ситдыйков төрле 5 дипломга лаек булган.**



«Челнинская мозаика» балалар бакчасының тантаналы ачылышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

лалар бакчаларын төзү буенча 2013 елда башланып киткән өчьеллык республика программасы темасына кагылды. Нәкъ менә әлеге программа нәтиҗәсендә Татарстанда, аерым алганда, Яр Чаллыда, яңа мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре төзелә дә инде. Соңгы елларда республика Хөкүмәте каршында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балалар өчен 30 меңнән артык яңа урын булдыру кебек мөһим бурыч торды. Бу максатларга 2014 елда республика бюджетыннан – 4 миллиард сумнан артык, 2015 елда 5 миллиард сумнан артык акча бүленде.

Бүген яңа федераль стандарт шуны күз уңында тота: балалар бакчалары сабыйларның талантын ачу, белем үзләштерә башлау урыны булырга тиеш.

– Баланың таланты һәм сәләте 7 яшькә кадәр ачыла. Без аларга ике дәүләт теле – татар һәм рус телләрен өйрәтергә тиеш. Моннан тыш, инглиз теленә өйрәтү дә комачауламас иде, шулай ук балаларны гомуми башлангыч белем алуга психологик яктан әзерләү дә кирәк. Бүген тәрбиячеләр алдына менә шундый бурычлар куела, – дип билгеләп үтте Энгель Фәттахов.

Чират буенча өченче булып «Звездочки» балалар бакчасы ачылды. Тантанада шәһәр мэры Наил Мәһдиев катнашты. Ул республика ярдәме нәтиҗәсендә Чаллыда өч яшьтән зуррак балаларны бакчада урын белән тәэмин итүнең кискенлеге кимүенә басым ясады.

– Без хәзер яшь планкасын яшь ярымга кадәр киметә алабыз, – диде шәһәр башлыгы, 13 комплекста яшәүчеләрне әлеге көтеп алынган шатлыклы вакыйга белән котлап. Ә вакыйга чыннан да көтеп алынган, чөнки, бакча булмау сәбәпле, моңа кадәр әти-әниләргә сабыйларын күрше комплексларда урнашкан балалар бакчаларына йөртергә туры килә иде.

Сентябрьнең беренче яртысында Чаллы шәһәрендә тагын ике балалар бакчасы кулланугa тапшырылды: 58 комплекста – «Уенчык» һәм 65 комплекста – «Яблочко». Бәләкәй Ниязның әнисе Лилия Ситдыйкова «Яблочко» балалар бакчасы ачылуга куанып бетә алмый:

– Бу бакчага күчүебез белән мин бик канәгать, биредә менә дигән тәрбиячеләр эшли, рәхәтләнеп, бик теләп йөрибез, – ди ул.

Быел Нияз инде мәктәпкә бара икән. Лилия ханым сөйләвенчә, әлеге бакчага йөри башлаганнан бирле, малай күзгә күренеп үзгәргән. Элегрәк, ди әнисе, малай татарча исәнләшә генә белә иде, ә хәзер әти-әнисе һәм тәрбиячеләрнең генә түгел, шәһәрнең дә горурлыгына әйләнгән. Декабрьдә Нияз татар теле буенча шәһәр конкурсында катнашкан һәм икенче урынны алган. «Яблочко» балалар бакчасына йөри башлаганнан бирле (узган елның сентябреннән), Нияз Ситдыйков төрле 5 дипломга лаек булган.

Кечкенә Амелиянең әнисе Светлана Халикова да кызының уңышларын күреп сөенә:

– Кызым бик аралашучан түгел, сөйләшергә яратмый, бигрәк тә олылар белән авыр аралаша, ә биредә ул бөтенләй үзгәрде. Гадәттә бөрәр нәрсәне эшли алмый икән, ул йомыла, кәефсезләнә, ә монда тәрбиячеләр

ярдәме белән Амелия уңайга үзгәрә, үсә башлады.

Әгәр элегрәк 5 яшьлек Амелияне бакчага илтү өчен җайлап уятырга һәм озак итеп җыендырырга, көйләргә кирәк булган булса, хәзер бала «Яблочко»га бик теләп бара. Мондый уңай үзгәрешләрне әти-әниләр тәрбиячеләрнең балаларга булган мөнәсәбәтенә бәйләп аңлаталар. Төркемдә барлыгы 16 бала тәрбияләнә, тәҗрибәле педагогларның игътибары һәр балага да җитә.

– Башка учреждениеләрдә төркемгә 20дән артык бала йөри. Тәрбиячеләрнең һәр балага көче дә, вакыт да җитми, – дип өсти Светлана Халикова.

Балаларына шундый игътибарлы мөнәсәбәт өчен, ата-аналар балалар бакчасы мөдире Зөлфия Юзекаевага рәхмәтле.

«Яблочко» балалар бакчасын педагоглар составының көчле булуы аерып тора, бу мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе җитәкчесе туплаган коллектив. Әйтик, татар телен өйрәнүдә балалар ирешкән уңышлар өчен, әти-әниләр татар теле укытучысы, югары категорияле тәрбияче Асия Хуҗинага рәхмәтләрен белдерәләр. Дзюдо буенча дөнья чемпионкасы, Европа призеркасы, Россия беренчелегендә берничә мәртәбә призлы урын яулаган дзюдо һәм самбо буенча спорт остасы Регина Капаева шулай ук әлеге учреждениенең горурлыгы булып тора. Бакчада әлеге спорт төре белән шөгыльләнергә теләүчеләр бик күп. Бу дәресләр балаларны физик яктан чыныктыра, аларда максатчанлык, ныклы холык тәрбияли, агрессиягә дә урын калмый.

– Бу – бик матур, көчле, кызыклы спорт төре. Күнегүләр вакытында балалар бергәләшеп, парлашып эшләп, нәтиҗәгә ирешергә өйрәнәләр, бер-берсенә булышалар, аларның көче-егәре арта. Тискәре эмоцияләр җыелган булса да, спорт залында дәресләрдән һәрвакыт рәхәт, җиңел булып кала, – ди Регина Капаева.

Балалар агрессиясе темасына кире кайтып, шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: «Яблочко» балалар бакчасы психологы мондагы балаларның үз-үзләрен тотышында агрессиянең булмавын әйтә. Белгечне күбрәк соңгы вакытларда еш күзәтелә торган сөйләм теле үсешендә артта калу борчый. Моннан тыш, Земфира Фәйрушина балаларда вак моториканың җитәрлек дәрәҗәдә үстерелмәгән булуын да әйтеп үтте. Балалар бакчасында әлеге проблеманы хәл итү юнәлешендә эшлиләр, биредә махсус адаптация төркемен ачарга планлаштыралар.



«Уенчык» балалар бакчасы үз ишекләрен узган ел ахырында ачты.

**2015 елда Яр Чаллыда барлыгы 1440 урынлы 6 балалар бакчасы сафка бастырылган. Алдарак бары тик 3 бакча төзү генә каралган булган, ләкин республика ярдәме нәтиҗәсендә әлеге санны ике мәртәбәгә арттыру мөмкинлеге туган. Әлеге объектларны салу өчен, 900 миллион сумга якын акча бүленгән. Бүгенге көндә шәһәрдә балалар бакчаларына чират юк диярлек, элегрәк төзелгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хисабына 9500 мең бала бакчада урын белән тәэмин ителгән. 2014 елда 2190 урынлы 8 бакча ачылган булган.**

Татар теленнән тыш, бакчада инглиз телен дә өйрәнәләр. Дәресләр тел мохитенә кереп китеп өйрәнелә. Балалар бакчасының 3 ай эшләве дәверендә анда тәрбияләнүчеләр төрле уңышлары өчен 50дән артык дипломга лаек булганнар. Бәләкәй чаллылылар татар телен өйрәнүдә генә түгел, башка өлкәләрдә дә уңышка ирешәләр. Музыка, шахмат, биюләрдә иң яхшылар рәтенә күтәрелүдә аларга тәҗрибәле укытучылар булыша, биредә шөгыльләнү өчен, башка балалар бакчаларыннан да күчәргә теләүчеләр күп икән.

Бакчада эшләүче хезмәткәрләр дә үз тәрбияләнүчеләреннән артта калмыйлар. Шәһәр балалар бакчалары персоналы арасында җиңел атлетика буенча үткән ярышларда тәрбиячеләр беренче урынны алган, ә волейбол турнирында өченче урынга лаек булган. Балалар бакчасының өлкән шәфкать туташы Надежда Птицынаның шигырьләре «Талантлы шәһәр» дип аталган шәһәр конкурсында билгеләнеп үтелгән.

Төзүчеләргә карата Зөлфия Юзекаеваның бернинди дә дәгъвасы юк. Нинди дер хилафлыклар, җитешсезлекләр ачыкланган очракларда, аларны «Евростиль» компаниясе тиз арада төзәтә.

2015 елда ачылган иң соңгы балалар бакчасы – «Кроха», ул Мәләкәс аръягы микрорайонында урнашкан. Әлеге балалар учреждениесе үзенең ишекләрен 7 октябрь көнне ачкан. Ачылыш тантанасында, балалар һәм аларның әти-әниләреннән тыш, төзүчеләр үзләре һәм мэрия хезмәткәрләре катнашкан.

Үзенең чыгышында шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Абдуллин, шәһәрдә ачылган барлык балалар бакчалары да иң югары таләпләргә җавап бирәләр, балаларга уңай булсын өчен, алар бар нәрсә белән дә җиһазландырылган,



«Кроха» балалар бакчасында.

**«Яблочко» балалар бакчасын педагоглар составының көчле булуы аерып тора, бу мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе җитәкчесе туплаган коллектив. Әйтик, татар телен өйрәнүдә балалар ирешкән уңышлар өчен, әти-әниләр татар теле укытучысы, югары категорияле тәрбияче Асия Хуҗинага рәхмәтләрен белдерәләр. Дзюдо буенча дөнья чемпионкасы, Европа призеркасы, Россия беренчелегендә бернichә мәртәбә призлы урын яулаган дзюдо һәм самбо буенча спорт остасы Регина Капаева шулай ук әлеге учреждениенең горурлыгы булып тора.**

дип билгеләп үтә. Ул шулай ук иң кыска срокларда – бары тик 7 ай эчендә әлеге учреждениене сафка бастырган төзүчеләргә рәхмәтен белдерә.

«КамГЭСэнергострой» ААҖ гендиректоры урынбасары Сергей Ямашев бакча мөдиренә символик ачкыч тапшырганда төзүчеләргә бизәү эшләрен төгәлләүдә булышкан тәрбиячеләргә рәхмәтен белдерә.

Башка балалар бакчалары кебек үк, «Кроха»да да йөзү бассейны бар, аерым медицина кабинеты булдырылган. Су үзенең составы буенча эчә торганга якын: су ультрафиолет аша үткәрелә һәм кислород белән баетыла, анда хлор юк.

2015 елда Яр Чаллыда барлыгы 1440 урынлы 6 балалар бакчасы сафка бастырылган. Алдарак бары тик 3 бакча төзү генә каралган булган, ләкин республика ярдәме нәтиҗәсендә әлеге санны ике мәртәбәгә арттыру мөмкинлеге туган. Әлеге объектларны кору өчен 900 миллион сумга якын акча бүленгән. Бүгенге көндә шәһәрдә балалар бакчаларына чират юк диярлек, элегрәк төзелгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хисабына 9500 мең бала бакчада урын белән тәэмин ителгән. 2014 елда 2190 урынлы 8 бакча ачылган булган. Шулай итеп, соңгы ике елда гына да шәһәрдә 3630 өстәмә урын булдырылган. Меңнән артык кеше эш урыны белән тәэмин ителгән.

Чаллыда уңышлы тормышка ашырылучы тагын бер республика программасы – «Авыл клублары». Әйтик, 2015 елның 10 сентябрендә «Прибрежный» микрорайонында күпфункцияле үзәк ачылган. Тантаналы бәйрәм чарасы шәһәр мэры Наил Мәһдиев катнашлыгында узган: «Биредә чыршы бәйрәмнәре, микрорайонда яшәүчеләр белән очрашулар оештырырга була. Күпфункцияле үзәк янәшәсендә генә бик матур сквер ясадык, микрорайон территориясе бөтенләй үзгәрде», – ди ул, җыелган халыкка мөрәҗәгать итеп.

Бүген клуб белән идарә итү «Эврика» Шәһәр мәдәни үзәге» Муниципаль автоном мәдәният учреждениесенә тапшырылган. Әлеге үзәк эшчәнлегенең төп юнәлешләре – клублар эшен оештыру, мәдәни массакүләм чаралар, концертлар оештыру һәм уздыру. Биредә төрле кызыксыну юнәлешләре буенча 15 клуб һәм студия эшли: 9ы – балалар һәм яшүсмерләр өчен, 6сы яшьләр һәм өлкәннәргә карый.

Күпфункцияле үзәккә төрле яшьтәге халык йөри. 1 яшьтән зуррак балалар белән тәҗрибәле педагоглар шөгыльләнә, бераз олыраклар өчен цирк бүлеге, хореография студиясе, каратэ секциясе һ.б. эшли. Өлкәннәр аэробика белән шөгыльләнә алалар, шулай ук төрле кызыксынуларны үз эченә алган клублар да ачылган: «Безнең бакча», «Гаилә учагы», сәламәтлекләре чикләнгән кешеләр өчен «һәрвакыт бергә» төркеме төзелгән.

Бүгенге көндә үзәккә 500гә якын кеше йөри. Тик барлык теләге булганнарны кабул итү өчен урыннар җитеп бетми.

– Авыллардагыга караганда, бездә мөмкинлекләр күбрәк, ләкин урын җитми, тыгызрак, – дип сөйли «Эврика» үзәге директоры Ландыш Галиева.

Мисалга, робот техникасы буенча дәресләргә 20гә якын кешене йөртү мөмкинлеге бар. Балалар ике төркемгә бүленгән: кече – 1–2 сыйныфлар, өлкән – 3–5 сыйныфлар. Учреждение директоры билгеләп үткәнчә, күбрәк баланы кабул итү өчен бүлмәләр җитешми: – 15, 20 баланы чакырырга була, тик кысанрак, балаларга кызык булмаячак.

Укытучы Альберт Закиров үзенең укучыларыннан бик канәгать, балалар гамәли фәннәргә тартыла. «Балаларның уңышлары шактый. Алар робот техникасы белән генә шөгыльләнмиләр, электрика нигезләрен дә үзләштерәләр», – ди остаз.

Республика ярдәме нәтиҗәсендә шәһәрдә социаль әһәмияттәге объектларны төзү бүген дә бара, шулай да мәктәпләргә зуррак игътибар күрсәтелә. Хәзерге вакытта 37 комплекстагы белем бирү учреждениесен төзү удар темплар белән алып барыла. Аның ачылышы 1 сентябрьгә планлаштырылган. Әлеге бурычны һәм срокны чаллылылар алдына Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов куйды.



**38 мең 300 км – республикада гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары челтәренең озынлыгы шуның кадәр,** шул исәптән 27 мең 400 км юл – каты өслекле. 2015 елда ТРнда юл төзү эшләрен финанслауның гомуми күләме 27,2 млрд сум тәшкил иткән.



**36 млрд 100 млн сум – 2015 елда республикада юл-транспорт комплексы шул күләмдә финансланган.** Республика бюджетыннан – 25 млрд 50 млн сум, федераль бюджеттан – 10 млрд 31 млн сум, Моношәһәрләрне үстерүнең федераль фондыннан – 408,5 млн сум, муниципаль юл фондыннан 682,7 млн сум бүлеп бирелгән.




**597 млрд сум – 2015 елда Татарстанда төп капиталга шуның кадәр инвестицияләр кертелгән.** Тулаем алганда, төп капиталга инвестицияләр кертү күләме буенча Татарстан Идел буе федераль округында – беренче, Россиядә беренче өчлеккә керә. Узган ел республикага чит илләрдән 812 млн долларлык инвестиция җәлеп ителгән, шуларның турыдан-туры чит илләрдән кертелгәне – 482 млн доллар.



**2, 4 млрд сум – ел саен республика башкаласын төзекләндерүгә Казан бюджетыннан шуның кадәр акча бүлеп бирелгән.** Әлеге сумманың төп чыгымнары гадәттәгечә юл челтәрләрен, юлларны, күперләрне, транспорт һәм җәяүлеләр өчен объектларны карап тотуга, яшеллек, фонтаннар һ.б. өчен киткән.



**30 мең 572 гаилә – Татарстанда быелтыр шулкадәр пар теркәлгән,** бу сан, аннан алдагы ел белән чагыштырганда, 6,1 процентка кимрәк.


**349 меңнән артыграк кеше 2015 елда борынгы Болгарны барып күргән** (2014 елда – 285 мең кеше). Свияжск утрау-шәһәре 261 меңнән артык кешене кабул иткән (2014 ел йомгаклары буенча –182 мең кеше).



**Турист кесәсеннән чыккан 1 сумның, чиктәш тармакларның мультипликатив эффектын да санаганда, 43 тиене Татарстан бюджетына тама.** ТР Туризм буенча дәүләт комитетының йомгаклау коллегиясендә шушындый сан яңгырады.




**11,3 млрд сум – 2015 елда туризм өлкәсендә күрсәтелгән хезмәтләрнең күләме шуның кадәр бәяләнә, бу чиктәш тармакларны исәпкә алмаганда.** Бу 2014 ел белән чагыштырганда, 12,8 процентка күбрәк. Әлеге күрсәткечкә туристларның яшәгән, экскурсия һәм шифаханә-сәламәтләндерү өчен киткән чыгымнары керә. Шул ук вакытта туризм тармагының гомуми әйләнеше ел йомгаклары буенча 18,4 млрд сум тәшкил иткән.



**154,1 мең кеше – Федераль миграция хезмәтенең ТР буенча Идарәсе мәгълүматларына караганда, 2015 елда чит илләрдән килгән.** 2014 елда чит ил кунаклары 145,9 мең кеше булган. Татарстанга иң күбе Төркия, Кытай, Германия, АКШ һәм Франциядән киләләр.




**4,2 млн кеше – 2015 елда Татарстан музейлары шулкадәр халыкны кабул иткән.**





# КРИЗИСКА каршы инвестицияләр

12 февраль көнне ТР Премьер-министры Илдар Халиков парламент тыңлауларында катнашты һәм Россия Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары каршында чыгыш ясады. Тыңлаулар РФ Федераль Җыены, РФ Хөкүмәте һәм Россия Банкының илдәге икътисадый үсешне тәэмин итү буенча беренче чираттагы чараларын тикшерүгә багышланган иде. РФ Хөкүмәте, РФ субъектлары вәкилләре, әйдәп баручы экспертлар икътисадый вазгыять үсешенең төрле сценарийларын тикшерде, икътисадны тотрыклыландыру чараларын анализлады.

Татарстан Хөкүмәте җитәкчесе Илдар Халиков үз чыгышында үткән елда Кризиска каршы планны гамәлгә кертү нәтиҗәләре турында тәфсилләп сөйләде. Аның кысаларында гамәлгә кертелә торган проектлар республика икътисадына таяныч булган. «Татарстан потенциалны саклап кала һәм елны лаеклы төгәлли алды, – диде ул. – Исәпләүләр буенча, республика тулай төбәк продукты 2014 елгы бәяләр дәрәҗәсендә сакланды. Сәнәгатьтә аз булса да – 100,4 процентка – үсеш күзәтелә, авыл хуҗалыгында да уңай динамика теркәлде».

Илдар Халиков әйтүенчә, Татарстан төп капиталга инвестицияләр күләмен саклап кала алган.

«Шул ук вакытта төбәкләр бүген катлаулы шартларда яши, – дип белдерде ТР Премьер-министры. – Республиканың агымдагы елга бюджеты 5,8 миллиард сумлык дефицит белән кабул ителде. Беренче чираттагы һәм социаль әһәмияткә ия чыгымнар арта, алар инде бюджет чыгымнарының тулаем күләменең 74,7 процентын тәшкил итә. Шунлыктан федерация субъектларына федераль үзәкнең хуплавы бик мөһим. һәм бүген без икътисадның перспективалы үсеш нокталары сыйфатында инфраструктура объектлары үсешен күрәбез. Бу бизнесны формалаштыру, яңа эш урыннары булдыру өчен нигез булып тора».

Уңай мисаллар арасында Илдар Халиков махсус икътисадый зоналар үсешен атап китте. Мәсәлән, «Алабуга» махсус икътисадый зонасында 48 компания-резидент урнашкан, зур инвестицион проектлар гамәлгә кертелә, 5,5 мең эш урыны булдырылган. Тышкы факторларга карамастан, былтыр «Алабуга» МИЗ территориясендә 6 яңа завод ачылган, шул исәптән – чит ил партнерлары катнашлыгында.

Икътисадның төп «үсеш нокталарыннан» Татарстан Премьер-министры шулай ук индустриаль парклар, технопарклар, бизнес-инкубаторларны да атады.

Илдәге икътисадый үсеш перспективаларына Татарстан күзлегеннән бәя биреп, ТР Премьер-министры бүген төбәкләрдә инфраструктура проектлары үсешен алга таба да саклау бигрәк тә мөһим дигән ышанычын белдерде. Инфраструктурага инвестицияләр – бер үк вакытта күп кенә чиктәш тармакларга ярдәм дә ул, нәтиҗәдә икътисад куәтләнә генә бара.



Фото www.tatarstan.ru сайтыннан


04:19
ДЕРАЛЬНОЕ СОБРАНИЕ
ССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
УДАРСТВЕННАЯ
ДУМА

# ДӘВАМЫ булачак



Арчада Җиңүнең 70 еллыгы паркы.



Татарстан башкаласында яңартылган Лядской бакчасы.



Казанда «Континент» паркы.




2015 елда Яр Чаллыда 9 парк һәм сквер төзекләндерелде.





Парк һәм скверларны төзекләндерү бюджеты 1 млрд сумны тәшкил итте.



Узган ел Татарстанда 140тан артык ял зонасы барлыкка килде, күбесе икенче сулыш алды.

Фото www.tatarstan.ru сайтыннан

Былтыр шәһәр һәм авылларыбызда, күзләрне сөендереп һәм һаваны сафландырып, кислород белән туендырып, күпсанлы яшеллек: парк зоналары һәм кечкенә скверлар пәйда булды. Кайдадыр фонтаннар эшли башлады, кайбер урыннарны скульптура композицияләре бизәде, кайдадыр хуш исле чәчәк түтәлләре белән әйләндереп алынган балалар мәйданчыклары үсеп чыкты – төрле җирдә төрлечә, әмма кеше кайда гына яшәмәсен – бистәме, яки шәһәрчекме, яисә сәнәгать мегаполисымы ул – бу һәркемгә сөенеч. Табигать почмакларының, сәйран кылу һәм ял итү урыннарының артуы куандыра. Кайбер җирләрдә моңа кадәр бер кечкенә бакча да булмавын исәпкә алсаң, бигрәк тә.

Татарстанда рәсми рәвештә Парклар һәм скверлар елы дип игълан ителгән 2015 елда 140ка якын яңа объект төзелгән һәм төзекләндерелгән. Әлеге максатларга республика бюджеты 1 миллиард сум акча бүлгән, меценат һәм инвесторлар тагын 600 миллион сум өстәгән. Бу программага багышланган матбугат конференциясендә ТР Президенты ярдәмчесе Наталья Фишман йомгак ясап әйткәнчә, халыкның ял итү урыннарын төзекләндерү буенча Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан кала, илдә башка беркайда да Казандагы кадәр эш алып барылмаган.

Казан парк һәм скверларында гына да 700 яфраклы һәм ылыслы агач, 6,5 меңнән артыграк куак утыртылган, 1 меңнән артык яңа эскәмия куелган, 1,5 меңнән артык яңа фонарь эленгән һ.б. Казаннан тыш, Татарстан районнарында да зур эш алып барылган. Сүз уңаеннан, муниципаллар арасында бу өлкәдә иң яхшы нәтиҗәне Түбән Кама, Мөслим, Әлмәт, Саба, Лениногорск, Яшел Үзән, Актаныш, Зәй һәм Бөгелмә районнары күрсәткән.

Әйе, Парк һәм скверлар елы тәгәлләнде, әмма башланган программаны гамәлгә кертү киләчәктә дә дәвам итәчәк. Бу максатларга республика бюджетыннан тагын 1 миллиард сум акча бүленгән. Татарстан җирендә быел да меценат һәм хәйриячеләр дә табылмый калмас, дип ышанырга була. 2016 елда Татарстан Республикасында Су саклау зоналары елына бәйле яңа программа чараларына да 1 миллиард сум акча бүленәчәк.

Татарстанда үткән ел азагында карар кылынганча, Су саклау зоналары елы программасын гамәлгә кертүгә акча бүлү критерийларыннан берсе булып муниципаль берәмлекләрнең Парк һәм скверлар елы программасы рейтингындагы урыны торачак. Ягъни 2015 елда эш нәтиҗәлелеге ягыннан алдынгылык яулаган районнарга Су саклау зоналары елы программасы кысаларында акча алуга өстенлекле хокук биреләчәк.



**Людмила КАРТАШОВА тексты.**
**Фотолар ТР Экология министрлыгы архивыннан алынган һәм авторныкы.**

# ТЫКШЫНУ *бәһасе*

СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ ДӘҮЛӘТ СТРУКТУРАЛАРЫНЫҢ ҖИРГӘ КАГЫЛГАН ЗАКОННАРНЫҢ ҮТӘЛЕШЕНӘ ИГЪТИБАРЫ АРТТЫ, БИГРӘК ТӘ КАРЬЕРЛАР КАЗУ ТАРМАГЫНДА. БИК КҮП ХАЛЫК ҖИР АСТЫНДАГЫ ФАЙДАЛЫ КАЗЫЛМАЛАРНЫҢ КҮЛӘМЕ ТЕЛӘСӘ КЕМ ҺӘМ ТЕЛӘСӘ КҮПМЕ, ҖИТМӘСӘ ӘЛЕ БУШЛАЙ ЧЫГАРЫРЛЫК ДИП УЙЛЫЙ. МОНДЫЙ НАДАНЛЫК ЭЗСЕЗ ҮТМИ – «КЫРГЫЙ» КАРЬЕРЛАР ДИСТӘЛӘРЧӘ ЕЛ БУЕ ҖИР ӨСЛЕГЕНДӘ ТӨЗӘЛМӘС ҖӘРӘХӘТ БУЛЫП СЫКРАП ЯТА. ҖИР АСТЫ ТӨПСЕЗ ТҮГЕЛ ШУЛ: КАЗЫЛМА БАЙЛЫКЛАРДАН ДӨРЕС ҺӘМ БӘРӘКӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН, ДӘҮЛӘТНЕҢ КЫРЫС КОНТРОЛЕ КИРӘК. ЯГЪНИ КАЗЫЛМАЛАРНЫ ЧЫГАРУЧЫЛАРНЫҢ ЛИЦЕНЗИЯЛӘРЕ БУЛУ ЗАРУР. ӘГӘР УЛ ЮК ИКӘН, ДИМӘК, ФАЙДАЛЫ КАЗЫЛМАЛАРНЫ ЧЫГАРУ ЗАКОНСЫЗ АЛЫП БАРЫЛА.

### «КАРА КАЗУЧЫЛАР» ИРКЕНЛӘП ЭШ ИТӘ

Бу мөһим тема Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең ТР буенча Идарәсе йомгаклау коллегиясенең быел гыйнварда Казанда үткән берләштерелгән утырышында тикшерелде. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте җитәкчесе Артем Сидоров, Идел буе төбәкара табигать саклау прокуроры Вениамин Селифанов катнашты. Татарстан муниципаль районнары башлыклары да коллегия эшендә актив булды. Һәм бу мантыйкка ярашлы да – бирелә тикшерелгән мәсьәләләрнең күбесе муниципалитетларга турыдан-туры кагыла, алай гына да түгел, уртак утырыш беркетмәсендә нәкъ менә муниципаль органнарга йөкләнәчәк шактый бурыч билгеләнгән. Алар арасында, мәсәлән, муниципаль берәмлек мөлкәте саналган гомумкуллану су объектларына һәм аларның яр буйларына гражданнарның ирекле керүен тәэмин итү дә бар. 2017 һәм аннан соңгы елларга җирле бюджетларны формалаштырганда муниципаль дәрәҗәдәге җитәкчеләр

**Соңгы өч елда Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы Татарстанда җир кишәрлекләрен карьерлар эшкәртү максатыннан кулланганда 900дән артык закон бозу очрагын теркәгән, салынган штрафлар күләме 35 миллион сумнан арткан. Бүген республикадагы «кыргый карьерлар» базасына 600дән артык участок кертелгән.**

## КАРЬЕРЛАРНЫ РЕКУЛЬТИВАЦИЯЛӘҮ

Татарстан Республикасы буенча

**105**
карьер

**108,33**
гектар




## КАРЬЕРЛАРДАН ЗАКОНСЫЗ ФАЙДАЛАНУ БЕЛӘН КӨРӘШ



бюджетка файдалы казылмалар чыгарудан кергән салым акчаларын бары тик максатчан гына – табигатьне саклау чараларына, шул исәптән ташландык карьерларны рекультивацияләүдә файдаланырга тиеш.

Карьерлардан законсыз файдалануда вазгыятьне ничек үзгәртергә, кагыйдә бозучыларга каршы көрәшне нинди ысуллар белән көчәйтергә? Нәтиҗәле чаралардан берсе – заманча мәгълүмати технологияләр. Республикада җир асты байлыкларына кагылышлы белешмәләрне бердәм исәпкә алу геомәгълүмат системасы уңышлы эшли. Мәгълүматлар базасына барлык хокук саклау һәм күзәтү органнары керә ала. Экология министрлыгы хезмәткәрләре, прокуратура һәм Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, тикшерүләр үткәрә, дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча даими төркем эшли. Үткән ике елда лицензия килешүләрен бозу очраклары дүрт тапкырга арткан: 2013 елда 11 булса, 2015 елның ун аенда 45кә җиткән. Менә кайбер мисаллар.

Күптән түгел ТР экология һәм табигый байлыклар министры Фәрит Габделганиев кушуы буенча, Идел һәм Кама акваторияләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруның законлылыгын тикшерү үткәрелгән. Нәтиҗәдә акваториядә 26 йөзмә кран һәм җир казу снаряды эшләве, аларның алтысында закон бозу очраклары булу ачыкланган. Алар арасында – гомумтаралган файдалы казылмаларны лицензиясез чыгару, су судноларында рөхсәт документлары булмау. Законсыз табылган комчуерташ катнашмасының якынча күләме – 80 мең тоннадан, гомуми зыян 13 миллион сумнан арткан.

**Рейд барышында техниканы ташлап качу очраклары да шактый – бу вакытта административ материалны теркәү катлаулана. Бер нәрсә кала – транспорт чарасын штраф туктальшына кайтарып кую. Бу дәлил тиз арада хуҗаны табарга һәм закон бозучыны ачыкларга ярдәм итә. Әмма законсыз карьерны табу, «кара казучыларны» бушлай файдалы казылма чыганагыннан мәхрүм итү әле бер хәл. Законсыз тыкшынулар нәтиҗәсендә актарылып ташланган җирләрне торгызырга да кирәк бит.**

Былтыр көз Экология министрлыгы белгечләре, РФ Эчке эшләр министрлыгының Питрәч районы бүлеге хезмәткәрләре белән берлектә, Питрәч районы территориясендә дәүләт экология мониторингы үткәргәндә, Тогашево авылы янында лицензиясез торф чыгару факты ачыкланган. Җинаять өстендә фронталь төягеч һәм берничә КАМАЗ автомобиле тоткарланган. Мамадыш районындагы Усали авыл җирлеге территориясендә 6,5 гектар мәйданлы законсыз карьер табылган. Җир кишәрлегенә административ тикшерү үткәргәннән соң, аның хуҗасы ачыкланган. Чирмешән районы территориясендә законсыз карьер табылган. Юридик затка 60 мең сум штраф салынган.

Күптән түгел башкаланың Отар бистәсе янындагы «кара казучылар» турында вакыйга бөтен Казанны шаулаткан иде. Әлеге факт буенча күрелгән чаралар хакында ТР экология һәм табигый байлыклар министры Фәрит Габделганиев сөйләде.

– Отар бистәсе янындагы мең квадрат метрдан артыграк мәйданда ком чыгарган «кара казучыларга» ноябрьнең салкын һәм юеш һавасы да комачауламый иде. Мин бу рейдта шәхсән үзем катнаштым – төягеч һәм экскаватор йөртүчеләр җинаять урынында тоткарланды, ком ташучы берничә КАМАЗ да якында гына табылды. Экология министрлыгы инспекторлары тиешле беркетмәне тутырды. Әлеге факт буенча барлык документлар җинаять эше ачу өчен хокук саклау органнарына тапшырылды. 2015 елда «кара казучылар» Татарстан табигатенә 100 миллион сумлык зыян китерде, 2014 елда зыян суммасы 150 миллион сумнан арткан иде.

### КЫШКЫ БОРЧУЛАР

Законсыз карьерлар саны елдан ел азагына кадәр аерута ишәя. Әмма гадәттән тыш хәлләр кышын да була. Мәсәлән, законсыз карьерларга бәйле зур җинаятьләрнең берсе 2015 елның гыйнварында Авиатөзелеш районының Щербаково бистәсендә ачыкланган. Аның турында гражданнар хәбәр иткән. Шул урында 4 йөк автотранспорты, экскаватор һәм төягеч табылган. Белгеч-маркшейдерләр мәйданны һәм чыгарылган төзелеш комы күләмен үлчәгән. Ике көндә әйләнә-тирә мохиткә 4 миллион сумнан артыграк зыян китерелгән.



Яңадан торгызу эшләренә миллионлаган сум акча китә.



Соңгы елларда республикада карьерлардан файдалану буенча контроль көчәйде.

**Муниципалитетлар өчен җир асты байлыкларын саклау мәсьәләләре дә бик актуаль. Һәм бу аңлашыла да – үз территорияләрендә законсыз эшкәртелә торган карьерлар өчен беренче чиратта аларга җавап бирергә туры килә бит. Кызганычка, җинаятьтә чын гаеплеләрне еш кына табып булмый, һәм ул вакытта карьерны рекультивацияләү өчен җаваплылык әлеге территориядә урнашкан муниципалитетка йөкләнә.**

Кагыйдә буларак, карьерларны рөхсәтсез казыганда дәүләт теркәү билгеләре булмаган техника файдаланыла. Рейд барышында техниканы ташлап качу очраклары да шактый – бу вакытта административ материалны теркәү катлаулана. Бер нәрсә кала – транспорт чарасын штраф тукталышына кайтарып кую. Бу дәлил тиз арада хуҗаны табарга һәм закон бозучыны ачыкларга ярдәм итә.

Законсыз карьерны табу әле бер хәл. Әмма законсыз тыкшынулар нәтиҗәсендә актарылып ташланган җирләрне торгызырга да кирәк бит әле. Моның өчен нәрсә эшләнә соң?

Файдалы казылмаларны законсыз чыгару фактлары турында барлык материаллар, зыян күргән җирләрне рекультивацияләү чаралары күрсәтүгә мәҗбүр иттерү өчен, табигатьне саклау прокуратурасына тапшырыла. Былтыр республикада мондый чаралар барлыгы 108 гектарлы 105 карьерда үткәрелгән. Мәсәлән, Азнакай муниципаль районындагы элек казылмалар законсыз табылган тугыз авыл җирлеге территориясендә җирләр тигезләнгән һәм йомшартылган. 2016 елда бу кишәрлекләрдә агач утырту, шулай ук районда тагын алты законсыз карьер урынын рекультивацияләү планлаштырыла. Зыян күргән җирләрне торгызу буенча барлык чаралар Азнакай муниципаль районы табигатьне саклау программасы кысаларында алып барыла.

Файдалы казылмаларны, мәсәлән, ком-чуерташ катнашмасын законсыз чыгару еш кына су объектлары, шул ук Идел яки Кама акваторияләрендә турыдан-туры алып барыла. Судан файдалану тармагындагы проблемалар моннан берникадәр вакыт элек Ульяновскида Россия Куркынычсызлык советы секретаре һәм РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиленең берләштерелгән киңәшмәсендә тикшерелгән иде. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм республикадагы экологик вазгыять белән таныштырды. Мәсәлән, ике елдан азрак вакыт эчендә Экология министрлыгы хезмәткәрләре хокук саклау органнары белән берлектә республика су объектларында гомумтаралган файдалы казылмаларны законсыз чыгаруның 24 очрагын теркәгән, 4 факт буенча җинаять эше ачылган.

ТР Экология министрлыгында, су һәм яр зоналарына рейдлар хокук саклау органнары хезмәткәрләре, муниципалитет җитәкчелеге һәм халык бергәләшеп тотынганда гына нәтиҗәле була, дип саныйлар.

Күптән түгел Татарстан территориясендә табигатьне саклау законнарын бозу, шул исәптән законсыз карьерлар казу фактлары хакында мәгълүмат хәбәр итүче гражданнарга түләү суммасы арттырылды. Әгәр элегрәк фото- һәм видеотеркәү өчен гражданга 1 мең сум бирелсә, 2016 елдан сумма 1,5 мең сум тәшкил итә. Хәбәр ителергә тиешле законнар бозу исемлеге дә киңәйтелгән – калдыкларны тиешсез урынга түгү һәм файдалы казылмаларны законсыз табудан тыш, бирегә гражданнарның гомумкуллану су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тыю, су саклану зонасында хуҗалык һәм башка эшчәнлек алып бару режимын һәм җирләрне (туфракның уңдырышлы катламын юкка чыгару) бозу да кертелгән. Болар барысы да көнүзәк мәсьәлә, бигрәк тә быел, чөнки 2016 ел республикада Су саклау зоналары елы дип игълан ителгән.

## ЖИР АСТЫ БАЙЛЫКЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ҺӘМ СУ САКЛАУ ЗОНАЛАРЫНДА УРНАШКАН ЖИР КИШӘРЛЕКЛӘРЕН КУЛЛАНУДАГЫ ХОКУК БОЗУЛАР

2013 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 6 октябренә кадәр

Татарстан Республикасы буенча барлыгы:

**924** закон бозу очрагы


**908** беркетмә төзелгән


**35 378, 6 мең сум** салынган штрафларның күләме

## КАРЬЕРЛАРНЫ ЗАКОНСЫЗ ЭШКӘРТҮ

**1040** кишәрлек тикшерелгән

**641** законсыз эшкәртелгән карьер ачыкланган





### МУНИЦИПАЛЛАР ҖАВАПЛЫ

Муниципалитетлар өчен жир асты байлыкларын саклау мәсьәләләре дә бик актуаль. Һәм бу аңлашыла да – үз территорияләрендә законсыз эшкәртелә торган карьерлар өчен беренче чиратта аларга җавап бирергә туры килә бит. Кызганычка, җинаятьтә чын гаеплеләрне еш кына табып булмый, һәм ул вакытта карьерны рекультивацияләү өчен җаваплылык әлеге территориядә урнашкан муниципалитетка йөкләнә.

Рөхсәтсез казылган карьерларның күпчелеге Баулы, Аксубай, Питрәч, Әлмәт, Балык Бистәсе, Мөслим, Биектау, Зәй, Теләче һәм Мамадыш муниципаль районнарында теркәлгән. Законсыз эшкәртүдән соң калган чокырларда стихияле чүплекләр пәйда була, алар грунтны һәм жир асты суларын пычрата. Болар барысы да экологик вазгыятькә тискәре йогынты ясый. Әмма муниципаль берәмлек җитәкчеләренең үз фикерләрен нигезли торган капма-каршы дәлилләре дә бар. Һәм аларның дәлилләре белән санлашмый булмый.



### ЛӘЙСӘН ГАЛӘВЕТДИНОВА, БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫ:

*– Законсыз карьерлар проблемасы безнең районыбызда шактый кискен тора. Былтыр өч авыл җирлегендә – Семиозерское, Дачное, Чернышевское – ком һәм торфны законсыз табу фактлары буенча тиешле беркетмәләр төзелде. Бүгенге көндә районга җиде законсыз карьер өчен штраф салырга мөмкиннәр. Әмма хикмәт менә нәрсәдә: кайчандыр әлеге карьерлар авыл җирлекләре мәнфәгатьләрендә эшкәртелгән, жир кишәрлекләрен арендага бирү турында рәсми документлар бар. Тик аренда вакыты беткән, ә карьер калган. Һәм хәзер муниципаль берәмлек җитәкчеләре штраф түләргә, рекультивация үткәрергә, ягъни үзләре кылмаган җинаять өчен җәза үтәргә тиеш. Кайда соң монда гаделлек?! Карьерларны муниципаль бюджет хисабына төзекләндерү бик кыйбатка төшә. Былтыр Чыпчык авыл җирлегендәге бер карьерны рекультивацияләү 1 миллион 300 мең сумга төште! Килешәсездер, бик кыйммәткә төшкән рәхәтлек, бигрәк тә авыл җирлекләрен төзекләндерүгә нибары 100–200 мең сум бүленүен исәпкә алганда. Бүген административ хокук бозулар турында беркетмәләр ни өчендер нәкъ менә муниципалларга карата төзелә. Гәрчә безнең әйләнә-тирә мохитнең саклануы өчен ТР Экология министрлыгы җаваплы булса да. Ә без кайчак теге яки бу карьерны кем казыганын да белмибез. Алар арасында моннан егерме ел элек казылганнары да бар, алар күптән файдаланылмый, ул чакта әле Экология министрлыгы үзе дә булмаган хәтта...*

*Тагын бер нәрсә – Биектау районының Дачное җирлегендә карьер казучыларны туктатканнар. Штрафлар миллион сумнан арткан... Әгәр бу акчаларны безгә карьерны төзекләндерү өчен кире кайтарсалар, хәл шундук җайга салыныр иде. Алай са нигә соң бүген җирлек башлыкларын карьерлар өчен штраф түләргә, рекультивация белән шөгыльләнергә мәҗбүр итәләр? Аларның бит моңа акчасы юк. Кайбер карьерларның тирәнлеге исә утызар метрга җитә, анда бер генә миллион китмәячәк...*

Ләйсән Галәветдинованың фикере мантыйкка ярашлы. Ихтимал, җыелган проблемаларны бергәләшеп хәл итү юлларын эзләргә кирәктер. Сүз уңаеннан, 2016 елның 1 гыйнварыннан гомумтаралган файдалы казылмалар табуга салым түлысынча муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына күчереләчәк (бу елына 80 миллион сум тирәсе булачак). Бәлки, бу салымнан кергән акчаны бары тик ташландык карьерларны рекультивацияләү максатларында гына кулланыргадыр?



Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.
Автор фотолары.

# КЕЧЕ хуҗалыкларның «олы» хуҗалары

БҮГЕНГЕ КӨНДӘ КЕЧЕ ЯРДӘМЧЕ ҺӘМ КРЕСТЬЯН-ФЕРМЕРЛЫК ХУҖАЛЫКЛАРЫН АВЫЛНЫҢ «ИМИНЛЕК МЕНДӘРЛӘРЕ» ДИЛӘР. ҺӘМ БУ АСЫЛДА ДӨРЕСЛЕККӘ ТУРЫ КИЛӘ, ЧӨНКИ КРИЗИС ШАРТЛАРЫНДА КРЕСТЬЯН УТАРЫ ГАИЛӘ БЮДЖЕТЫН ТУЛЫЛАНДЫРУНЫҢ ТӨП ЧЫГАНАГЫН, АВЫЛ ҮСЕШЕНЕҢ НИГЕЗЕН ТӘШКИЛ ИТӘ.

Соңгы елларда шәхси һәм фермерлык хуҗалыклары Татарстанның азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүдә зур роль уйный. Хәзерге көндә республикада 4700дән артык КФХ һәм 400 меңнән артык ШЯХ исәпләнә, алар тулай авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысыннан артыгын, шул исәптән сөтнең өчтән берен, итнең 20%ын, бәрәңге һәм яшелчәнең 90%ка якынын җитештерә. ШЯХларда ел саен тере үлчәүдә 132 мең тонна ит, 600 мең литрдан артык сөт, 300 миллионнан күбрәк йомырка җитештерелә.

## ҖИРДӘ ХЕЗМӘТ КУЮ

Шәхси утарың яки фермерлык хуҗалыгың күләме ягыннан нинди зурлыкта булуына карамастан, ул көндәлек игътибар һәм кайгырту гына түгел, физик һәм матди чыгымнар таләп итә, хуҗаларының инициативалылыгын һәм булдыклылыгын, үзләренең эш-гамәлләрен берничә адымга алдан исәпләп карый белүен көздә тота. Республиканың Балтач һәм Чүпрәле районнарында нәкъ менә шундый уңган кешеләр белән очраштым мин.

Әлеге районнарны сайлавым очраклы түгел, чөнки бу муниципаль берәмлекләр соңгы ике елда, республикада җан башына күчереп исәпләгәндә тигән сыерлар санының үсеш темпы ягыннан, шуларга ярашлы рәвештә, беренче һәм икенче урыннарны бүлешә. Бары тик 2014–2015 елларда гына балтачлылар савым сыерлары көтүен 232 башка арттырган. Әлеге җәһәттән районның Куныр һәм Карадуган авыл җирлекләре бигрәк тә аерылып тора, аларда соңгы биш елда ШЯХларда сыерларның баш саны үсеше динамикасы, шуларга яраш-




Авылда кешенең эшлекле активлыгын үстерү — республика җитәкчелеге, муниципалитетлар башлыклары, фермерлар һәм ШЯХ башлыклары катнашлыгында уздырылган зона семинарларының төп темасы.

**Хәзер республикада 4700дән артык КФХ һәм 400 меңнән артык ШЯХ исәпләнә, алар тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысыннан артыгын, шул исәптән сөтнең өчтән берен, итнең 20%ын, бәрәңге һәм яшелчәнең 90%ка якынын җитештерә. ШЯХларда ел саен тере үлчәүдә 132 мең тонна ит, 600 мең литрдан артык сөт, 300 миллионнан күбрәк йомырка җитештерелә.**

лы рәвештә, 120 һәм 119 процент тәшкил иткән.

Карадуган авыл җирлегенең алты торак пунктында бүгенге көндә 900 баштан артыграк мөгезле эре терлек асрала, шуларның 480гә якыны – сыер. Быелтыр биредә 60 тоннадан артык ит һәм 2200 тоннадан күбрәк сөт җитештерелгән. Муниципаль берәмлек башлыгы Шамил Низамиевның сүзләренә караганда, җирлектәге 6 шәхси эшкуар һәм 5 крестьян-фермерлык хуҗалыгы авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүгә зур өлеш кертә. Алар арасында «Сәмигуллин А.Г.» КФХ бар. Бүгенге көндә аның гаилә фермасында 30 баш МЭТ асрала, шуларның 12се – савым сыеры. Айдар Галиевич рәсми теркәлеп фермерлык белән шөгыльләнергә 8 ел элек керешкән. Әүвәле ул күпләп дуңгыз асраган булган, әкренләп МЭТкә күчкән. 2014 елда аның хуҗалыгы «Терлекчелек буенча ТРның иң яхшы гаилә фермасы» исеменә лаек булган.



Карадуган авыл җирлеге башлыгы Шамил Низамиев һәм фермер Айдар Сәмигуллин. 2014 елда фермерның хуҗалыгы «Терлекчелек буенча ТРның иң яхшы гаилә фермасы» исеменә лаек булган.

– Моңарчы республиканың бернинди программасында да катнашканым юк иде, шунлыктан әлеге бүләк минем өчен бердәнбер дәүләт булышлыгы булды, – ди Айдар Сәмигуллин. – Әлегә эшемне үз мөмкинлекләремә таянып кына киңәйтәм, әкренләп хуҗалыкта эшкуарлык алып бару серләрен өйрәнәм. Үз продукциям белән базарга чыкканым юк, сөт һәм итне алыпсатарларга сатам. Арзан килеп чыга инде, билгеле. Продукциямне шәһәрдә сатсам, табышы икеләтә зуррак булыр иде. Әмма бүгенге көндә минем моңа вакытым да, моңа яраклы техникам да юк. Киләчәктә хуҗалыгымны киңәйтергә, савым сыерлары көтүен ишәйтергә ниятлим. Һәм моңа ирешү өчен, республика программаларына өмет баглыйм. Безгә, крестьяннарга, иренеп яту хас түгел.

Балтач районының 18 җирлегендә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән 92 крестьян-фермерлык хуҗалыгы шөгыльләнә. Шул ук вакытта районда гаилә фермалары саны әкренлек белән арта, алар нибары 11 генә. Якын арада тагын 9 ферманы эшләтеп җибәрергә ниятлиләр.

Күптән түгел балтачлылар мал чалуны һөнәри дәрәҗәдә оештыру мәсьәләсен хәл иткән. Бер елдан аз гына элегрәк, «Эш башлаучы фермер» республика максатчан программасы кысаларында, райүзәктә заманча хайван чалу цехы эшли башлаган. Ул «Закирова Р.З.» КФХна карый. Биредә бер тәүлек эчендә 12 башка чаклы мөгезле эре терлек чалалар. Маллар нигездә халыктан сатып алына. Суелган иттән төрле ярымфабрикатлар, казылык, өч төрдәге колбаса, ат итеннән төрле ысланган ризыклар җитештерелә. Бер үк вакытта мини-цехта казлар һәм үрдәкләр ыслыйлар. Бөтен җирле продукция «Хәләл» стандарты буенча сертификацияләнгән.

Фермерлык хуҗалыгы көн саен Балтач районының 45 мәктәбенә һәм 28 балалар бакчасына 1 категорияле суытылган ит җибәреп тора.

– Без шулай ук товарның ветеринария таләпләренә туры килүен дә кайгыртабыз, колбаса эшләнмәләре, казылыклар җитештерәбез, – ди «Закирова Р.З.» КФХның башкарма директоры Рифат Закиров.

## ЯРДӘМЧЕДӘН – ТӨП ХУҖАЛЫККА

Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылында, аягында нык басып торучы һәм хезмәт сөючән гаиләләр турында сүз чыкканда, беренче чиратта Айсылу һәм Ранил Камәраевларны атыйлар.

Камәраевларның искиткеч матур һәм төзек йорт-җиренә, пөхтә ихатасына күз салгач: «Монда чын хуҗалар яши», – дип уйлап куясың. Ир белән хатын, бергә яши башлаган көннәреннән алып, утарларында күп итеп мал асрый.

– Ихатабызны буш тотуны күз алдына да китерә алмыйбыз, – ди Айсылу Камәраева, яңарак кына бозаулаган сыерын савуны төгәлләп. – Аллага шөкер, әти-әниләребез кече яшьтән эшкә өйрәтеп үстерде.



Чүпрәле районы Кече Үби авылыннан аталы-уллы Сергей һәм Алексей Павловлар.



Чүпрәле районы Село-Үби авыл җирлеге башлыгы Алексей Ярухин.

Сүз дә юк, бөтен кешедән иртәрәк торасың, соңрак ятасың, кунакка да озакка барып булмый, әмма муллыкта яшисең. Ирем белән икебезнең хезмәт хакына гына балаларны аякка бастырып булмас иде. (Камәраевлар шуның өстенә социаль хезмәткәрләр дә әле, олы яшьтәге ялгыз авылдашларын карыйлар. – Авт.)

Тиң парлар ике ул тәрбияләп үстерә. Олысы Раил Казан авиация–техник көллиятен тәмамлап, эти–әнисе янына әйләнеп кайткан. Кечесе Рузил тиздән дипломлы электрик булачак: быел Ульяновск электр-механика көллиятен тәмамлый.

– Уларыбыз – төп ярдәмчеләребез, – дип әңгәмәгә кушыла гаилә башлыгы. – Менә олы улыбыз ярдәменә таянып, былтыр малларның баш санын арттырдык. Ул безнең гаилә эшен дәвам итәргә ниятли. Шулай итеп, элеккеге ярдәмче хуҗалыгыбыз хәзер төп хуҗалыкка әйләнде.

Кече гаилә фермалары төзү республика программасы ярдәмендә һәм шуңа үз маяларын да өстәп, Камәраевлар 2015 елда үз өйләре янәшәсендә борыстан сыер абзарын сафка бастырган. Бина 22 баш савым сыерына исәпләнгән, ул яртылаш тулган да инде. Ир белән хатын киләчәктә ШЯХларын тагын да киңәйтергә ниятли, фермерлык хуҗалыгы ачулары да мөмкин. Әмма аңарчы алар нинди дә булса авыл хуҗалыгы техникасына ия булырга һәм, зур булмаса да, җир

**– Ихатабызны буш тотуны күз алдына да китерә алмыйбыз, – ди Айсылу Камәраева, яңарак кына бозаулаган сыерын савуны төгәлләп. – Аллага шөкер, эти-әниләребез кече яшьтән эшкә өйрәтеп үстерде. Сүз дә юк, бөтен кешедән иртәрәк торасың, соңрак ятасың, кунакка да озакка барып булмый, әмма муллыкта яшисең. Ирем белән икебезнең хезмәт хакына гына балаларны аякка бастырып булмас иде. (Камәраевлар шуның өстенә социаль хезмәткәрләр дә әле, олы яшьтәге ялгыз авылдашларын карыйлар. – Авт.)**

кишәрлегенә тиенергә хыяллана. Шәхси тракторың булмауга ничектер түзеп була әле, әмма үз сөрүлек җирләреңнең юклыгы малларның баш санын арттыруга киртә куя. Хуҗалыкны асылда сатып алынган терлек азыгы белән алып барганга күрә, чыгымнар гаилә бюджетына нык суга.

– Сатып алынган мал азыгы белән ерак китеп булмый, әле шуның өстенә җитештергән продукциягә мантыйкка ярашлы тотрыклы бәяләр юк, – дип борчыла Айсылу Камәраева. – Декабрьдә сөтнең литрын 17 сумнан тапшырдык, монысы ярыйсы иде әле. Сөт җыючылар әкренләп сатып алу бәяләрен 15 тәңкәгә чаклы төшерде. Тиздән тагын күтәрмәкчеләр, әмма озаккамы? Каймаклы сөтеңне юк бәягә алыпсатарларга биреп җибәргәндә, чарасызлыктан җан әрни, кулдан эш төшә.

Аның фикеренчә, авыл кешесе шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга ничек кенә җәлеп итмәсеннәр, нинди генә программалар уйлап чыгармасыннар, авыл хуҗалыгы продукциясен сату базарын көйләү генә шәхси хуҗалыкларны алга таба үстерү өчен төп этәргеч була ала.

Кече Үбидә яшәүче Сергей Павлов та бу фикер белән килешә. Бүгенге көндә аның шәхси хуҗалыгында 11 баш МЭТ асрала, шуларның 9ы – савым сыеры. Бары тик гыйнвар аенда гына ул 2500 литр чамасы сөт саткан. 2015 елда, Камәраевлар сыман, Павловлар да республика программасы кысаларында кечкенә сыер абзарына тиенгән. Бина терлек белән тулган инде.

– Яңа сыер абзары турында күптәннән хыяллана идек, чөнки иске сарайда гомумән урын юк иде бит, – ди Сергей Зиновьевич. – Ә монда терлек азыгы таратырга да, савым аппараты кулланырга да була. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп узыйм: аны сатып алырга безгә республика һәм район бу-

**Моннан 20 ел элек татарстанлыларның утарында 214 мең сыер исәпләнсә, бүгенге көнгә ул нәкъ ике тапкырга кимегән. Шуның өстенә, савым сыерларының баш саны соңгы өч елда бик нык азайган – 14,3 мең башка! Һәм боларның барысы да хуҗалык итүнең кече формаларына дәүләт ярдәме фонында: бары тик 2015 елда гына да авыл эшкуарлыгын үстерүгә ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аша республика бюджетыннан җәмгысе 2 млрд сум акча бүлеп бирелгән!**



«Без шәхси секторда савым сыерларының баш санын саклап калу гына түгел, арттырурга да ирештек», — ди Чүпрәле районы башлыгы Александр Шадриков.

лышты. Гомумән, күрсәткән ярдәме өчен, дәүләткә зур рәхмәтебезне җиткерәсе килә. Үзебезгә мондый ферма төзеп чыгу авырга туры килер иде.

Сөт һәм ит җитештерү юнәлешләрендәге терлекчелек Село-Үби авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпчелегенең төп керем чыганагы. Җирле шәхси ярдәмче хуҗалыкларда 870 баш мөгезле эре терлек асрала, шуларның 341е – савым сыеры. Бары тик узган елда гына да җирле халык 545 мең литр сөт сатып, 8,5 миллион сум керем алган. Шул ук вакытта җирлектә яшәүчеләр ШЯХ үстерүгә биш ташламалы кредит та алган. Җәмгысе 1,4 миллион сум акча нигездә терлекчелек биналарын үзгәртеп коруга сарыф ителгән.

Дәүләттән субсидияләнүче кредитлар Чүпрәле районындагы шәхси хуҗалыкларны ныгыту өчен әйбәт этәргеч. Бүгенге көндә Чүпрәленең һәр дүртенче гаиләсе шундый кредит алган, халыкка күрсәтелгән ярдәмнең тулаем күләме 800 миллион сумга якынлашып килә. ШЯХның мал азыгы сатып алу чыгымнарын өлешчә каплауга юнәлдерелгән республика программасы савым сыерлары көтүен саклап калу һәм арттыруда сизелерлек роль уйный. Былтыр чүпрәлеләр әлеге максатларга 15,8 миллион сум акча алган. Таналар сатып алуга һәм зур булмаган сыер абзарлары төзүгә тәгаенләнгән яңа республика программалары җирле халыкның күңеленә хуш килгән.

Хуҗалыгында яхшы сыйфатлы маллар асрауның ничаклы әһәмиятле булуын авылда һәркем белә. 2013 елдан бирле чүпрәлеләргә бу эштә җирле ветеринария пунктлары белгечләре ярдәмгә килә.

– Район тарихында, корылык аркасында терлек азыгы җитмәгәнгә күрә, кешеләрнең үз малларын киметкән чаклар да булды, – дип сөйли Чүпрәле районы башлыгы Александр Шадриков. – Әмма салада яшәүчеләрнең киләчәккә өмет белән каравы һәм эш сөючәнлеге, авыл җирлеге башлыкларының халык арасында алып барган көндәлек эшчәнлеге, республика ярдәме дә, әлбәттә, шәхси секторда савым сыерларының баш санын саклап калырга гына түгел, арттырырга мөмкинлек тудырды.

2016 ел башына районның 19 авыл җирлегендәге ШЯХларда 13400 чамасы МЭТ, шул исәптән 5100дән артыграк сыер асрала. Агымдагы ел муниципаль берәмлектә Эшлекле активлык елы дип игълан ителгән, җирле хакимиятләр бу күрсәткечләрне тагын 10 процентка арттырырга ниятли. «Гаилә фермасы» программасы чүпрәлеләргә авыл эшкуарлыгы белән шөгыльләнергә ярдәм итә. Бүгенге көндә 17 гаилә шуның кысаларында хезмәт куя.

## СЫЕРНЫҢ КАДЕРЕ ЮГАЛА

Кызганычка, бүгенге көндә республикада терлекләрнең баш санына бәйле гомуми вазгыять Балтач һәм Чүпрәле районнарындагы кебек уңай түгел. Әйтик, моннан 20 ел элек татарстанлыларның утарында 214 мең сыер исәпләнсә, бүгенге көнгә ул нәкъ ике тапкырга кимегән. Өстәвенә, савым сыерларының баш саны соңгы өч елда бик нык азайган – 14,3 мең башка! Һәм боларның барысы да хуҗалык итүнең кече формаларына дәүләт ярдәме фонында: бары тик 2015 елда гына да авыл эшкуарлыгын үстерүгә ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аша республика бюджетыннан җәмгысе 2 млрд сум акча бүлеп бирелгән!

Малларның баш саны кимүе өчен, район һәм җирлек башлыкларын гына гаепләү дөрес булмас иде, билгеле. Вазгыять объектив процесслар белән аңлатыла: авылларыбыз әкренләп картая, ялгыз картларның хуҗалык алып бару көченнән килми, эшкә сәләтле кешеләр мал карарга атлыгып тормый, шуның өстенә, сөт, май, итне кибеттән сатып алып була.


– Муниципаль һәм җирле хакимиятләр халык белән тыгыз элемтәдә эшләгән районнарда малларның баш саны кимүгә юл куелмады, – дип саный ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов. – Бүгенге көндә ихатасында моңарчы мал тотмаганнарны сыер асрарга үгетләүдән мәгънә юк. Әмма без хәзер күпмедер терлеге булганнарга йөз тотабыз, 2015 елдан башлап, 3–8 баш сыерга исәпләнгән сөтчелек фермалары төзү чыгымнарын каплауга юнәлдерелгән программаны эшләтеп җибәрдек. Аңа ихтыяҗ бик зур булып чыкты, быел бу максатка 60 миллион сум акча тоту каралган.

Республикада мини-фермалар төзү программасын башлап җибәрүдә Мамадыш районы әйдәп бара. Биредә 64 мини-ферма сафка бастырылган инде. Кукмара районында – 32, Арчада 30 кече ферма төзелгән.

Моннан тыш, быелдан башлап, Татарстанда шәхси хуҗалыкларга ярдәм күрсәтүнең яңа чарасы гамәлгә керде. Сүз «ТР биләмәләрендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында»гы канун хакында бара. Ул уннан артык яңа төрдәге ярдәмне күздә тота.



**237,5 млрд сум – Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен былтыр шуның кадәр күләмдә акча тотылган.** Республикада заказчыларның гомуми саны 8 меңнән артып киткән, сатып алуларда катнашкан тәэминатчыларның гомуми саны 33 меңнән артык. 2015 елда конкурсларда җиңгән тәэминатчыларның 60 проценты – үзебездәге товар җитештерүчеләр.



**78 – 2016 елда ТР муниципаль берәмлекләренең авыл җирлекләре советлары** урнашкан шул сандагы бинаны ремонтлау планлаштырыла.



**268,2 чакрым – 2016 елда республикада салыначак суүткәргеч челтәрнең гомуми озынлыгы шулкадәр.** Шулай ук 43 артезиан суы скважинасы һәм 45 су башнясы урнаштыру каралган.



**12 мең 552 данә диодлы яктырткыч – 2016 елда Татарстанның авыл җирлекләрендә урамнарга шуның кадәр яктырткыч урнаштырылачак.** Шулай ук 475 чакрым электр тапшыру чыбыгы да монтажланачак.




**203 млн сум – 2016 елда Казан юл хәрәкәте куркынычсызлыгы программасын тормышка ашыруга шуның кадәр акча бүлергә ниятли.** Әлеге сумманың төп өлеше (190 млн сум) светофор объектларын яңартуга, юл хәрәкәте белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасын үстерүгә һәм карап тотуга китәчәк. Программа шулай ук куркыныч урыннарга юл билгеләре урнаштыру, сызыклар сызу һәм халык арасында акцияләр уздыруны күздә тота.

**830 күпфатирлы торак йорт – 2016 елда 4,7 млн кв. м торак йорт мәйданы капиталь ремонт программасы буенча төзекләндереләчәк.** Быел 1,9 млрд сумга 95 гомуми белем бирү учреждениесенә, 589, 6 млн сумга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына ремонт ясалачак. Мәктәпләр исемлегенә 80 муниципаль һәм 15 махсус (коррекцион) мәктәп кергән.



**9 балаларны савыктыру лагеры 2016 елда капиталь ремонт көтә.** Республика бюджетыннан шушы максатларда 51 млн сум күләмендә акча бүлеп биреләчәк. Шулай ук балалар өчен ике савыктыру лагеры төзү (25 млн сум) һәм бер балалар савыктыру лагерын реконструкцияләү (15,4 млн сум) каралган. 27 үсмерләр клубына ремонт ясалачак.



**8 процент – узган ел хайваннар һөҗүменнән зарланып мөрәҗәгать итүчеләрнең саны шулкадәргә арткан.** Республиканың 26 муниципаль районында әлеге проблема белән ешрак очрашканнар. Татарстанда хайваннар арасында котыру чире очраклары 2,4 тапкырга арткан. 12 муниципаль берәмлектә, авыру төлкеләрне ату өчен, өстәмә рәвештә 3,5 млн сумнан артыграк акча бүленгән.



**1 млн 33 мең баш – республикада хуҗалык итүнең төрле формалары буенча санаганда, 2016 ел башына шуның кадәр мөгезле эре терлек һәм кош исәпләнә,** шул исәптән 748,1 мең баш – авыл хуҗалыгы берләшмәләренә һәм крестьян-фермер хуҗалыкларына туры килә. 2015 елда Татарстанда 488 мең тонна терлек һәм кош ите җитештерелгән, 1 млн 751 мең тонна сөт савып алынган, 1 млрд 171 млн данә йомырка җитештерелгән.



**11 мең трактор, 6 меңнән артыграк чәчкеч, 600дән артыграк чәчү комплексы, 5700 культиватор һәм башка авыл хуҗалыгы техникасы** – алдагы чәчү чорында Татарстанда шуның кадәр техника кулланылачак. 2015 елда техник модернизацияләүнең республика программасы кысаларында 800дән артык авыл хуҗалыгы җитештерүчесе 5 меңгә якын техника һәм җиһаз сатып алган, аларның гомуми суммасы 5,8 млрд сум тәшкил иткән, «60х40» схемасы (авыл хуҗалыгы техникасының 40 проценты субсидия рәвешендә бюджеттан бүлеп бирелә) буенча 1,9 млрд сум акчаны бюджеттан алган.





**Лилия НУРМӨХӘММӘТОВА тексты.
Фотолар Марат ФАЗЛЕЕВ архивыннан
һәм Андрей Титовтан алынды.**

# БӘХЕТ формуласы

МАРАТ ФАЗЛЕЕВНЫҢ БИК ТӘ АГРОНОМ БУЛАСЫ КИЛӘ. ТИК ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫНА БАРЫРГА ГЫНА ЮНЬЛЕ КИЕМЕ ЮК. ӨЛКӘН ЯШЬТӘГЕ ӘТИ-ӘНИДӘН АКЧА СОРАУ КИЛЕШМИ, БОЛАЙ ДА КӨЧЛӘРЕННӘН КИЛГӘНЧӘ ТЫРЫШАЛАР. ӨС-БАШЫН КАРАР ӨЧЕН, ИМТИХАННАРГА КАДӘР УЛЬЯН ЯКЛАРЫНА ШАБАШКАГА БАРЫРГА БУЛА. ГӨНАҺ ШОМЛЫГЫНА КАРШЫ, АКЧАНЫ ВАКЫТЫНДА БИРМИЛӘР. БУШ КУЛ БЕЛӘН КАЙТАСЫ КИЛМИ. ХЕЗМӘТ ХАКЫН АЛГАНДА ИНДЕ ИМТИХАННАР ВАКЫТЫ ТӘМАМЛАНГАН, УКУЛАР БАШЛАНГАН БУЛА.

Тәтеш районының Мәмәй бистәсендә туган егет, әтисе кебек агроном белгечлеге аласы килсә дә, кәефен төшерми. Укырга беркайчан да соң түгел, дигән уй белән ДОСААФ ишеген ачып керә. Укый гына башлый, Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумы тренеры, урамда күреп, нишләп йөрүе белән кызыксына. Мәктәптә яхшы укыган, районда чаңгы ярышларында гел алдынгы булган Маратны үзләренә укырга чакыра. Шулай итеп, көндез – агрономлыкка, кичен шоферлыкка укый башлый. Шул ук вакытта спортны да ташламый. Төрле ярышларда катнаша. Районда гына түгел, республика, ил күләмендә җиңүләргә ирешеп, спорт мастеры дәрәҗәсен ала. «Танылган чаңгычы, Олимпия уеннары чемпионкасы Галина Кулакова белән бергә катнашкан ярышлар да булды», – дип искә ала ул яшьлек дәрте ташып торган студент елларын.

Язмышын спорт белән бәйләгән дә булыр иде. Тик балачактан күңелгә кереп калган агроном булу теләге көчлерәк була шул. Өлкән яшьтәге әти-әнисен калдырып читкә дә китәсе килми, аларга да терәк кирәк.

## ГОМЕРЛЕК САБАК

Укып бетергәч тә, март аенда Олы Тарханга агроном итеп җибәрәләр аны. Нәкъ шул вакытта колхоз рәисе дә, баш агроном да каты авырып китә. Партоешма секретаре белән Марат икесе генә кала. Нишләргә? Кол-



ТР Президенты Минтимер Шәймиевнең Тәтеш районына эш сәфәре. (1990нчы еллар).

**Марат Галимҗановичны халыкның хөрмәтләвенең тагын бер сере бар. Ул районда яшәүче халыкларның телен белә. Татарлар белән үз ана телендә рәхәтләнеп сөйләшә. Руслар белән рус телендә иркен аралаша. Чувашлар белән күрешсә, мәктәп елларында малайлар белән аралашкан чуваш теленә күчә, мордвалар килеп кул бирсә, мордвача сүз башлый.**

хоз зур, 6 мең гектар җирне тиешенчә эшкәртеп, чәчеп чыгарга кирәк. Партоешма җитәкчесенә таяныр идең, укытучы кеше, чәчүнең нечкәлекләрен белми. Техникумда алган белемнәрен эшкә җигеп, белмәгәнен китап-дәфтәрдән укып, чәчүне башкарып чыга. 8 майда чәчүне бетереп, 10 майда Совет Армиясенә китә.

Армиядән кайткач, егет җиң сызганып кабат үз эшенә алына. 1976 елда Фазлеев эшләгән «Рассвет» колхозы игенчелектә яхшы уңышка ирешә. КПСС райкомының беренче секретаре Федор Андреевич Хохлов баш агроном булып эшләүче Маратны алдынгылар слетына алып бара. Кайту белән, эшләү дәрте ташып торган 25 яше дә тулмаган егетне мордва авылына колхоз рәисе итеп җибәрә. «Телләрен белмим», – дип карышып торса да, ул чорда партия сүзе – закон, риза була. «Авангард»ка рәис булып килгәч, кайсы урманга кереп качыйм икән, дигән көннәре күп була. Ничек итсә итә, колхозны төзекләндерә. Бер-бер артлы мәктәп, клуб, ферма, урамы белән йортлар һәм башка объектлар калкып чыга. 10 ел эшләү дәверендә телләрен дә өйрәнә, колхозны да алдынгы урынга чыгара.

Ул чактагы беренче секретарь Михаил Андреевич Офицеров Марат Галимҗановичка бер колхоз гына аз булуын аңлый. Аны район авыл хуҗалыгы идарәсенә җитәкче итеп билгели. Авыл хуҗалыгы тынгысыз өлкәләрнең берсе икәнен Фазлеев яхшы белә. Бер колхоз белән идарә итү бер хәл, район авыл хуҗалыгы өчен җавап бирү тагын да зур җаваплылык сорый. Өенә кайтып керә алмаган көннәре дә шактый була.

## ҖАВАПЛЫ ЧОР

1989 елда исә аңа тагын да зур җаваплылык йөкләнә. Өч кандидатура арасыннан Марат Фазлеевны Тәтеш районы халык депутатларының башкарма Советы җитәкчесе итеп сайлап куялар. Нәкъ Совет хакимияте таркалган чорда, иң авыр елларда район белән җитәкчелек итәргә туры килә аңа. Кибет киштәләре буш, нәрсәгә тотынсаң, шул юк, халыкны азык-төлек белән тәэмин итәргә кирәк. Илдә талон системасы. «92 төрдә талон бар иде. Даруыннан алып карамель конфетка кадәр бүлеп утырдык. Җиткереп булмый. Шул чорларны искә алганда әле дә йөрәкләрем әрнеп куя. Кешеләргә ярдәм итәсе килә, тик мөмкинлекләр чамалы иде бит», – ди Марат Галимҗанович.

Авыр еллар булса да, районны газлаштыру эшенә җиң сызганып керешә. Күрше районнар инде зәңгәр ягулык яга, ә тәтешлеләр салкыннан интегә. Проектлар ясатып, кирәкле җиһазларны юнәтеп, районны тулысынча газлаштыруга ирешәләр. «Безнең район Идел буйлап 110 чакрымга сузылган. Җиңел булды дип әйтә алмыйм, әмма башкарып чыктык. Беренче тапкыр газ җибәргән вакыт әле дә исемдә. Гомер җылынмаган хастаханә, ниһаять, җылынды. Ул вакытта һәр планерка газ белән башлана, газ белән бетә иде. Авылларда халык түземсезләнеп зәңгәр ягулык килүен көтте. Очрашкан саен, безгә газ кайчан булыр икән, диләр. Ә мин буш вәгъдәләр биреп йөри торган кеше түгел, ышандырам икән, ничек тә үтәргә тырышам. Гомер буе эшкә алындың икән, башкарып чыгарга, дигән девиз белән яшәдем», – ди Фазлеев.

Авырлык алдында югалып калмавы, үҗәтлеге аркасында, халкының мәхәббәтен яулый да ул. Алай гына түгел, республика җитәкчелеге дә аның оста җитәкче булуын белә. Президент Указы белән Марат Фазлеев Тәтеш районы хакимияте башлыгы итеп билгеләнә. 10 ел район белән җитәкчелек итү дәверендә Тәтешне шактый үзгәртә.

– Район белән җитәкчелек иткән чорда мин шактый эш башкардым, дип сөйлим икән, бу дөрес булмас иде. Ялгызым гына берни дә эшли алмаган булыр идем, без аны халык белән бергәләп башкардык, – ди Марат Галимҗанович.

Район халкының гына түгел, республикадә яшәүчеләрнең дә язмышын хәл итүдә шактый көч куя. Ике чакырылыш Татарстан Югары Советы депутаты да була, 10 ел дәвамында икътисад һәм бюджет комитетында эшли. Бәйсезлек игълан ителгән, беренче конституция кабул ителгән чорда депутат буларак ныклы эш алып барырга туры килә аңа.

## ТӘТЕШ КАЗАН АРАСЫ

Үзе әйткәндәй, аның хезмәт юлы өч чордан тора: Тәтеш – Казан – Тәтеш. Алдына куйган максатын җиренә җиткереп эшләвен белгәнгә, аны 1999 елда авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбаса-



**Техникумны Марат Галимҗанович кабул итеп алганда, андагы хәлләрне күрсәгез, исегез китәр иде. Хәзер анда һөнәр үзләштерер өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Техникум каршында ярдәмче хуҗалык оештырылды. Ташландык җирне алып, мең гектар мәйданны менә дигән уку базасы итте. Балаларны эшкә өйрәтер өчен, заманча техника кайтартты. Чәчү, урып-җыю чорларында хуҗалыкларга булышу гадәтен кертте.**

ры итеп билгелиләр. Тик бик тиз үз эше түгеллеген аңлый. Җитештерү тармагы кирәк аңа. Үз сүзен кистереп әйтә белүче Фазлеевның гозерен аяк астына салып таптамыйлар. «Татсахарпром»га генераль директор итеп куялар. 7 ел эшләү дәверендә шикәр комын җитештерүдә генә түгел, шикәр чөгендере үстерүдә дә зур яңалыклар кертүгә ирешә. Басудан кайтып керә алмаган авыл халкының эше җиңеләйтеп, республикага заманча техника кайтарта. Ләкин күңел тынычлыгын таба алмый. Үзенә башлангыч белем биргән техникум аяныч хәлдә.

2007 елда кире Тәтешкә кайта. Шундый эштә эшләп, таралып бетә язган урынга кем кайта инде диючеләр, аны аңламаучылар шактый була. «Беркем сүзенә карамадым, кайттым. Ник кайттыммы? Үземә белем биргән техникумны бу хәлдә күрү авыр иде миңа. Карап торган иске бер трактор. Ул да йөрми. Аның белән ничек балалар укытасың?» – ди бу хакта сүз чыккач. Максатына ирешә, уку йортын танымаслык итеп үзгәртә. 60 миллион грант отып, заманча җиһазлар кайтарта. Агроном, механиклардан тыш, эшче һөнәрләре әзерли башлыйлар. Бүген биредә 800ләп укучы 13 төрле һөнәр үзләштерә. 65 яшендә тыныч күңел белән лаеклы ялга китә.

## МИН БИК БӘХЕТЛЕ

Марат Фазлеев бүген дә район халкына кирәк булуын тоеп яши. Район Советы депутатлары арасында киңәш бирердәй олпат кеше кирәк дип, аның кандидатурасына тукталалар. Икътисад, бюджет, эшмәкәрлек, салым һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча даими комиссиянең рәисе ул. Без хакимият бинасында булганда да, аның янына әллә ничә кеше килеп, хәл-әхвәлләрен белешеп китте. «Мондый мөнәсәббәт булу бик куанычлы хәл билгеле. Үз районына кайта алмый йөргән җитәкчеләр бар. Ул яктан мин бәхетле. Район җитәкчелегендә эшләү дәверендә төрле хәлләр килеп чыга иде. Әмма уч белән эш йөртмәдем. Хезмәтенә салкын караган, аракы белән дус булганнарга кырыс идем. Бүген кайберләре яныма килеп, әле ярый шул чорда баткаклыктан коткардыгыз, дип, рәхмәт әйтә», – ди ул.

Марат Галимҗановичны халыкның хөрмәтләвенең тагын бер сере бар. Ул районда яшәүче халыкларның телен белә. Татарлар белән үз ана телендә рәхәтләнеп сөйләшә. Руслар белән рус телендә иркен аралаша. Чувашлар белән күрешсә, мәктәп елларында малайлар белән аралашкан чуваш теленә күчә, мордвалар килеп кул бирсә, мордвача сүз башлый.

Гомере буе кеше кадерен белеп яши ул. Кайда гына эшләсә дә, кадрларга зур игътибар бирә. Бик күпләрне эшкә өйрәтә. Районның кайсы оешма ишеген ачып кермә, аның укучылары эшли.

– Марат Галимҗанович бик таләпчән җитәкче, безне эшләргә өйрәтте. Техникумга тикшерү килә икән, коллективтагы беркемгә дә сүз тидерттермәде, канат астына алып, һәркемне яклый, бөтен авырлыкны үзе күтәрә иде, – ди Тәтеш муниципаль Советының аппарат җитәкчесе Людмила Абрамова. – Без аның янәшәсендә үзебезнең якланган булуыбызны тоя идек.

– Мин гади бер авыл баласы. Эшли-эшли, халкым ярдәме белән дәрәҗәләргә ирештем. Төрлесен күрдем. Үз фикеремне анык итеп әйтүем аркасында, авырлыклар белән дә очраштым. Әмма авыл баласында була торган ныклыгым күп нәрсәләрне чишәргә ярдәм итте, – диде ул.

## КИҢӘШЧЕБЕЗ УЛ БЕЗНЕҢ

Тәтеш муниципаль районы башлыгы Рәмис Хатыйпович Сафиулловтан Марат Галимҗанович хакында сорагач, бермәл сүзсез торды.

– Аның турында сөйләр өчен, башта фикереңне туплап бетерергә кирәк, – дип сүзен башлады ул. – Бик талантлы җитәкче. Мондый кешеләр сирәк. Нинди авыр чорда, ил үзенең кыйбласын үзгәрткән елларда эшләгән җитәкче ул. Хезмәт хакы, пенсияләр вакытында түләнмәде. Ә Тәтеш районында өзеклекләр бик бул-



Бөтен гаилә җыелганда.




«Оныклар мине яшьлеккә кайтарды», – ди Марат Фазлеев.

мады. Боларның барысы да аның тырышлыгы аркасында. Шул ук вакытта районда төзелеш эшләрен дә алып барды. Тузган торак һәм башка программалар буенча бик күп кешеләрне фатирлы итте. Нинди генә авыр чор булса да, районнан киткәндә 24,5 мең баш МЭТ калдырды. Моннан тыш, кадрлар мәсьәләсенә дә нык игътибар итте. Ул әзерләгән кадрлар әле дә районны алып бара. Мин үзем дә аның укучысы. «Сахарпром»да эшләгән чорын гына алыйк. Ул җитәкче булып килгәч, шикәр чөгендерен үстерү, эшкәртү бермә-бер артты, заманча технологияләр керде, кул көче бетерелде. Элек мең гектарга мең кеше кирәк булса, хәзер бер кеше дә җитә. Техникумны Марат Галимҗанович кабул итеп алганда, андагы хәлләрне күрсәгез, исегез китәр иде. Хәзер анда һөнәр үзләштерер өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Техникум каршында ярдәмче хуҗалык оештырылды. Ташландык җирне алып, мең гектар мәйданны менә дигән уку базасы итте. Балаларны эшкә өйрәтер өчен, заманча техника кайтартты. Чәчү, урып-җыю чорларында хуҗалыкларга булышу гадәтен кертте. Бу кеше турында, аның эшләре хакында тәүлек буе сөйли алам. Ул минем төп киңәшчем, әле дә аңа таянабыз.

## ГАИЛӘ ҖЫЛЫСЫ

Дәрәҗәләргә ирешү өчен, тылның яхшы булуы кирәк, дигәнне күпләр әйтә. Марат Галимҗанович та шулай, ди. Яшьли сөйгән яры Тәнзилә ханым гомер буе иренең төп терәге була. «Ир-ат тормышта ничек кенә талпынмасын, әгәр дә аны гаиләсе аңламый, ярдәм итми икән, ул үзе генә әллә кая бара алмый. Ул яктан минем тылым яхшы иде. Йорт эшләре гел хатын җилкәсендә булды. 41 ел бергә матур гомер кичерәбез, – ди ул. – 60 яшенә кадәр рус теле һәм әдәбияты укытып, «ТРның атказанган укытучысы» дәрәҗәсенә ирешкән мөгалимә хатыным. Узган ел икебез дә эштән туктап, ял итәргә булдык. Хәзер дә өйдә тик кенә ятарга исәп юк. Җәмәгать эшләрендә катнашырга чакырып торалар. Исән-сау булганда, булыша алганда, сәламәтлегем борчымаса, көчемнән килгәнчә эшләргә тырышырмын. Өйдә ятып кына депутат эшен башкарып булмый бит».

Юк, депутат эшләреннән тыш, аның әле оныкларын тәрбияләшәсе бар. Кызы белән улын спортка тартып, табигатьтә хозурланырга өйрәткән кебек, оныкларына да шуны сеңдерәсе бар. Әнә, олы оныгы Булат бабасы янында мәш килә. Оныклар мине яшьлеккә кайтарды, дияргә ярата бабалары. Булат белән бергә дәрес хәзерлиләр, иртән торып, көн саен спорт белән шөгыльләнәләр. Атнага бер-ике тапкыр булса да, чаңгыга чыгып керәләр. Шугалакка да барып кайталар, кар көриләр. Җәй көне Иделгә су коенырга йөриләр, балык тоталар.

– Мин – табигать баласы. Урманга барырга, җиләк-гөмбә җыярга, Идел белән хозурланырга яратам. Балаларымны да, өч оныгымны да шуңа өйрәттем. Алар моңа шулкадәр күнекте, шимбә-якшәмбе җитүгә, өебез балалар тавышына күмелә. Аллага шөкер, язмышыма рәхмәтле, – ди Марат Фазлеев.

Кызы Альбина мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, медицина юлыннан китеп, табиб булып эшли. Улы Альберт әтисе кебек яшьтән спорт белән шөгыльләнә. Педагогия көллиятен тәмамлаганнан соң, юридик белем алып, прокуратура системасында эшли.

– Без гадәти татар гаиләсе. Мин дә, хатыным да, балалар да масаеп йөрмәдек. Мин-минлеккә юл куймадык. Бизнесым да юк. Байлыкка омтылмадым. Булганына шөкер итеп, канәгать булып яшим, – ди Марат ага.




Марина БЕЛЬТИКОВА тексты.
Фотолар автордан һәм Таһир МӘХМҮТОВтан алынды.

# ТАРТЫЛУ *ноктасы*

КАЙЧАНДЫР БИРЕДӘ ҮТӘ АЛМАСЛЫК КАРУРМАН БУЛГАН. ИВАН ГРОЗНЫЙ ТАРАФЫННАН БАШЛАНЫП КИТКӘН МАССАКҮЛӘМ ХРИСТИАНЛАШТЫРУДАН КАЧКАН МАРИ КЕШЕЛӘРЕ МОНДА НИГЕЗ САЛГАН. БҮГЕН ИСКЕ КҮКЛЮК – АЛАБУГА РАЙОНЫНДАГЫ БЕРДӘНБЕР МАРИ АВЫЛЫ. УЛ УДМУРТИЯ ҺӘМ КИРОВ ӨЛКӘСЕ БЕЛӘН ЧИКЛӘШӘ. ШАКТЫЙ ЕРАКТА УРНАШСА ДА, БИРЕДӘ ҺӘРВАКЫТ КУНАКЛАР КҮП: РЕСПУБЛИКАДАН ДА, БАШКАЛАДАН ДА ҺӘМ ЧИТ ИЛЛӘРДӘН ДӘ КИЛӘЛӘР БИРЕГӘ. АЛАРНЫ НӘРСӘ ҖӘЛЕП ИТӘ СОҢ? БӘЛКИ «ТӘГӘРМӘЧЛЕ МУНЧАДЫР»? ЯИСӘ МИЧТӘ ПЕШКӘН МАРИ КОЙМАКЛАРЫМЫ? Ә БӘЛКИ ҮЗЛӘРЕНЕҢ «БУРАН», ЯГЪНИ МӘСӘЛӘН КҮКЛЮК ӘБИЛӘРЕ ҺӘМ ЗУРЛАП УЗДЫРЫЛА ТОРГАН «СЕМЫК» ФОЛЬКЛОР БӘЙРӘМЕДЕР? ӘЙДӘГЕЗ, КҮЗ САЛЫЙК ӘЛЕ, ҖИРЛЕК НИ БЕЛӘН ЯШИ ИКӘН, БӘЛКИ СЕЗНЕҢ ДӘ БИРЕГӘ КИЛӘСЕГЕЗ КИЛЕР.

**МАТУРЛАНДЫРЫЛГАН «ПОЧМАК»**

Күклюк дигән атама, тәрҗемә итсәк, «як», «почмак» дигәнне аңлата. Хәзер биредә урманнар ул заманнардагы кебек күп түгел, алай да болан, поши, кабан дуңгызларын очратырга була. Без озын юл буйлап барабыз: Алабугадан – 45 чакрым. Юл шәһәр юлларыннан ким түгел.

– Безнең җирлеккә җиде торак пункт керә. Иң кечкенәсендә ике генә кеше яши. Анда да юлны һәрвакыт чистартып торабыз, – дип сөйли җирлек башлыгы Аркадий Бахметов. Ул инде 19 елга якын җирлек белән җитәкчелек итә икән. Үзе дә тумышы белән Иске Күклюк авылыннан, милләте буенча мари кешесе. Үз вакытында иң яшь җирлек башлыгы булган: вазыйфасына керешкәндә аңа нибары 24 яшь кенә тулган. Эшен баш-

**Җирлектә күп эшләр федераль, республика һәм җирле программалар кысаларында башкарылган. Бары тик грантлар формасында гына да җирлек соңгы ике елда 600 мең акча алган. Әлеге акчаларга клубны җиһазлаганнар, мәктәп өчен техника һәм спорт инвентарьлары сатып алганнар. 300 меңен күптән түгел генә отканнар, җирлекләрдә үзәк яңа ел чыршысын иң матур бизәү буенча республика конкурсында җиңү яулаганнар.**



Җирлек башлыгы Аркадий Бахметов (уңда) һәм тарих укытучысы Николай Мельников.



«Мари ызбасы» этномәдәни комплексы.

лаганда ул үз алдына максат куйган: «авылдагы тормыш шәһәрдәгедән ким булмаска тиеш».

– Ул заманнарда яңгыр вакытында урам буйлап тракторда гына узарга була иде, урамны яктырту гомумән юк иде, – дип искә төшерә Аркадий Борисович. – Әкренләп барысын да эшләдек. Бездә ФАП, спорт залы, клуб, ут, газ бар, урамнар яктыртыла. Чүп-чар даими чыгарыла! Үзем уйлап куям: шәһәрдәге кебек яшибез бит!

Җирлекләрдән чүп-чар чыгаруны оештыру – Алабуга районы башлыгы Геннадий Емельянов ярдәме нәтиҗәсе. Элек чүпләрне гомумән оешкан төстә чыгару юк иде, һәм менә өч ел бу эш башкарыла. Чокыр-чакырлар да дистә еллар буе җыелып килгән чүп-чардан арынып килә.

Автомобиль юлларына килгәндә исә, кечкенә авылларга таш җәясе калган, бу агымдагы елга куелган төп максат. Ул вакытта анда да кешеләр өйләр төзи башлаячаклар. Әле тагын яңа республика программасы буенча авыл советы административ бинасына капиталь ремонт үткәрергә ниятлиләр. Авыл йорты заманча бинага әйләнәчәк.

Җирлектә күп эшләр федераль, республика һәм җирле программалар кысаларында башкарылган. Бары тик грантлар формасында гына да җирлек соңгы ике елда 600 мең акча алган. Әлеге акчаларга клубны җиһазлаганнар, мәктәп өчен техника һәм спорт инвентарьлары сатып алганнар. 300 меңен күптән түгел генә отканнар, җирлекләрдә үзәк



Башлык Убырлы карчыкның күчмә ызбасына керергә чакыра.

яңа ел чыршысын иң матур бизәү буенча республика конкурсында җиңү яулаганнар. Кардан скульптуралар белән бизәлгән бәйрәм мәйданыннан тыш, авылдагы күп кенә утарларда да кар сыннар куелган.

Призны авыл үзәгендә, клуб янында, парк ясауга тотарга карар кылганнар. Шактый зур эш көтә: сукмаклар түшәргә, эскәмияләр куярга, яктылык урнаштырырга, чәчәк түтәлләре эшләргә, тыл хезмәтчәннәре хөрмәтенә мемориаль такча ачарга кирәк.

– Авылны төзекләндерү, матурайту – өстенлекле төп эшләребезнең берсе, – ди җирлек башлыгы. – Авылда кайда да ял итеп була дип тә әйтергә мөмкиннәр. Әйе, тик бу бит авылда культуралы ял итү урыннары булмаска тиеш дигән сүз түгел, әйтик, балалар, оныклар белән ял итәргә, аралашырга, уйнатырга.

## МӘКТӘП БАР ИКӘН – АВЫЛ ДА ЯШИ

Без урам буйлап атлыйбыз, һәм Аркадий Борисович авылның истәлекле урыннары белән таныштыра. Менә репрессия корбаннары истәлегенә һәйкәл – кайбер гаиләләр 10–20 кешеләрен югалтканнар. Мәктәп директоры Иван Мельников тарих белән ныклап кызыксынучыларның берсе, ул безгә дә авылдашлары истәлеген бер минут тынлык белән искә алырга тәкъдим итә.

Янәшәдә – күкләргә мөрәҗәгать иткән нәфис йөзле җирлекнең саклаучы фәрештәсе. Әлеге скульптураны монда яшәгән рәссам ясаган.

Ә менә болары – кар тавы, чаңгы юлы, күпфункцияле спорт мәйданчыгы, балалар мәйданчыгы, хоккей корты. Авылларда спорт белән шөгыльләнү гадәте таралмаган, физик хезмәт болай да җитәрлек кебек. Тик тыр-




Репрессия корбаннары истәлегенә һәйкәл — кайбер гаиләләр 10—20 кешесен югалтканнар.

**Безнең мәктәп – мари мәдәниятен саклау үзәге ул, биредә менә дигән коллектив, укучылар яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр. Иртән мәктәпкә баручы балаларның гәпләшкәнен, көлешкәнен ишеткәч, күңел шатлана. Әгәр бу да булмаса, авылда тормыш бөтенләй сүнә.**

ма тырмалау һәм маллар карау физкультура белән шөгыльләнгәндәге кебек файданы бирми.

Авыл балалары, аз санда булсалар да (мәктәбенә – 17 укучы), районда оештырылган барлык спорт ярышларында катнашалар, призлы урыннар яулыйлар. Шулай да мәктәп бинасы биредә шактый зур, 170 укучыга исәпләнгән. Кайчандыр ул чыннан да шаулап-гөрләп торган, ә хәзер тын, өйдәге кебек тыныч. Дәресләргә 30 ел элек кебек кыңгырау белән чакыралар. Беренче катта – балалар бакчасы. Безне мөлаем генә ханым каршы ала, бакча мөдире икән. Ул тавышын акрынайтып кына (бакчада – йокы сәгате, сабыйлар ике ярусլы кроватьларда йоклыйлар), бакчаның тулылыгы, 14 бала йөрүе, коллективның бик дус булуы турында сөйли, менә күптән түгел генә интерактив такта откаңнар икән – шундый зур, әле ачылмаган да.

Күптән түгел генә бу уку йорты урта мәктәптән гомумигә әйләнгән. Әлбәттә, аңа ябылу куркынычы да янарга мөмкин, монда балалар бик азга калып бара бит. Ләкин мәктәп – авылның үзәге, ул ябылганнан соң, авылсалаларның әкренләп сүнә баруына мисаллар шактый бит.

– Яхшыга өметләнәбез, туучылар әлегә бар, яңа кешеләр дә күченеп киләләр, – ди җирлек башлыгы. – Безнең мәктәп – мари мәдәниятен саклау үзәге ул, биредә менә дигән коллектив тупланган, укучылар яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр. Иртән мәктәпкә баручы балаларның үзара гәпләшкәнен, көлешкәнен ишеткәч, күңел шатлана. Әгәр болар булмаса, авылда тормыш бөтенләй сүнәр кебек.

## ТУРИСТИК МАРШРУТ

Күпсанлы кунакларны үзенә җәлеп иткән авылның төп үзенчәлекләренең берсе – мари халкының сакланып калган традицияләре. Мәктәп территориясендә борынгы мари хуҗалыгын чагылдыручы тулы бер утар урнашкан. Аның үзәк өлешендә, әлбәттә, ызба тора. Бүрәнәдән, салам түбәле, ул элек мари халкының ничек яшәгәнен чагылдыра. Урта зурлыктагы бер бүлмә, анда мич, гади генә җиһазлар, сандык, бишек, гөбе, каба. Мондый өйдә 10–12 кеше яшәгән – мариларда гаиләләр бик зур булган. Кышын өйдә яңа туган бәрән яисә бозауларны да алып кергәннәр, язын каз йомыркасында утыра, иртән-иртүк алар каңгылдашып, бөтен гаиләне уята.

Музей-йорт өчен борынгы әйберләрне бөтен авыл белән җыялар. Монда әле дә ягыла торган мичне, табагач һәм кисәү агачларын күрергә була. Кроватьта – салам түшәк, мондыйда йоклау арка өчен файдалы. Бирегә килгән туристлар «Марийские зори» милли ансамбле башкаруында җырлар тыңлыйлар, коймак, тәм-томнар белән сыйланалар. Теләге булганнарга авыл эшләрен башкарып карау мөмкинлеге тудырыла: кәрзин үрү, утын кисү һәм яру, атта йөрү кебек шәһәр кешесе үз гомерендә бер тапкыр да эшләп карамаганны эшли алалар бу авылда. Хуҗалык территориясендә кара мунча да бар, туристлар мунча кереп чыга ала. Гел шундый мунчада чабынган кешегә үпкә чирләре тими, дип сөйлиләр.

Узган елны бирегә 600 турист килгән. Германия, Төркия, Кытай, Финляндия, Казахстан кебек чит илләрдән дә кунаклар булган икән.

Ә бу якларда бик зурлап үткәрелә торган чара – «Семык» Республика традицион мари мәдәнияте бәйрәме. Бу чыннан да олы вакыйга. Ул саен җәй көнне республиканың марилар яши торган төрле районнарында оештырыла. Соңгы ун елда Иске Куклюкта ул ике мәртәбә үткәрелгән. Меңләгән кунакны каршы ала – гади генә бурыч түгел, берничә ай дәвамында әзерлек таләп ителә. Аның каравы кунаклар бәйрәмнең Алабуга районында тиешле югарылыкта оештырылуын билгеләп үтәләр.

Мари халкы бер-берсе белән элемтәләрне җуймаска тырыша. Куклюк ансамбле концертлар белән башка мари авылларына бара. Ә Иске Куклюкка еш кына Йошкар-Ола-



Безнең Куклюк әбиләре.



«Семык» Республика традицион мари мәдәнияте бәйрәме (Иске Күклюк авылы).

**Җирлектә барлыгы 500 кеше яши, шуларның 70 проценты марилар. Руслар татарлар, керәшеннәр, азәрбайҗаннар бар. Дус-тату яшиләр. Күп кенә марилар туган телләре һәм рус телен белүдән тыш, татарча да сөйләшәләр. Мари теле мәктәптә факультатив рәвешендә өйрәнелә. Традицион мәдәниятне саклауда халык ансамбльләре зур роль уйный.**

дан артистлар килә. Күптән түгел генә булган концерт афишасын әле алырга да өлгермәгәннәр иде.

## КҮКЛЮК ӘБИЛӘРЕ

Җирлектә барлыгы 500 кеше яши, шуларның 70 проценты марилар. Руслар татарлар, керәшеннәр, азәрбайҗаннар бар. Дус-тату яшиләр. Күп кенә марилар туган телләрен һәм рус телен белүдән тыш, татарча да сөйләшәләр. Мари теле мәктәптә факультатив рәвешендә өйрәнелә. Традицион мәдәниятне саклауда халык ансамбльләре зур роль уйный. «Ужара» («Таң») балалар вокаль-хореография ансамбле күп кенә фестивальләрдә дипломант булган коллектив. Ә өлкән артистларны авылда шаяртып «безнең буран әбиләребез» дип атыйлар. Күптән түгел генә аларны 200 мең сумлык сертификат белән бүләкләгәннәр. Әлеге акчаларга аппаратура һәм яңа сәхнә костюмнары тектерергә ниятлиләр икән.

Ансамбль авылга килгән кунакларны каршылый, җыр белән генә түгел. Хатын-кызлар пироглар пешерәләр, мари милли тәм-томнарын әзерлиләр, үлән чәйләре белән сыйлыйлар. Җәен бирегә бик күп балалар экскурсиягә килә, аларга да мари халкы көнкүрешен күрсәтәләр – шәһәр балалар өчен бу чып-чын экзотика инде.

## ТӘГӘРМӘЧЛЕ МУНЧА

Иске Күклюкның тагын бер кызыклы шәхесе – җирле мәктәп директоры Иван Мельников. Үз халкының мәдәни һәм тарихи мирасын өйрәнүдән тыш, оста бөтен Россиягә үзенең уйлап табулары белән билгеле. Конструкциясен булдыра алганча җиңеләйтеп, иске «Москвич»тан «лошемобиль» ясаган ул: арбада утырып йөрү алай ук җайлы түгел, ә монда баш өстендә түбә, җил дә исми. Тәртәсен кидереп, ат җигә дә – алга. Бензин кирәкми, ягулык урынына – бер-ике чиләк су һәм бер кочак печән.

Бераздан алтынкулның коллекциясендә «лошесани» дип аталганы пәйда була. Монысын җыюда мәктәптә эшләүчеләр дә, укучылар да булышкан. Чана табанына утыртылган «Москвич» кабинасы җыйнак кына чанага әверелгән.

Чираттагы проект итеп тәгәрмәчле мунчаны атарга кирәктер. Бу турыда Иван Николаевич күптәннән хыялланган. Эшкә яраксыз автобус рамына 3х3 метрлы агач бура утырталар, мич итеп, К-700 тракторы дискын җайлыйлар – морҗасын эшлиләр, ташын салалар. Су савытлары урынына – ике иске газ баллонын көйлиләр – 100 литр су өч-дүрт кеше юынып чыгарга җитә. Яктылыгы – керосин лампасы. Гомумән, конструкция тулысынча автоном. Барган килеш юынырга була: тракторга эләктердең дә рәхәтләнеп юын! Борылышлар өчен мунчаның руле дә бар. Мондый тәгәрмәчле мунчаны җәйге урак өстендә кулланырга мөмкин – кырда эшләүчеләр өчен. Аны туристларга да күрсәтәләр.

Күчмә мич тә бар биредә: Масленица бәйрәмендә аны авыллар буйлап йөртәләр, халыкны коймак белән сыйлыйлар.

## АВЫЛ «КОМАНДАСЫ»

– Өлкән буын турында онытырга ярамый. Без үзебезнең картларыбызны бәйрәмнәргә чакырабыз. Чәй белән сыйлыйбыз, концерт күрсәтәбез – алар рәхмәтле, берничә елга яшәреп киткәндәй булалар, – дип елмая Аркадий Бахметов. – Халык белән киңәшләшеп, алар нәтиҗәне күрерлек, үзләре дә бу эшләрдә катнашырлык итеп эшләргә тырышабыз.

Җирлек башлыгы үз командасына ышана. Ә команда – авыл советы белән башкарма комитет кына түгел, бюджет оешмаларында эшләүчеләрнең барысы да дип әйтергә мөмкин: алар барлык эшләрдә дә беренче ярдәмчеләр. Монда очраклы кешеләр юк. һәркем үз урынында. Район советы депутатлары белән эш уңышлы оештырылган. Алар арасында – Алабуга политехника колледжы директоры Светлана Соколова. Барлык чараларны үткәрүдә яшь эшкуар, крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы Илфар Җамалетдинов ярдәм кулы суза. Авыл җирлеге территориясендә үсемлекчелектә һәм яшелчә игүдә махсуслашкан «Вятские зори» һәм «Новый Юраш» агрофирмалары эшли. Халык та үз хуҗалыкларында сыерлар тота, эремчек, сөт кебек бүген бик кирәкле натураль продуктлар сата. Каз һәм үрдәк, тавык һәм индоутка кебек кош-корт асраучылар да байтак бу авылда. Әгәр кош-корт тотуны субсидияләү программасы эшләп китсә, халык бик теләп кушылыр иде.

Менә безнең Күклюк шулай матур итеп, республикадагы күп кенә авылларга күпмилләтле Татарстанда яшәүче халыкларның милли гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү үрнәге булып яшәп ята.



Надил ГЫЙМАДЕТДИНОВ тексты.
Фотолар Түбән Кама муниципаль район Советы матбугат хезмәтеннән алынды һәм Андрей ТИТОВныкы.

# КАМА *буендагы яшел кала*

БЫЕЛ СЕНТЯБРЬДӘ 50 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТӘРГӘ ӘЗЕРЛӘНГӘН ТҮБӘН КАМАНЫ БҮГЕН ХАКЛЫ РӘВЕШТӘ ТАТАРСТАННЫҢ ГЫНА ТҮГЕЛ, БӨТЕН РОССИЯНЕҢ НЕФТЬ ХИМИЯСЕ ҺӘМ НЕФТЬ ЭШКӘРТҮ БАШКАЛАСЫ, ДИП ӘЙТЕРГӘ БУЛА. ТӨП КАПИТАЛГА ИНВЕСТИЦИЯЛӘР ҖӘЛЕП ИТҮ ҺӘМ ҮЗЕНДӘ ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН ТОВАРЛАР КҮЛӘМЕ БУЕНЧА ШӘҺӘР РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ АРАСЫНДА ИКЕНЧЕ УРЫННЫ БИЛИ. ШУЛ УК ВАКЫТТА ХИМИКЛАР КАЛАСЫ – ТАТАРСТАНДА ИҢ «ЯШЕЛЛӘРДӘН» БЕРСЕ.

Шәһәр мәйданының тугыз гектары яшел агач-куакларга бирелгән, бу мәйдан елдан-ел арта. Мәсәлән, 2015 елда Түбән Камада 20 мең төп яңа агач һәм куак утыртылган, ә кала үзе Россиянең һаваны аеруча пычрата торган мегаполислары «кара исемлегеннән» төшереп калдырылган.

– Узган ел юлларны яңарту, тракларны һәм социаль тармак учреждениеләрен – хастаханәләр, мәктәпләрне ремонтлау, балалар бакчалары төзү һәм яңа сәнәгать җитештерүләре ачу белән дә хәтердә калыр, – дип сөйли Түбән Кама муниципаль районы башлыгы, Түбән Кама шәһәре мэры Айдар Метшин. – Икътисадый кыенлыкларга карамастан, безнең сәнәгать предприятиеләре үз хезмәт коллективлары каршындагы барлык социаль йөкләмәләрен тулы күләмдә үтәде.

### БӘХӘССЕЗ ӨСТЕНЛЕКЛӘР

Соңгы вакытта сизелерлек үзгәргән Түбән Кама белән танышуыбызны өр-яңа 2нче шәһәр дәваханәсеннән башладык. Шәһәр халкы әлеге вакыйганы 23 ел көткән! Аны төзүгә һәм җиһазлар сатып алуга республика бюджетыннан 327 миллион сум акча сарыф ителгән. Бүген бу медицина учреждениесе сменага 700 кеше кабул итә ала. Заманча җиһазландырылган биш катлы бинада авырулар һәм персонал өчен күп уңайлыклар тудырылган.

– Иске дәваханәдә без мондый функциональ мөмкинлекләр һәм уңайлыклар турында хыяллана да алмадык, – дип сөйли Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе баш табибы Габибулла Әхмәтов. – Ул химкомбинатның элеккеге тулай торагында урнашкан иде бит.

Шулай да иске дәваханә бина-

сы буш тормаячак: җирле хакимият аны табиблар өчен торак итеп үзгәртергә планлаштыра. Бу исә 88 фатир, дигән сүз.

2015 елда Түбән Камада 260 балага исәпләнгән «Сөенеч» балалар бакчасы, Идел буе федераль округының Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Татарстан кадетлар корпусы базасында 25 метрлы йөзү бассейны һәм спорт залы булган заманча физкультура-сәламәтләндерү комплексы куллануга тапшырылган. Шулай ук биш универсаль спорт мәйданчыгы (берсе – районда) төзелгән, күпфатирлы 97 йорт, 5 яшүсмерләр клубы, 2 балалар бакчасы, 2 мәктәп капиталь ремонтланган.

Капиталь ремонттан соң яңартылган 1нче балалар дәваханәсе ачылган. Хәзер «Кояшлы» исемен йөрткән бу учреждение бүгенге көндә 34 меңгә якын баланы кабул итә.

Түбән Кама актив төзелә һәм үз чикләрен киңәйтә. 2011 елдан бирле барлыгы 600 мең квадрат метр торак куллануга тапшырылган, шулардан 131 мең квадрат метры – 2015 елда. Ике елдан соң 47нче һәм 49нчы микрорайоннарда 12 мең түбәнкамалы өй туе үткәрер, дип планлаштырыла. Биредә гомуми мәйданы 230 квадрат метрдан артыграк булган 37 йорт куллануга тапшырылачак. Социаль ипотека программасы буенча төзелә торган фатирлар «Түбән Кама Нефтехим», ТАИФ-НК, ТЭЦ-1 предприятиеләре хезмәткәрләре һәм бюджеттагылар өчен тәгаенләнгән.

Бүген Түбән Камада ике ресурс үзәге уңышлы эшли. Аларның беренчесе – нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы – шәһәр һәм республиканың нефть химиясе һәм нефть эшкәртү җитештерүләре өчен «эшче кадрлар чыныктыру урыны» булып тора. 51 ел эшләү дәверендә уку йорты 45 мең югары квалификацияле белгеч әзерләгән. Икенче ресурс үзәге – индустриаль техникум – шин җитештерү өчен белгечләр әзерли.

## ТУКАЙНЫ ХӨРМӘТЛӘП

Ярты гасырлык тарихына карамастан, Түбән Кама яшь, динамик үсештәге, креатив шәһәр булып кала бирә. Моңа ачык дәлил – төзекләндерү буенча 2015 елда башланган «Минем эскәмия» муниципаль проекты, анда теләгән һәркем катнаша алган. Нәтиҗәдә бер-ике ай эчендә шәһәрнең төрле почмакларында, эшмәкәрләр, меценатлар ярдәме белән, калага үзенә бертөрле ямь өстәп, 30 өрнәк үзенчәлекле эскәмия пәйда булган. Акция быел да дәвам итәчәк.

2015 елда Камадагы калада төзекләндерү буенча күп эшләнгән. Мәсәлән, «Татнефть» һәм «ТАНЕКО» компанияләренең актив катнашында «Кояшлы алан» спорт һәм гаилә ялы паркы янәшәсендә «ТАНЕКО» әкият бакчасы пәйда булган.

Габдулла Тукай исемендәге яңартылган уку һәм ял паркына да халык югары бәя бирә. Аны



«Узган ел юлларны, торак һәм социаль тармак учреждениеләрен ремонтлау белән истә калды», – дип сөйли Түбән Кама муниципаль районы башлыгы, Түбән Кама шәһәре мэры Айдар Метшин.

**Бүген Түбән Камада ике ресурс үзәге уңышлы эшли. Аларның беренчесе – нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы – шәһәр һәм республиканың нефть химиясе һәм нефть эшкәртү җитештерүләре өчен «эшче кадрлар чыныктыру урыны» булып тора. 51 ел эшләү дәверендә уку йорты 45 мең югары квалификацияле белгеч әзерләгән. Икенче ресурс үзәге – индустриаль техникум – шин җитештерү өчен белгечләр әзерли.**




Узган ел шәһәрдә өр-яңа 2нче дәваханә ачылган.

реконструкцияләүгә республика һәм шәһәр бюджетларыннан 100 миллион сум чамасы акча бүленгән. Шунысы да әһәмияткә лаек – паркны төзекләндергәндә агачларның күбрәк өлешен саклап кала алганнар. Нәтиҗәдә шәһәр халкы фонтан, Су анасы, Былтыр, Шүрәле, Кәҗә, Сарык һәм Тукайның башка әсәрләре персонажлары сыннары куелган, яхшы яктыртылган парклы булган. Биредә газоннар бик пөхтә, җәяүлеләр һәм велосипедчылар өчен юллар ясалган, уңайлы эскәмияләр куелган, татар йорты, шулай ук шигырьләр уку өчен сәхнә бар. Парк территориясенең өчтән бер өлешен төрле яшьтәге балалар өчен спорт-уен зонасы алып тора.

Юл аша урнашкан Габдулла Тукай исемендәге яңартылган үзәк шәһәр китапханәсен исә паркның башы яки тематик дәвамы итеп карарга була. Биредә бөтен җирдә укырга рөхсәт ителә: киң тәрәзә төбендә дә, төсле кәнәфидә дә, йомшак пуфта да, хәтта китап киштәсендәге махсус уентыда да. Теләсә нинди китапны үзеңә алырга ярый. Белемгә омтылганнарга җайлырак булсын өчен, бинада күчерелмәле баскычлар куелган. Балаларны фикерләргә өйрәтә торган төрле уеннар һәм китаплар махсус җиһазландырылган бүлмәгә тупланган.

Китапханәдәге алты эш өстәленә компьютерлар куелган, Wi-Fi да, ЛитРес ресурсының аудио– һәм электрон китапларын бушлай укып була торган планшетлар да бар.

– Кайчандыр бу стеллажлары тузанга баткан, тәрәзәләре рәшәткәле, караңгы, ямьсез бер бина иде, – дип сөйли китапханәнең укучыларга хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире Анфиса Фәйзетдинова. – Мәскәүгә сәфәрләренең берсендә директорыбыз Гөлназ Арысланова Достоевский исемендәге китапханәдә була, заманча китап йортының ниндилеген күрә һәм Түбән Камада да шуңа охшаш бина булдырырга омтыла. Республика акча белән ярдәм иткәч, идея тормышка аша.

Хәзер яңартылган китапханә чын иҗтимагый үзәккә әйләнгән. Ачылып бер-ике ай үтүгә үк, анда йөрүчеләр саны ике-өч тапкыр арткан.



2015 елда Түбән Камада 260 балага исәпләнгән «Сөенеч» балалар бакчасы кулланууга тапшырылган.



Түбән Кама нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы шәһәрдәге сәнәгать гигантлары өчен эшче кадрлар әзерләү урыны булып тора.

**Шәһәр халкы фонтан, Су анасы, Былтыр, Шүрәле, Кәҗә, Сарык һәм Тукайның башка әсәрләре персонажлары сыннары куелган, яхшы яктыртылган парклы булган. Биредә газоннар бик пөхтә, җәяүлеләр һәм велосипедчылар өчен юллар ясалган, уңайлы эскәмияләр куелган, татар йорты, шулай ук шигырьләр уку өчен сәхнә бар. Парк территориясенең өчтән бер өлешен төрле яшьтәге балалар өчен спорт-уен зонасы алып тора.**

– Бу – Россиядә шундый типтагы дүртенче китапханә, калган өчесе Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм Владивостокта, – дип горурланып сөйли район башлыгының кече һәм урта бизнес мәсьәләләре буенча киңәшчесе Максим Сперанский. Ул китапханәне булдыруда иң актив катнашкан һәм проектның «креатив» өлеше өчен җаваплы булган. – Хәзер иң мөһиме – шәһәр китапханәләрен реконструкцияләүне системалы, планлы процесска әйләндерү. Миңа шундый ук китапханәне Әлмәттә ачарга ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеләр инде, тиздән башкалар да килә башлар, дип уйлыйм.

### ТИУЛӘР ЭШЕ

Түбәнкамалылар территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүдә әйдәп баручылардан берсе булып тора. Шәһәрдәге ТИҮ хәрәкәтенә инде 16 ел, биредәге микрорайоннарда 25 Территориаль иҗтимагый үзидарә советы исәпләнә. Совет чикләре депутат округлары чикләре һәм полициянең участок вәкилләренә беркетелгән чикләр белән тәңгәл килә. Һәр ТИҮС эшчәнлеге зона-



Лариса Орлова 6,7нче микрорайоннардагы ТИҮСләр белән 2000 елдан бирле җитәкчелек итә.

сында 7дән 14 меңгә кадәр кеше яши.

Һәркемгә мәгълүм ки, муниципаль берәмлек башлыгы белән аңлашып һәм ярдәмләшеп яшәгән, аларның фикерләренә һәм территорияләрне үстерү буенча тәкъдимнәренә колак салына торган ТИҮләр аеруча нәтиҗәле эшли.

Түбән Камада ТИҮСләр җирле хакимияткә көндәш түгел, бәлки барыннан да элек партнер буларак кабул ителә. ТИҮ советлары биредә муниципалитет җитәкчелеге һәм шәһәр халкы арасында элемтә буыны булып хезмәт итә.

– Бездә микрорайон ТИҮСләренең төгәл структурасы формалашкан, – дип сөйли Түбән Кама Территориаль иҗтимагый үзидарәләр советы җитәкчесе Тимур Гәраев. – Шәһәр иҗтимагый үзидарәсенең төп фигурасы булып ТИҮС рәисе тора, әмма микрорайон халкы белән эшләгәндә төп рольне йорт комитеты, төгәлрәк әйткәндә, йорт өчен җаваплы кеше уйный. «ТИҮС армиясе» үзидарәне оештыру мәсьәләләрен хәл итә һәм шул территориядә пәйда булган проблемалар турында сигнал бирә.

Җирле ТИҮСләр эшчәнлеге ай саен 80 меңнән артыграк тираж белән чыга торган «Без – түбәнкамалылар» газетасында чагылыш таба. Түбән Камада микрорайоннар иҗтимагый үзәкләре (МИҮ) төзелү дә уңай күренеш булып тора, анда бер түбә астында ТИҮС рәисе, полициянең участок вәкиле, балигъ булмаганнар белән эшләүче инспектор, тәртип саклау иҗтимагый пункты штабы урнашкан. Кайбер үзәкләрдә хәтта яшүсмерләр клублары да бар. Бүген шәһәрдә шундый 8 «кече мэрия» исәпләнә.

Лариса Орлова 6,7 нче микрорайоннар ТИҮСләре белән 2000 елдан бирле җитәкчелек итә. Бу вакыт эчендә ул иҗтимагый үзидарә тармагында зур тәҗрибә туплап кына калмаган, бәлки халыкның ышанычын да яулаган. Биредә яшәүчеләр үзләренең ТИҮләренең конкрет йортта, ишегалдында яки хәтта микрорайондагы яшәү шартларын чынлап та яхшырта алуларында үз тәҗрибәләрендә инанган.

– Безнең җаваплылык зонасында 9 меңнән артыграк кеше яши, – дип таныштыра мине ТИҮС рәисе. – Без территория үсешенә кагылышлы бөтен нәрсә белән шөгыльләнәбез. Мәсәлән, былтыр 300дән артык агач утырттык. Бергәләшеп, авыр хәлләргә тарыган гаиләләр проблемаларын хәл иттек. Хәзер төп игътибарны ТКХ өчен түләмәүчеләргә юнәлтәбез.

6,7нче микрорайоннар ТИҮСләре шулай ук өлкәннәргә, ветераннарга булыша, бәйрәмнәр оештыра, иганәчеләр белән бергә, социаль яктан аз якланган гражданнарга адреслы ярдәм күрсәтә. Моннан тыш, яшьләргә патриотик тәрбия бирү, хокук бозуларны кисәтү һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү дә җирле активистлар эшчәнлегендә өстенлекле юнәлеш булып тора. ТИҮС рәисенең баш ярдәмчеләре – йорт буенча җаваплылар. Аларның төп нигезен совет чыныгуы үткән кешеләр тәшкил итә.

6, 7нче микрорайоннар ТИҮСләре бюджеты нигездә иганәчеләр хисабына формалаша. Шунлыктан, Лариса Орлова әйтүенчә, территориаль иҗтимагый үзидарәләргә 2014 елдан бирле күрсәтелә башлаган дәүләт ярдәме алар өчен зур таяныч булып тора. «Татарстан Республикасының 2015 елда иң шәп территориаль иҗтимагый үзидарәсе» беренче республика конкурсында яуланган 665 мең сум күләмендәге грант та ТИҮС өчен яхшы стимул булган.

**Түбәнкамалылар территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүдә әйдәп баручылардан берсе булып тора. Шәһәрдәге ТИҮ хәрәкәтенә инде 16 ел, биредәге микрорайоннарда 25 Территориаль иҗтимагый үзидарә советы исәпләнә. Совет чикләре депутат округлары чикләре һәм полициянең участок вәкилләренә беркетелгән чикләр белән тәңгәл килә. Һәр ТИҮС эшчәнлеге зонасында 7дән 14 меңгә кадәр кеше яши.**



Нәтиҗәдә бер-ике ай эчендә шәһәрнең төрле почмакларында, калага үзенә бертөрле ямь өстәп, 30 өр-яңа үзенчәлекле эскәмия пәйда булган.




**Людмила КАРТАШОВА тексты.**
**Автор фотосы һәм Бөреле авыл җирлеге архивыннан.**

# *МАТУР авыл*

РАЙОН ҮЗӘГЕ БИЕКТАУ АРТТА КАЛДЫ, ЯХШЫ ЮЛДАН ТАГЫН БЕРНИЧӘ ЧАКРЫМ БАРГАЧ, БӨРЕЛЕ ҖӘНЛЕК СОВХОЗЫ БИСТӘСЕНӘ КИЛЕП ҖИТӘБЕЗ. БИРЕГӘ БЕЗ ОЧРАКЛЫ ГЫНА КИЛЕП ЧЫКМАДЫК – ӘЛЕГЕ БИСТӘ ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ТӨЗЕК ТОРАК ПУНКТЫ РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕНДӘ «ХАЛЫК САНЫ ӨЧ МЕҢГӘ КАДӘР БУЛГАН ТОРАК ПУНКТЛАР» КАТЕГОРИЯСЕНДӘ ҖИҢҮЧЕ БУЛДЫ. ТРНЫҢ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТКХ МИНИСТРЛЫГЫНДА ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ ҮТТЕ, АНДА БӨРЕЛЕЛЕЛӘРГӘ БЕРЕНЧЕ ДӘРӘҖӘ ДИПЛОМ ТАПШЫРЫЛДЫ. ӘЙТЕРГӘ КИРӘК, БҮЛӘК СЫЙФАТЫНДА БИРЕЛГӘН 300 МЕҢ СУМ АКЧАНЫ ДА ҖИРЛЕКНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮГӘ ТОТАРГА КАРАР ИТКӘННӘР.

### ЯМЬЛЕ КҮЛ

Соңгы елларда Бөреле җәнлек совхозы бистәсе күзгә күренеп үзгәрде – урамнар чистартылды һәм тигезләнде, шәхси утарлар гына түгел, күпфатирлы йортлар да матурланды, чәчәкләргә күмелде. Ә авыл мәдәният йорты янәшәсендәге зур булмаган сулык – бистә халкы аны күл дип йөртә – җирле халыкның яраткан ял итү урынына әверелеп килә.

һәм «әле тагын да матуррак булыр», дип вәгъдә бирә Бөреле авыл җирлеге башлыгы Таһир Баһаветдинов. Күл әйләнәсендәге территорияне төзекләндерү буенча генплан эшләнгән, анда спорт белән шөгыльләнү һәм балалар өчен мәйданчыклар, кечкенә күпер, аллеялар, йөгерүчеләр һәм велосипедта йөрүчеләр өчен сукмаклар, матур һәм уңайлы итеп эшләнгән эскәмияләр, шулай ук чәчәк түтәлләре, ылыслы агачлар һәм башка яшеллек булдыру каралган.

– Бистә халкы табигать кочагында матур итеп ял итә алсын дип, төзекләндерәбез күлне. 2016 ел Президент Рөстәм Миңнеханов карары белән Су саклау елы дип игълан ителде, – дип сөйли Таһир Хәйдәрович. – Шулай булгач, теләсә кайсы чара актуаль. Без як-



«Әле тагын да матуррак булыр», — дип вәгъдә бирә Бөреле авыл җирлеге башлыгы Таһир Баһаветдинов.

тырту эшләрен төгәлләдек инде, эскәмияләр, чүп савытлары сатып алдык, сквер өчен үсентеләргә заказлар бирдек, алар күл әйләнәсенә утыртылачак. Безгә мәктәп укытучылары, балалар бакчасы, мәдәният йорты хезмәткәрләре, торак ширкәтләре белгечләре ярдәмгә килә. Ягъни барыбыз бергә, нәтиҗә булсын, дип эшлибез. Бистә территориясен участокларга бүлдек, ул участокларның төзеклеге өчен билгеле бер оешма яки предприятие җаваплы. Кар эреп бетүгә, өмәләр башлыйбыз. һәм шул режимда кара көзгә кадәр эшлибез – бистәбездә чисталык һәм тәртипне даими рәвештә саклыйбыз.

2013 елда Таһир Баһаветдинов Бөреле җирлеген җитәкли башлаганнан соң (аны Сосновка җирлеге белән берләштергәч), үзәк авылда һәм башка торак пунктларда чисталык һәм тәртип саклауга аерым игътибар бирелә. Төзекләндерү буенча республика һәм федераль күләмдә оештырылган бәйгеләрдә катнаша башлаганнар. Кешеләр зур эшләр башкара бит, нигә катнашмаска әле? Бу турыда сөйләргә кирәк, тәҗрибә уртаклашырга.

**Ә РОССИЯ МАСШТАБЛАРЫНДА?**

Биектау муниципаль районы башлыгы урынбасары Ләйсән Галәветдинова Бөреле җәнлек совхозы бистәсенә рәхәтләнеп килә. Аңа бирелдә барысы да ошый: табигате дә, хезмәт сөючән һәм көр күңелле кешеләре дә – Бөреле бистәсе халкы шушы сыйфатлары белән дан тота. Бу юлы да җирлекне күреп китәргә килгәч, башлык кабинетында чәй эчеп алгач (иртә белән Биектауда зәмһәрир суык иде), Ләйсән Илгизовна мактау сүзләрен кызганмады. Сәбәбе дә бар иде.

– Мәскәүгә бүләкләү тантанасына чакыру көтәбез, – дип хәбәр итте ул. – Әйтергә кирәк, уртак казаныш – бәйгедә һәрбер кеше катнашты. Җирлек халкы Җиңүнең 70 еллыгына багышланган чараларда да катнашты – Биектау районы республикада беренче урынны алды. Безнең район шулай ук «Сәламәтлек территориясе» бәйгесендә дә катнашты – анда икенче урынга лаек булдык. Былтыр Муниципаль хезмәткәрләр спартакиадасында Биектау районы республика күләмендә беренче урынга чыкты. Монда шул исәптән Бөреле авыл җирлеге башлыгы Таһир Баһаветдиновның да өлеше бар. Ул менә дигән спортчы, волейбол белән мавыга.

Биектау районында торак пунктларны төзекәндерүгә соңгы елларда зур игътибар бирәләр. Бу эш бигрәк тә 2013 елда, ТР Президенты ТР Муниципаль берәмлекләре Советының гражданнарның үзара салымын дәүләт тарафыннан «1гә 4» нисбәтендә финанслау программасы башлангычын хуплагач, активлашып киткән. Биектаулылар әлеге схема буенча тәҗрибә рәвешендә эшли башлаган беренче дүрт районның берсе булган. Бөреле халкы да әлеге башлангычны хуплап каршы алган. 2013 елда алар зиратларын ремонтлаганнар, моңа кадәр караучысыз яткан каберләрне әйләндереп алганнар, шуннан соң чиркәү сала башлаганнар. 2014 елда ихата тирәләрендәге мәйданнарны чистартуга басым яса-

**Күл әйләнәсендәге территорияне төзекләндерү буенча генплан эшләнгән, анда спорт белән шөгыльләнү һәм балалар өчен мәйданчыклар, кечкенә күпер, аллеялар, йөгерүчеләр һәм велосипедта йөрүчеләр өчен сукмаклар, матур һәм уңайлы итеп эшләнгән эскәмияләр, шулай ук чәчәк түтәлләре, ылыслы агачлар һәм башка яшеллек булдыру каралган.**



Мәдәният йорты янәшәсендәге зур булмаган күл бистә халкының яраткан ял итү урынына әверелеп килә.

**Бөреле җирлеге составына Кирилловка, Керасиново, Сосновка, Бимери, Бөреле тимер юл разъезды, һәм иң зуры – Бөреле җәнлек совхозы бистәсе (анда 2465 кеше яши) керә. Җирлектә барлыгы 3188 кеше исәпләнә. Җирлекнең урта мәктәбе, амбулаториясе, 125 урынлы балалар бакчасы, мәдәният йорты, тугыз кибете, элемтә бүлеге һәм Саклык банкы филиалы бар.**

ганнар. Игътибар итсәгез, бистәдә шәхси утарлар территорияләре генә түгел, күпфатирлы йорт әйләнәләре дә чиста – анда да чәчәк, яшелчә түтәлләре бар. Кешеләр үзләре, матур һәм уңайлы булсын, дип тырыша.

## БОЛЫНЛЫДАН ӘЙЛӘНЕП ЧЫГЫЙК ӘЛЕ…

Җәй көне Болынлы урамында яшеллек хакимлек итә, төрле төсләрдәге чәчәк түтәлләренә карап күңел сөенә, ә кышын күзләр камашырлык аклык. Кар көртләре өелгән челтәрле коймалар янындагы эскәмияләр бушап калган, куаклар һәм агачлар да ап-ак карга күмелеп утыра. Тып-тын, беркем дә юк. Бары тик сирәк-мирәк кенә башына җылы шәлен ураган берәр хуҗабикә, абзардагы мал-туарга күз төшереп алырга дип, баскычка чыгып кергәли: ашатасы түгелме, су эчерәсе юкмы, янәсе. Яки инде безнең кебек көтмәгәндә килеп төшкән кунак капка кага…

Пөхтә итеп чистартылган юлдан – «Бөреле» ЯАҖ тракторчысы, йорт хуҗасы Равил Кәримовка эш бар – өйгә таба үтәбез. Моңа кадәр Таһир Баһаветдинов Кәримовлар хуҗалыгын, аларның матур итеп җыештырылган хуҗалыгын бик мактаган иде. Мондый йортлар бистәдә шактый. Әйтерсең лә, кешеләр узара ярыша – кемнеке чистарак, матуррак.

…Безгә ишекне мөлаем йөзле ханым ача – Нурия Шамилевна Кәримова, Бөреле совхозының элеккке сыер савучысы, хәзерге вакытта лаеклы ялда, уңган хуҗабикә, кайгыртучан дәү әни. Аш бүлмәсеннән өч яшьләр тирәсендәге кечкенә малай башын тыга. Нурия Шамилевна аның белән, оныгыбыз Марсель, дип таныштыра. Кызы бистәдә яши, һәр иртәне Казанга эшкә йөри, улын дәү әнисенә калдырып тора икән. Кайчак тагын бер оныкны да китерәләр – икенче кызларыныкын. Оныклар бераз үскәч, бистәдәге балалар бакчасына йөри башлаячак.

Авыл хатын-кызларына хас булганча, кытыршы кулларын алдына кушырып, Нурия апа ашыкмый гына тормышы турында сөйли. Гаилә 1982 елда Биектау районына Арчадан күчеп килгән. Ире белән совхозда хезмәт куйганнар, йорт тирәсен рәткә китергәннәр, хуҗалык торгызганнар. Хәзер инде бу йорт соклану гына уята. Бу, мөгаен, Нурия апаның канында бардыр. Ул йокламаса йокламый, ә өен ялт иткәнче чистарта. Әле Кәримовлар берничә мөгезле эре терлек тә асрый: ике сыер (моңа кадәр өчне тоткаңнар), өч бозау һәм бер үгез. Азык әзерләү ир җилкәсендә, ә сыерларны хуҗабикә үзе сава. Сыер савучы булып эшләгән кеше өчен ике сыерны гына саву авыр түгел, ди.

– Җәй көннәрендә өч сыердан көненә 30ар литр сөт савып ала идем, – ди Нурия апа. – Кыш көне азрак, шулай да начар түгел. Сатарга да җитә (күршеләр көтеп торып ала), үзебезгә дә җитәрлек кала. Элегрәк тавык, башка хайван да асрый идек, хәзер бөтен игътибар мөгезле эре терлеккә. Беренчедән, икебезнең дә яшь бара, икенчедән, хуҗалыкта сыер асрауның файдасы күбрәк – ите дә, сөте дә була. Зур булмаса да, яшелчә бакчабыз бар, анда төрле яшелчәләр үстерәм: кишер, кыяр, помидор, ташкабак, төрле яшел үләннәр, бәрәңге. Тозларга да җитә – баз асты тозланган, маринадланган банкалар белән тул-тулы.

Әмма Нурия апаның төп мавыгуы – чәчәкләр. Кыштан ук кибеттән



Әйтерсең лә, кешеләр узара ярыша – кемнең өй тирәсе чистарак, матуррак.

**Илнең иң төзек авыл җирлеге (15 меңгә кадәр халкы булган) Бөтенроссия бәйгесендә Биектау (икенче урынга лаек булды) һәм «өч меңгә кадәр халкы булган» категориясендә Бөреле (өченче урынны алды) аерылып торды. Әйтергә кирәк, бөрелеләрнең узган елгы җиңүләрен санап бетерү дә мөмкин түгел. 2015 ел башында алар территорияне Яңа елга бизәү буенча республика бәйгесендә дә беренче урын алган иде.**



Нурия Кәримованың төп мавыгуы – чәчәкләр. Кыштан ук кибеттән орлыклар алып куя, алдан ук аларны утыртырга әзерли, яз көне туфракка чәчә.



«Төзекләндерү эшләрендә актив катнаша торган кешеләр һәрбер йортта диярлек бар», – ди Хәлил Әхмәтҗанов.

орлыклар алып куя, алдан ук аларны утыртырга әзерли, яз көне туфракка чәчә. Һәм җәй буе көзгә кадәр Кәримовлар утарында төрле төстәге бакра гөлләр, ромашкалар, ләлаләр, кашкарыйлар, гладиолус һәм башка бик күп төрле чәчәкләр хуш ис таратып утыра. Мондый бакча янышнан туктамыйча үтеп китеп булмый – хозурланып карап торасы килә. Бу җәһәттән Кәримовлар гына аерылып тормый, җәй көннәрендә Бөреле совхозында бик күп ихаталар картинаны хәтерләтә – чисталык, пөхтәлек, чәчәк түтәлләре, чәчәкләрдән бизәкләп эшләнгән вазоннар. Мисал өчен, Нурия Кәримованың ахирәте – каршы йортта яшәүче Фирдәвес Ганиеваны алыйк. Ул чәчәкләрдән һәм төрле үсемлекләрдән шундый матурлык тудыра – һәвәскәр ландшафт дизайнерына бөтен бистә халкы киңәшкә йөри.

### ХУҖА ЭШЕ

– Без бергә эшлибез, бергә яшибез. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки «Бөреле» ЯАҖндә нигездә бистә халкы хезмәт куя да. Җирлек алга китсен, дип тырышабыз, чиста, уңайлы булсын, – дип сөйләвен дәвам иттерә Таһир Хәйдәрович, Кәримовлар өеннән чыккач та. Кояш нурларында кар җемелди, суыкта битләре кып-кызыл булган малайлар кар атыша. Аларга карап, еракта калган балачак искә төшә, ә башлык кыш турында фикер йөртә:

– Кыш, билгеле, елның үзенә бер фасылы, беренче карашка территорияләр җәй көннәренә караганда яктырак һәм чистарак булып тоела – барысы да, шул исәптән чүп-чар да кар астында калган бит. Ләкин яз килүгә, бөтен пычрак өскә чыга. Шуңа күрә төзекләндерү, чистарту эшләре белән даими рәвештә шөгыльләнергә кирәк, ел фасылына карап түгел. Бездә халык «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ белән килешү төзи – машина килеп, чүп-чарларны төяп алып китә. Ә менә дачада торучылар үзләре түгә. Кайчак кисәтүләр ясарга туры килә, өстәвенә, узган елдан башлап, җирлек башлыкларына тәртип бозучыларга беркетмә тутыру вәкаләтләре бирелде. Тәртип беренче тапкыр бозылганда кисәтү ясыйбыз. Ә инде бөтен искесен койма аша урамга ташлаган кешеләргә карата катырак чаралар күрелә.

Таһир Хәйдәровичтан аны бу вазыйфада нәрсә борчуы турында кызыксынам.

– Безнең бистәнең төп проблемасы булып озак еллар инде тузган бараклар кала бирә, алар безгә ерак совет чорыннан мирас булып күчте. Республика җитәкчелегенә рәхмәт, ул мондый корылмалардан актив төстә котыла бара. Күптән түгел без 27шәр фатирлы ике йортны куллануга тапшырдык, анда тузган торак программасы буенча баракта яшәгән кешеләрне күчердек. Бүген безнең төп бурыч – бистәне иске, тузган корылмалардан чистарту. Күп тә калмады инде – өч кенә барак. Быел көзгә барысын да күчерергә планлаштырабыз.

Бистә буйлап йөргән вакытта, безне анда «Бөреле» Торак ширкәте рәисе Хәлил Әхмәтҗанов озатып йөрде, без күпфатирлы бер йорт янына тукталдык. Ул матур итеп тәбәнәк кенә койма белән уратып алынган. Миңа мондый коймалар озакламый бистәдәге калган 35 күпфатирлы йорт әйләнәсендә барлыкка киләчәк, диделәр.

– Йортларга агымдагы ремонт даими рәвештә ясалып тора, – ди Хәлил Әхмәтҗанов. – Сууткәргечләрне, канализацияне алыштырабыз, подъездларга тимер ишекләр куябыз, кашагаларын үзгәртәбез. Безгә торакларга капиталь ремонт ясау буенча федераль программа ярдәмгә килә. Халык бүген үзе яшәгән мәйданның квадрат метрына 5 сум күләменнән түләп бара – шушы суммадан капиталь ремонтка дигән акча җыела. 2016 елга өч йортка капиталь ремонт планлаштырылган, аларның түбәсен алыштырасы бар. Эчке эшләрен башкардык инде. Безнең ширкәт авыл җирлеге башлыгы белән тыгыз элемтәдә тора, теләсә кайсы чара бергәләшеп үтә. Өмәләрдә катнашу да, йортлар әйләнәсендәге территорияләрне төзекләндерү дә, коймалар тоту да. Төзекләндерү эшләрендә актив катнаша торган кешеләр һәрбер йортта диярлек бар. Сүз уңаеннан, безнең бистәдә урам себерүчеләр юк – подъездларны һәм йорт тирәләрен анда яшәүчеләр үзләре җыештыра. Бистә территориясендә чүп контейнерлары урнаштырылган, чүп-чар даими рәвештә чүплеккә чыгарыла. Шулай булгач, чүп белән исәп-хисап ясалган, дип ышанам.

**Бездә халык «Бөреле коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ белән килешү төзи – машина килеп, чүп-чарларны төяп алып китә. Ә менә дачада торучылар үзләре түгә. Кайчак кисәтүләр ясарга туры килә, өстәвенә, узган елдан башлап, җирлек башлыкларына тәртип бозучыларга беркетмә тутыру вәкаләтләре бирелде. Тәртип беренче тапкыр бозылганда кисәтү ясыйбыз. Ә инде бөтен чүбен койма аша урамга ташлаган кешеләргә карата катырак чаралар күрелә.**





«ТАТАРСТАНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТ ӨЧЕН ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ЯҢА ЗАКОННАРГА ҺӘМ НОРМАТИВ АКТЛАРГА, ШУЛАЙ УК ФЕДЕРАЛЬ ҺӘМ РЕСПУБЛИКА ЗАКОННАРЫНА КЕРТЕЛГӘН СОҢГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ КҮЗӘТҮ ЯСЫЙ.

**«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 28 ноябрендәге 357-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Авыл җирлекләре хәл итә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр муниципаль районнар дәрәҗәсенә күчерелде. Төзәтмәләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча авыл җирлекләре һәм муниципаль районнар җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен яңадан бүлүгә кагыла.

Шулай итеп, элек авыл җирлекләре карамагында булган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр муниципаль районнарга беркетелде. Авыл җирлекләре территорияләрендә халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау, юл эшчәнлеге, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, җирдән файдалану, коммуналь хуҗалык, әйләнә-тирә мохитне саклау, табигатьтән файдалану, мәдәният мәсьәләләре, әгәр алар региональ законнар белән авыл җирлекләренә беркетелмәгән булса, муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә.

Шулай ук шәһәр эчендәге районнарның җирле үзидарә органнарын төзү һәм аларның үзләре караган шәһәр округлары җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре җайга салынды. Шәһәр эчендәге районнарның җирле үзидарә органнары вәкаләтләре билгеләнде.

**«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 9 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 29 декабрендәге 395-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Законда муниципаль хезмәт стажын исәпләүгә бердәй якын килү юлы билгеләнгән. Муниципаль хезмәт стажына кертелә торган, шул исәптән тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпуск дәвамлылыгын һәм башка гарантияләрне билгеләү өчен алына торган хезмәт эшчәнлеге чорлары федераль дәрәҗәдә беркетелде.

Шулай ук тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләгәндә муниципаль хезмәт стажына нинди чорларның кертелүе тәгаенләнде. Тәгәллек кертә торган үзгәрешләр дәүләт хезмәте стажын исәпләп чыгару тәртибенә дә кертелде.

**«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2.1 һәм 19 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 446-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Региональ норматив хокукый акт РФ субъектының дәүләт вазыйфаларында эшләүче затларга, шул исәптән регион башлыгына, аларның вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә өстәмә социаль һәм башка гарантияләр билгели ала, дип күрсәтелде.

Үзгәрешләрдә каралганча, мондый акт күрсәтелгән вазыйфаларда даими һөнәри нигездә эшләгән, пен-

сия яшенә җиткән яки вәкаләтләрне гамәлгә ашыру чорында хезмәткә сәләтен югалткан затларга кагылышлы гына кабул ителә ала.

Гарантияләр вәкаләтләре законнарда каралган тыюларны, чикләүләрне һәм үз бурычларын үтәмәгән өчен туктатылган затларга бирелергә тиеш түгел.

Күрсәтелгән гарантияләрне бирүнең охшаш шартларын муниципаль берәмлекләрнең уставларына да кертү карала. Гарантияләр җирле үзидарә органы депутатларына, сайланулы органы әгъзаларына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына кагылырга мөмкин.

**«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 74 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2016 елның 15 февралендәге 17-ФЗ номерлы Федераль закон.**

Муниципаль берәмлек башлыгын яки җирле администрация башлыгын вазыйфасыннан алу өчен нигезләр төгәлләштерелде.

Муниципаль берәмлек башлыгы яки җирле администрация башлыгы үз вазыйфасыннан шулай ук җирле үзидарәнең күрсәтелгән вазыйфаи заты максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертларның, бюджет кредитларының максатчан кулланылмавына китерә торган норматив булмаган хокукый акт чыгару кебек гамәлләр кылган, РФ бюджет системасының башка бюджетларыннан алынган бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирү шартларын бозган очракта, әгәр болар тиешле суд тарафыннан ачыкланган, ә күрсәтелгән вазыйфаи зат үз вәкаләтләре чикләрендә суд карарларын үтәү буенча чаралар күрмәгән булса, вазыйфасыннан читләштерелергә мөмкин.

**«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2016 елның 15 февралендәге 21-ФЗ номерлы Федераль закон.**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга муниципаль хезмәткәргә үзенә бүләк ителгән бүләкне сатып алу хокукын бирә торган норма өстәлде.

Үзгәрешләрдән күренгәнчә, муниципаль хезмәткәр, үзенә беркетмә буенча үтә торган чаралар, хезмәт командировкасы яки башка рәсми очрашулар вакытында бирелгән бүләкне тапшыргач, аны РФ законнарында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәткәрләренә һәм дәүләт (муниципаль) вазыйфаларында эшләүче затларга кагылышлы охшаш нормалар «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законнарда бар.

**«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2016 елның 15 февралендәге 24-ФЗ номерлы Федераль закон.**

РФ субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында эшләүче затларга, федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренә кебек үк, тыюлар, чикләүләр, бурычлар һәм хезмәт урынындагы тәртибенә караган кагыйдәләр билгеләнергә мөмкин.

Элек федераль конституциячел законнарда, федераль законнарда, РФ субъектлары законнарында, муниципаль хокукый актларда аерым категориядәге затлар өчен башка («Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралганнарга өстәп) чикләүләр, тыюлар, бурычлар һәм хезмәт урынындагы тәртибенә караган кагыйдәләр билгеләнә ала, дип беркетелгән иде. Шул ук вакытта әлеге норма федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасында эшләүче затларга да кагыла, дип күрсәтелгән иде. Шулай итеп, әлеге норманың гамәлдә булу кырыннан РФ субъектлары дәүләт граждан хезмәткәрләре төшереп калдырыла иде.

**Аз керемле гражданнарның муниципаль торак фондыннан социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукы тәэмин ителүгә бәйле бәхәсләр буенча эшләрнең 2013-2014 елларда судларда каралу тәҗрибәсенә күзәтү (Россия Федерациясе Югары Суды Президиумы тарафыннан 2015 елның 23 декабрендә расланды).**

РФ Югары Суды Президиумы аз керемле гражданнарның муниципаль торак фондыннан социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерелүенә бәйле бәхәсләрнең 2013-2014 елларда судларда каралу тәҗрибәсенә ясалган күзәтүне раслады.

Аерым алганда, түбәндәгеләргә игътибар бирелә.

Гражданны мондый исәптән төшерү турында карарда, РФ Торак кодексында каралган шартларга сылтама ясалып, моның нигезләре күрсәтелгән булырга тиеш.

Әлеге нигезләрнең исемлеге тулы. Аларга, мәсәлән, торак йорт салу хокукыннан башка шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир бирелү керми.

Социаль найм шартнамәләре буенча торак бирелү

хокукы гражданнарны бу торакка мохтаҗ булаunion рак кына түгел, ә аз керемле дип тә тану шартлары булганда барлыкка килә. Әгәр кешенең кереме ул аз керемле дип санала торган дәрәҗәдән артып китсә, гәрчә торак шартлары үзгәрмәсә дә, исәптән төшерелә. Ләкин исәптән төшерү өчен каралган әлеге нигез торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак 2005 елның 1 мартына кадәр торакны соңыннан социаль найм шартнамәләре буенча бирү максатларында исәпкә куелган гражданнарга кагылмый.

Җирле үзидарә органының региональ законда билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән гражданны аз керемле дип тану турында карары булмау әлеге гражданны исәптән төшерү өчен нигез булырга мөмкин.

Исәптән төшерү өчен түбәндәге шартлар да нигез була алмый:

– торак урыны мәйданының исәпкә алына торган нормасының гражданнарны исәпкә куйганнан соң җирле үзидарә органы тарафыннан үзгәртелүе;

– яшәү өчен яраксыз дип табылган торакка милек хокукын алу;

– исәпкә куелган гражданнарның яшәү урыны буенча вакытлыча булмаулары (яшәмәүләре). Мәсәлән, кеше даими рәвештә башка шәһәрдә, вакытлыча теркәлеп, дәвалану узса.

Исәпкә кую өчен тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр табылса, исәптән төшерә алалар. Шарты – нәкъ шул мәгълүмат исәпкә кую турында карар кабул ителүгә тәэсир итә алган булса.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән вакытка бирелде.

Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары билгеләнде.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирү һәм дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору тәртибе каралды.

**«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

ТР дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара һәм муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату, маршрутлар реестрларын алып бару өлкәсендә вәкаләтләре билгеләнде.

ТР Министрлар Кабинетына даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруны җайга сала торган актлар кабул итү, даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны планлаштыру документын әзерләү тәртибен, транспортта йөрүгә ташламалардан файдаланучы пассажирларны йөртүгә бәйле чыгымнарны исәпләү методикасын һәм аларны бюджет акчаларыннан каплау тәртибен раслау йөкләнде.

Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының вәкаләтләре санап кителә. Муниципаль һәм муниципальара маршрутлар билгеләү, үзгәртү, туктату мәсьәләләре җайга салына.

Халыкның транспорт хезмәте күрсәтүләрдән файдалана алуын тәэмин итү максатларында вәкаләтле органнар җайга салына торган тарифлар буенча һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларын билгелиләр.

Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу дәүләт контрактлары яисә муниципаль контрактлар төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Җайга салынмый торган тарифлар белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән тиешле маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары белән раслана.

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж

ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирү һәм аның гамәлдә булуын туктату, тиешле маршрут карталарын бирү тәртибе билгеләнә.

**«Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә ул вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре расланган шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләре тапшырыла. Вәкаләтләр биш елга яңадан бүленә.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Закон, җир кишәрлекләрен региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары салу өчен бирү вәкаләтләреннән тыш, муниципаль район составындагы җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре расланган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләрне җайга сала.

Дәүләт вәкаләтләре республиканың барлык 43 муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына биш елга бирелде.

Тапшырылган вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү республика бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан республика башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына ТР Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр тапшырыла. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату шартлары һәм тәртибе билгеләнде.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2015 елның 29 декабрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Административ хокук бозулар турында ТР кодексы федераль законнарга туры китерелде.

ТР муниципаль берәмлекләрендәге контроль-хисап органнарының, башкарма комитетларның, финанс органнарының үз вазыйфалары бурычларына муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру керә торган вазыйфаи затларына Административ хокук бозулар турында РФ кодексының аерым составлары буенча, аерым алганда, сайлау комиссияләренә акчаларны үз вакытында күчермәгән, акча белән эшләү һәм касса операцияләрен алып бару тәртибен бозган, бухгалтерлык исәбен алып бару тәртибен тупас бозган, бюджет акчаларын максатка ярашлы кулланмаган, бюджет акчаларын бирү шартларын бозган, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә комачаулаган, финанс контроле органының законлы күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәгән, белешмәләр (мәгълүмат) бирмәгән өчен, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукы бирелде.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.**

Үзгәрешләрдә каралганча, Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләрен вазыйфаларына билгеләп кую һәм мондый органнарның структурасын раслау федераль башкарма хакимият органнары җитәкчеләре белән килештермичә генә башкарыла.

Калдыклар белән эш итү буенча экология өлкәсендәге ТР Министрлар Кабинеты вәкаләтләре киңәйтелде.

Җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм республика законнарында каралган экология өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар. Элек аларның вәкаләтләре исемлеге Кодекста күрсәтелгән иде.

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә нормалар билгеләү әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыклары турындагы федераль законнарга нигезләнеп башкарыла. Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортта ташуга карата таләпләр төгәлләштерелде.

Җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләренең ике яңа категориясе билгеләнде: ял итү урыннары һәм табигать микрозаказниклары.

Ял итү урыннарына чикләрендә ял итү һәм туризм өчен файдаланыла торган һәм шәһәр урманнары, скверлар, парклар, бакча-парк ансамбльләре булган җир кишәрлекләре урнашкан территорияләр керә. Табигать микрозаказниклары дип чикләрендә кыргый хайваннар тереклек итү һәм аерым кыйммәткә ия үсемлекләр төрләре үсү, кыргый хайваннарның сирәк һәм юкка чыгып баручы төрләрен, билгеле бер урында таралган үсемлекләрнең төрләрен саклау өчен аеруча әһәмиятле җир кишәрлекләре, шулай ук махсус табигатьне саклау әһәмиятенә ия, фәнни, мәдәни, эстетик әһәмияткә ия аерым урнашкан табигать объектлары булган җир кишәрлекләре урнашкан территорияләрне таныйлар.

Ял итү урыннары, табигать микрозаказниклары, аларны махсус саклау һәм алардан файдалану режимы турындагы нигезләмәләр җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.

## «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Закон авыл халкының эш белән тәэмин ителешен арттыру һәм матди хәлен яхшырту, Татарстан Республикасының азык-төлек базарын үстерүгә ярдәм итү максатларында ТР территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны (алга таба – ШЯХ) үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын билгели.

ШЯХ шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән яисә сатып алынган җир кишәрлегендә граждан яисә аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары тарафыннан шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында алып барыла. ШЯХ алып барганда җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сату эшкуарлык эшчәнлеге булып тормый.

ШЯХ алып бару өчен торак пункт чикләрендәге җир кишәрлеге (өй янындагы җир кишәрлеге) һәм торак пункт чикләреннән читтәге җир кишәрлеге (кырдагы җир кишәрлеге) файдаланылырга мөмкин. Өй янындагы җир кишәрлеге авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен, шулай ук, шәһәр төзелеше, төзелеш, экология, санитария-гигиена, янгынга каршы һәм башка кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәгән килеш, торак йорт, җитештерү, көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар, төзелмәләр торгызу өчен файдаланыла. Кырдагы җир кишәрлеге анда биналар һәм корылмалар торгызу хокукыннан башка бары тик авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен генә файдаланыла.

ШЯХ үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре беркетелде.

ШЯХ үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру чараларына гражданнарга терлек азыклары; товар өчен һәм нәселле сыерлар, таналар, кәҗәләр, авыл хуҗалыгы өчен яшь терлекләр, кош-корт бәбкәләре; терлекчелек һәм кошчылык өчен технологик җайланмалар; сакланган туфракта яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен орлык һәм утырту материаллары, материаллар һәм җайланмалар сатып алуда; мәгълүмати-консультатив хезмәт күрсәтүләрдә ярдәм итү керергә мөмкин. Моннан тыш, авыл хуҗалыгы хайваннарына ветеринария хезмәте күрсәтүне оештыру, аларның авыруларына каршы көрәш; авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативлары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары төзүдә ярдәм итү; авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу эшләрен оештыру; ШЯХны үстерү өчен кредит ресурслары җәлеп итүдә ярдәм итү керә.

ШЯХ үстерүгә дәүләт ярдәменең финанс чаралары билгеләнде.

## ТР Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә ярдәм итә торган чаралар үткәрүче коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» ТР Министрлар Кабинетының 2011 елның 24 августындагы 706нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә ярдәм итә торган чаралар үткәрүче коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 1032 номерлы карары.

Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә ярдәм итә торган чаралар үткәрүче коммерциягә карамаган оешмаларның субсидияләр алуы өчен алар тарафыннан ТР Финанс министрлыгына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге төзелде.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр билгеләнде. Субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кайтару тәртибе күрсәтелде һәм сроклары куелды.



Бүген яшь һәм заманча Түбән Камада төзелешләр гөрли, кала үз чикләрен актив рәвештә киңәйтә.

52 бит.










# *Татарстан муниципаллары журналы*

**Хөрмәтле укучылар! Россия почтасы Каталогында басмабызның индексы үзгәрде!**







## Язылу индекслары:

**П2268 –** татар телендә

**П2258 –** рус телендә

**Журналга барлык элемтә бүлекләрендә язылырга була**